*Җырларда җырланган җирләр*
*Очратсам да юлымда,*
*Йөрәгемдә сагыну уты*
*Туган авылым уемда.*
*Көрнәлемнең үрләреннән*
*Карадым күлләренә,*
*Кайтам әле Көрнәлемә*
*Сагынган көннәремдә.*
*Безнең авыл кызларына*
*Күзе төшмәс кемнәрнең,*
*Takташны гашыйк итәрлек*
*Кыз үстергән Көрнәлем.*
*Сандугачлар әрәмәдә*
*Тыңлап үстем көйләрен,*
*Бер сандугач булыр идем*
*Әрәмәңдә Көрнәлем.*
*Көрнәлемнең үрләреннән*
*Карадым күлләренә,*
*Кайтам әле Көрнәлемә*
*Сагынган көннәремдә.*

*Зиннур Бәширов*

# КОРЫ КӨРНӘЛЕ АВЫЛЫ ТАРИХЫ

Казан
2018

УДК 908
ББК 63.3(2Рос=Тат)
К70

**Китапны нәшер итүдә
ярдәм күрсәткәне өчен
Зиннур Закир улы Бәшировка
зур рәхмәтебезне белдерәбез.**

**Төзүчеләре:**
Гомәров Илһам Госман улы
Усманов Венер Мөдәрис улы

К70 **Коры Көрнәле авылы тарихы**. – Казан, 2018. – 168 б. : 20 б. фот.

Бу китапта Татарстан Республикасы Алексеевск районының Коры Көрнәле авылы тарихына караган материаллар туплап бирелә. Коры Көрнәле тарихына мөнәсәбәтле XIV гасыр эпиграфик һәйкәлләре (кабер ташъязмалары), архив материаллары һәм башка чыганаклар анализлана.

Китап тарих белән кызыксынучы киң катлау укучыларга тәкъдим ителә.

©Гомәров И. Г., Усманов В. М., төзү, 2018

# Гүзәл авылым – Коры Көрнәлем

*Туган якның һәр авазы –*
*Үзе үлмәс бер мөнәҗәт.*
*Зөлфәт Хәким*

Туган авыл, Туган нигез, Туган туфрак... Бу сүзләр барыбыз өчен дә күңелгә җылылык, җанга рәхәтлек тойгысы бирә торган изге төшенчәләр. Әти-әниеңне алыштырмаган кебек, Туган җиреңне, авылыңны да сайлап алып булмый. Ул синең белән бергә туа, гомереңбуе синең күңелең түрендә яши. Күренекле шагыйребез Роберт Әхмәтҗанов әйткәнчә, “Адәмне гомер-гомергә үзен дөнья кочагына үстереп тапшырган туган туфрагы, нигез-оясы озата бара”.

Мин дә туган авылым Коры Көрнәлене эчке бер сагыну һәм ярату хисе белән искә алам. Инде авылдан күптән чыгып киткән булсам да, аның мәңге шаулар урманнарын, зәңгәр күлләрен, әрәмәсен күз алдыма китермәгән, киң күңелле, якты йөзле авылдашларымны сагынмаган бер генә көнем дә юк сыман.

Чыннан да, Коры Көрнәле авылы табигате искиткеч гүзәл. Борынгы бабаларыбыз бу җирләрне тормыш итү өчен бөтен шартлары булганга сайлаганнар, шуңа биредә төпләнгәннәр, күрәсең. Авылыбызның тирәсен чолгап алган урманнарда гасырлар дәвамында имән, усак, юкә, өрәңге, нарат агачлары үскән. Җимеш бирә торганнардан алма, шомырт, чикләвек, балан, миләш, байлар җимеше (бояр җимеше), кура җиләге кебек агач-куакларны санарга мөмкиндер. Аланнарында җир җиләге, каен җиләге, бөрлегән хисапсыз күп. Безнең авыл кебек мондый хозурлык эченә урнашкан авыллар бик сирәктер, минемчә.

Мин сугыштан соңгы елларда туган бала. Бүгенгедәй хәтерлим, авыр еллар булуга карамастан, авылның ул вакыттагы кешеләре бер-берсенә ярдәмчел, ихтирамлы, тырыш һәм ачык күңелле иделәр. Өйләрдә бала-чага тавышы тынмады. Кешеләре бернинди югары уку йортлары тәмамламасалар да, затлы, эчке матурлык белән яшиләр иде.

Араларыннан күршебез Хәйретдин бабайны еш искә алам. Җәен-көзен сыерын җигеп, урманнан утынын да, печәнен дә ташыган бу тырыш карт кечкенә чагымда мине дә, үзенең сыер арбасына утыртып, әрәмәгә алып баргалый иде. Менә без юл буе аның белән гәпләшеп барабыз, ул миңа үзенең яшь чактагы хатирәләрен сөйли. Шул вакытларда аның әрәмә елгасы турында әйткән сүзләре исемдә калган: “Әй, улым, әле мин яшь чакта бу әрәмә елгасы ярларын тутырып, бик киң булып ага иде. Ә хәзер, күрәсең, барлыгы бер адым киңлектә калган”. Минем “Алай булгач, бабай, безнең авыл аша шундый киң әрәмә елгасы агып торганмы?” дип соравыма, “Әлбәттә, улым! Элекке заманнарда шулай булган, аны әле мин дә күрдем” дигән җавабын яхшы хәтерлим.

Ул чорларда авылыбызның уңдырышлы кырларында игеннәр гөрләп үсте. Авыл халкы игенче, терлекче, механизатор булып кырларда, фермаларда эшләде. 260 йортлы авылның кешеләре берсе дә эшсез калмады.

Мәктәптә һәр сыйныфта егермеләп бала белем ала иде. Кичләрен клуб буш тормады, яшьләр җырлап, биеп күңел ачтылар, еш кына кинофильмнар да күрсәтелә иде. Без – яшьләр, һәрвакыт табигать кочагында булдык. Кичләрен Каенлы тау чатында, әрәмә кырыенда туплар атыш уйный идек. Андагы чәчәк исләрен бүген бернинди хушбуйга да алмаштырмас идем...

Соңгы утыз ел эчендә авылыбызда читтән килеп эшләгән

кешеләр җитәкчелек иттеләр. Араларыннан иң беренчесе, бөтен көчен куеп, тырышып, үз эшен яратып эшләгән кеше Госман Әхәтович Идиятов булды. Ике ел эчендә (1986-1988 еллар) егермеләп яшь гаиләләргә үз йортларын салырга, унлап пар яшьләрне өйләндереп туйлар уздырырга булышкан шәхес ул. Җитәкченең һәр эшне җиренә җиткереп үтәвен күргән авыл халкы, ничек инде үзе дә тырышып эшләмәсен?! Кызганыч, Госман Әхәтович озак җитәкчелек итмәде, башка урынга күчте.

Заманалар үзгәрде... Әкренләп авылда эш кими, яшьләр эш эзләп шәһәрләргә, район үзәгенә китә башладылар. Соңгы елларда авылда бернинди дә эш юк дип әйтсәң дә, ялгыш булмастыр. Заманында 260 тан артык йорты булган авылыбыз, бүген барлыгы 120 гә якын хуҗалыкка калып көннән-көн кими бара. Бу хәлләргә күңелем әрнеп, “Көрнәлем” дигән шигырь дә язган идем. Күренекле композитор Илфат Дәүләтшин аңа көй язып, халкыбызның яраткан җырчысы Фердинанд Сәлахов яратып башкарды.

Читтә яшәүче авылдашларыма мөрәҗәгатем шул, авылыбызны онытмагыз, балаларыгызны, оныкларыгызны аның хәлләре белән таныштырып яшәгез, аларны авылны яратырга өйрәтегез һәм тәрбияләгез. Чөнки туган җиреңне ярату, туганлык чылбырын өзмәү – һәркемнең изге бурычы.

Укучылар игътибарына тәкъдим ителгән бу китап та әнә шул изге эшкә ныклы бер нигез булыр дип уйлыйм. Бирегә тырыш, сабыр халкы булган Коры Көрнәле авылы, аның килеп чыгышы, тарихи яшәеше турында уйланулар, төрле чорларда авыл язмышына зур өлеш керткән авылдашларым турында якты хатирәләр туплап бирелде. Аны чыгаруга булышлык күрсәткән Наил Зәйнулла улы Гатауллинга, Илдар Шамиль улы Мортазинга, Ренат Нәбиулла улы Сөнгатуллинга,

Алмаз Нәҗип улы Хәйруллинга, Резидә Сәлахетдин кызы Фатыховага барлык авылдашларыбыз исеменнән ихлас рәхмәтемне җиткерәм.

Хыялларым, теләкләрем дә туган авылым белән бәйле. Моннан 800 еллар элек тормыш шаулап торган җирдә урнашкан Коры Көрнәлем, кайчан да булса бер кире шул халәтенә кайтыр әле дип ышанам. Яшьләргә эш, киләчәккә ныклы ышаныч булса, авылым яшәр, елга-чишмәләре саекмас, өйләрендә утлары сүнмәс дигән өметтә калам.

*Зиннур Закир улы Бәширов*

# Ерак тарих ни сөйли...
## *(Коры Көрнәле авылының килеп чыгышы турында фаразлар)*

Коры Көрнәле авылы Чулман (Кама) елгасы аръягында, Алексеевск район үзәгеннән 33 чакрым ераклыктагы көньяк-көнбатыш җирләрдә, Көрнәле елгасының югары агымында урнашкан. Шуңа күрә XVIII-XIX гасыр чыганакларында аның исемен Югары Көрнәле (Верхние Курнали) рәвешендә дә очратырга мөмкин.

Галимнәр фаразлавынча, Кама аръягы җирләрендә безнең эрага кадәр II меңъеллыкта ук кешеләр яшәгән. Алар Бура археологик культурасына караган кабиләләр булып, нигездә, терлекчелек, китмәнле игенчелек, сунарчылык белән шөгыльләнгәннәр. Арехологлар Кама аръягының көнбатыш төбәгендә Бура культурасы вәкилләре яшәгән 120 гә якын торак урыннары булуы турында сөйлиләр.

Безнең эрага кадәрге дәвернең I меңъеллыгында Кама аръягындагы җирләргә күчмә тормыш алып баручы халыклар да үтеп керә башлый. Бу иң беренче чиратта, һун кабиләләренең Бөек күчеш чорларында әлеге якларга таба хәрәкәт итүе белән бәйле. Һуннар урдасы составында Идел-Чулман буйларына башка төрки кабиләләр дә килеп утырганнар.

Безнең эраның IV йөзъеллыгында Кама аръягы җирләрендә төп шөгыльләре игенчелек булган Имәнкискә археологик культурасы вәкилләре тормыш итә башлый. Үзенчәлекле мәдәнияткә ия бу борынгы төркемнең этник чыгышы ягыннан кайсы халыкка барып тоташуы турында галимнәр арасында бүген дә бәхәсләр бара, әмма күпчелек аларның төркиләргә мөнәсәбәтле булуын раслый. Күренекле тарихчы, археолог Равил Фәхретдинов бу хакта “Кызганычка каршы, имәнкискәлеләр һәм аларның кабиләдәш күршеләре дә безгә

үзләренең исемнәрен дә, тел мирасларын да калдырмаганнар. Әмма археология мәгълүматлары ачык дәлиллиләр: Урта Идел буена болгарлар килеп утырганчы ук анда төрки телле кабиләләр яшәгәннәр һәм Идел-Урал төбәге халыкларының, шул исәптән татар халкының элгәре урта гасырлар тарихына бераз өлеш кертеп калдырганнар" дип билгеләп уза[1].

VI-VII гасырларда Кама арьягы төбәгендә күчмә мажар кабиләләре барлыкка килә. Әмма мажарлар бу җирләргә VIII йөзләрдә күчеп килгән болгар һәм башка төрки кабиләләр тарафыннан акрынлап кысрыклана баралар, нәтиҗәдә, көнбатышка таба күченеп китәргә мәҗбүр булалар. Шул вакытлардан алып бу төбәктә бик күп төрки кабиләләрне үзенә берләштергән Идел Буе Болгар дәүләтенә нигез салына.

Татар дәүләтчелеге тарихында Идел Буе Болгар дәүләте төп урыннарның берсен били. Географик яктан караганда, X-XI йөзләрдә аның төньяк чиге Каманың уңъяк яры, көнбатышта сул тармаклары белән бергә Зөя елгасы, көнчыгышта Шушма елгасы буйлап үткән, ә көньяк чикләре хәзерге Самар тугаена – Жигули таулары янында Иделнең зур борылышына кадәр барып җиткән. Дәүләт барлыкка килгән елларда аның этник составын болгар, бирсула, суар, бәрәнҗәр, искил һәм башка бик күп кабиләләр тәшкил иткән. Тора-бара алар бер исем – болгар атамасы белән аталып йөртелә башлыйлар.

Болгар дәүләтенең башкаласы булып Шәһре Болгар торган. Моннан тыш ул башка шәһәрләре белән дә дан тоткан. Биләр (Бүләр), Суар, Җүкәтау, Кашан, Ашлы, Тубылгытау, Ибраһим, Алабуга кебек шәһәрләре турында европа һәм шәрык чыганакларында күп тапкырлар искә алына. Галимнәр фаразлавынча, бу зур шәһәрләреннән тыш та, Болгар дәүләтендә монголлар явына кадәр 500 гә якын

[1] Фәхретдинов Р. Көнчыгыш Европада һәм Урта Идел буенда беренче төркиләр / http://kitap.net.ru/fahretdinov/tarih09.php [Мөрәҗәгать итү датасы: 25.07.2018]

ереле-ваклы калалар һәм авыллар яшәп килгән.

Бүгенге Коры Көрнәле авылы урнашкан җирләрдә безгә исеме билгесез әнә шундый шәһәрчекләрнең берсе булган, күрәсең. Моны биредә 1324, 1326 елларда куелган кабер ташлары да кире каккысыз раслап тора, чөнки аларның текстлары шул чордагы болгар-татар телендә язылган. Димәк ки, бу ташлар болгар каласының югары катлам вәкилләренә куелган дип уйларга ныклы нигез бар.

Болгар дәүләтендә тимер әйберләре һәм корал җитештерелгән, чуен коелган, тире-күн эшкәртелгән, алтын-көмештән бизәнү әйберләре эшләнгән. Ул Византия, Гарәп хәлифәлеге, рус кенәзлекләре, Урта Азия мәмләкәтләре белән сәүдә мөнәсәбәтләрендә торган. Идел буе Болгар дәүләтендә 922 елда рәсми рәвештә Ислам динен кабул ителә.

Тарихтан күренгәнчә, күрше рус кенәзлекләре белән сугыш-бәрелешләр дә булгалап торган. 1229-32 елларда Болгар дәүләтенә Сөбүдәй, 1236 елларда Батый хан җитәкчелегендә монгол яулары оештырыла, дәүләтнең зур шәһәрләре яндырыла, халкы юк ителә. Шул чордан алып Болгар Алтын Урда дәүләте составына керә һәм Алтын Урданың Болгар олысы рәвешендә яшәвен дәвам итә. XIV гасыр башларында элеккеге дәүләт җирлегендә Болгар, Казан, Җүкәтау бәклекләре барлыкка килә.

Казан ханлыгы оешкач Кама аръягы җирләре аның составына керә. Кызганычка каршы, әлеге төбәк тарихында бу дәвер иң аз өйрәнелгән чор булып санала. XVI гасырда биредә икенче бер татар ханлыгы – Ногай Урдасының тәэсире көчәя. Казан ханлыгы идарәчеләренең һәм Ногай Урдасы кенәзләренең уртак килешүләре нигезендә, бу җирләр ногайлы мангыт кабиләләре тарафыннан контрольдә тотыла. Биредә яшәүчеләрнең саны өзлексез сугышлар нәтиҗәсендә азайганнан азая бара.

Тарихта монгол яуларыннан соң Кама аръягы җирләре

тулысынча бушап кала, мондагы авыл һәм калаларда тормыш өзелә дигән фикер яшәп килә. Әмма шул ук вакытта, бу төбәк тарихын тәфсилле тикшергән галимнәр, XIV-XVI йөзләрдә дә Чулман елгасының аръягында татар авылларының булуын раслыйлар. Тарихчы Р.Г. Насыров бу турыда болай дип яза: “Существование оседлых поселений во внутренней части Западного Закамья обусловлено еще тем, что через территорию края проходили дороги, связывающие Казань со странами Востока. Учитывая тесные связи Казанского ханства с его ближайшим восточным соседом – Ногайской Ордой, можно сделать вывод, что движение по этим дорогам было весьма интенсивным. Эффективное функционирование таких важных путей сообщения невозможно без нахождения вдоль них поселений, специализирующихся на содержании постоялых дворов, ямских станций и т.п.”[1]. Шул рәвешле, бу төбәктә Казан ханлыгы чорында һәм аннан соң да аерым бер татар авылларының яшәве ачык дәлилләнә.

1552 елда Казан ханлыгы Явыз Иван гаскәрләре тарафыннан яулап алына. 1552-57 елларда Мәскәү кенәзлеге җәза отрядларының канкойгыч походлары нәтиҗәсендә, бу төбәктәге бик күп татар авыллары юкка чыгарыла. Алар урынында бары тик харәбәләр генә утырып кала. Әмма бу чорларда да яшәвен дәвам иткән татар авылларының булуы турында тарихи мәгълүматлар бар, ягъни яшәү өчен шартлар авырлашса да, аерым бер авылларда тормыш өзелмәгән.

Казан ханлыгы Явыз Иван гаскәрләре тарафыннан яулап алынганнан соң Кама аръягына славян кабиләләре күпләп урнаша башлый. 1651 елда Мәскәү дәүләте яңарак үз составына керткән җирләрне ушкуйниклардан, калмык, ногай чапкынчыларыннан саклау өчен, Кама аръягы чик

---

[1] Насыров Р.Г. Сельское расселение Западного Закамья во второй половине XVI-XVIII вв. Диссертация на соискание ученой степени кандидата исторических наук. – Казань, 2007. – С. 35.

буе ныгытмалар линиясе (засечная черта) төзү турында фәрман чыгара. Шушы чорларда рус дәүләтендә хезмәттә булган Сембер, Пенза, Алатырь, Темников йомышлы мишәр татарлары күпләп әлеге төбәккә хезмәткә күчереп утыртыла, нәтиҗәдә, Чулман аръягы төбәгендә кабаттан татар авыллары күбәя башлый.

Шул ук вакытта бу җирләрдә башка татар ханлыклары юкка чыгарылганнан соң җәбер-золымнардан качып килгән татарларның кайбер авылларны нигезләве турында да мәгълүматлар бар. Мондый очракларда күченеп килүчеләр, гадәттә, элеккеге кала, авыл урыннарын сайлап утырырга тырышканнар. Чөнки элек-электән үк андый кала-авыллар яшәү өчен уңайлы табигый шартлары булган урыннарда салынган булганнар.

Шунысы игътибарга лаек, Коры Көрнәле авылының барлыкка килүе турындагы фаразларның берсе нәкъ шундый тарихи фактлар белән бәйле. 1928 елда авылга экспедициягә килгән галим Сәет Вахиди, картлар белән әңгәмә вакытында, аларның “Казан шәһәрен урыслар алгач, безнең мөселманнарга авыр тормышлар башланган. Әнә шул чакта безнең Көрнәле бабай урысларның җәбер-золымыннан котылу уе белән Пенза ягыннан килеп, менә шушы урынга утырган да, шуннан соң үрчи-үрчи менә шушы безнең Көрнәле авылы килеп чыккан” дигән сүзләрен теркәп куя. Димәк ки, халык хәтерендә әле ул елларда бу вакыйгалар бөтенләй үк җуелмаган булган.

Коры Көрнәле авылы турында тарихи документларга теркәлеп калган мәгълүматлар, нигездә, XVII йөзләргә карый. Россия Дәүләт Борынгы Актлары Архивында саклanучы чыганакларда, Коры Көрнәле авылы мәчетенең 1685 еллар тирәсендә төзелгән булуы искәртелә. Тарихи реконструкция алымына нигезләнеп, мәчет төзү өчен ким дигәндә авылның 30-40 еллар инде яшәп килергә тиешлеген исәпкә алсак, XVII

йөзнең беренче яртысында бу авылда инде тормыш гөрләп торган дигән сүз.

Югарыда телгә алынганча, XVII йөздә Кама аръягы җирләренә килеп төпләнгән татарларның төп өлеше, чыгышы белән Темников, Алатырь, Сембер өязләреннән булган йомышлы татарлар. Бу шул чорларда Рус патшасы тарафыннан йомышлы морзаларга җирләр бүлеп бирелү турындагы грамота-ярлыклар белән дә раслана. Әйтик, 1623 елда патша Михаил Федорович йомышлы татар Ишмөхәммәткә, географик яктан караганда Коры Көрнәледән ерак та булмаган, Тигин (Зур Тигәнәле) авылы җирләрен беркеткән. 1681 елда Темников өязеннән чыккан йомышлы татарлар Абдул Кайбуллин, Кәдрәк Багдалов, Мостафа Давыдовларга Мораса елгасының уң як ярындагы җирләргә ия булганнар.

Коры Көрнәле авылына мөнәсәбәтле мондый төр чыганак шулай ук Темников өязе йомышлы татары, морза Елмәмәт Янбай улы Барышев исеме белән бәйле. Патша Алексей Михайлович тарафыннан аңа бирелгән грамотада “По указу царя Алексея Михайловича, и по грамоте ис приказа Казанского дворца, и по челобитью Темниковца, служилого из мурз Елмеметя Янбаева сына Барышева, велено ему отцовскую жалованную землю, что была написана по поместным книгам разбору князя Григория Шаховского в 186, 187, 188 годех (1678, 1679, 1680 гг.) за отцом его за Янбаем мурзою Барышевым в Закамской стороне, в деревне Курналях 98 четвертей, сенных покосов 90 копен, в деревне Ромодон 25 четвертей, сенных 55 копен, владеть детям ево и внучатам вечно и никому не отнимать” диелгән[1].

Грамотадан күренгәнчә, Елмәмәт морзага 1678 елларда

[1] Насыров Р.Г. Сельское расселение Западного Закамья во второй половине XVI-XVIII вв. Диссертация на соискание ученой степени кандидата исторических наук. – Казань, 2007. – С. 214.

ук атасыныкы булган Коры Көрнәле җирләре беркетелгән. Бу Темников йомышлы мишәрләре белән Коры Көрнәле авылының бәйләнешен күрсәтә торган дәлилләрнең берсе.

Биредә шунысын да исәпкә алырга кирәк, әлеге төбәкнең йомышлы татарлары һәр очракта да үзләренә таныш түгел урынга килеп төпләнгәннәр, яңа авылга нигез салганнар диеп булмый. Аерым бер очракларда, аларның бирегә килүен ата-бабаларының туган җирләренә, үз тарихи ватаннарына кайту дип тә әйтергә мөмкин. Бу хакта тарихчы Р. Насыров "Примером тому служит получение служилыми мурзами братьями Имишем и Уразметом Сюндюковыми поместья в дер. Кулбаево Мураса. Как известно предки Сюндюковых получили земли по р. Мураса еще 1561 г. Впоследствии, по невыясненным причинам, их потомки покинули эти селения. В период массовой колонизации они вспомнили о своих наследственных правах на владения предков"[1] дип яза.

Мондый фактларның очравы бүгенге Коры Көрнәле авылы белән аның җирендәге элеккеге болгар каласы арасында да турыдан-туры бәйләнеш булу ихтималы турында сөйләргә мөмкинлек бирә. Биредәге 1324, 1326 еллар белән даталанган эпиграфик һәйкәлләр, монгол яуларыннан соң бер гасырга якын вакыт узгач та әле монда кешеләр яшәве турында сөйли. Димәк, бу каланың Явыз Иван сугышчылары тарафыннан туздырылуы дөреслеккә турырак килә. Ихтимал, аның кешеләре XVI йөз урталарында бу җирләрне ташлап китеп, берәр гасырдан соң, йомышлы татарлар рәвешендә, үз ватаннарына кире әйләнеп кайтканнардыр. Шунысы төгәл мәгълүм: бу фаразны раслarлык та яисә инкарь итерлек тә фактлар әлегә билгеле түгел.

Коры Көрнәле атамасы каян килеп чыккан, аның мәгънәсе нәрсәдән гыйбарәт соң? Исем авылның тарихына ачыклык кертерлек мәгълүматлар бирәме? Әйтеп үтик, Бүген

[1] Шунда ук. – 77 б.

Татарстанда өч торак пункт “көрнәле” сүзе кергән исемне йөртә, алар – Юеш Көрнәле, Коры Көрнәле һәм Көрнәле Әмзә. Кызганычка каршы, татар авыллары исемнәрен, елга атамаларын тикшергән фәнни хезмәтләрдә “көрнәле” сүзенең килеп чыгышы турында мәгълүматлар очратып булмый. Әлеге сорауларга җавап эзләсәң, “көрнәле”нең этимологиясенә кагылышлы берничә фаразны билгеләргә мөмкин. Аларның беренчесе халык этимологиясе белән бәйле дисәк тә, ялгыш булмас. Имеш, бу җирләргә кайчандыр беренче булып Көрнәле карт килеп утырган да, алга таба авыл аның исеме белән аталып киткән. Биредә шуны әйтергә мөмкин, борынгы чыганакларда теркәлгән кеше исемнәре арасында Көрнәле исеме очрамый.

Икенче фараз да беренчесенә якын: “Башлап урын карарга килүчеләр, таудан төшәләр дә, бер иркен әрәмәгә утырып ял итәләр. Янә киткән чакта борылып: “Утырган урын күренәме?” – дип бер-береннән сорашалар икән. Аннары барысы берьюлы: “Күренә әле, күренә”, - диләр. Авылның исеме дә шуннан: күренәле дип аталган, имеш... Соңыннан Күрнәле-Көрнәле дип атала башлый”. Аңлашыла ки, монда авазларның охшаш яңгырашыннан туган фараз турында сүз бара һәм ул дөреслеккә туры килми. Фәндә мондый күренеш ялган этимология яки икенче төрле әйткәндә, паронимик аттракция күренеше дип атала.

Өченче фараз Көрнәле гидронимы, ягъни елга атамасы белән бәйле. Мәгълүм булганча, Коры Көрнәле авылы Көрнәле (русча атамасы - Курналка) елгасы башланган җирдә урнашкан. Бу җирләрдә элеккеге чорларда урманнар үскән, сазлыклар булган. Гадәттә, андый урыннарда җиләк-җимеш күп үсүчән була. Менә шундый җиләкләрнең берсе – мүк җиләге. Аның борынгы төрки атамасы “көртмәле” дип йөртелгән. Татар теленең кайбер сөйләшләрендә көртмәле сүзе бүген дә мүк җиләген белдерә һәм кулланылышта

йөри. Этимологик сүзлектә аның мәгънәсе түбәндәгечә ачылган: “Көртмәле, көртмәлек “клюква, черника. Чувашча “кетмел”... удмуртча “курытмольы”, “әче җиләк” (курыт – “әче”). Көртмәлек формасы халык этимологиясе нәтиҗәсе[1]. ““Рт” тезмәсе борынгы төрки телгә хас күренеш. Хәзерге татар телендә бу тезмәдәге “т” тартыгы төшеп калган. Борынгы төрки телдә: йомыртка, себертке, чыбырткы һ.б. хәзерге татар телендә: йомырка, себерке, чыбыркы һ.б. булып йөриләр. Көртмәле сүзендә дә “рт” тезмәсеннән “т” тартыгы төшеп калу нәтиҗәсендә, көрмәле, м-н борын авазлары чиратлашу аркасында, көрнәле әйтелеше барлыкка килгән. Көртмәле – Кәрнәле исеме башта мүк җиләге күп үскән сазлыкка (микротопонимга) бирелгән. Аннан авыл исеменә күчкән булырга тиеш” дип яза бу хакта Ә.Галиев. Чыннан да елга, авыл исемнәре арасында шушы принцип белән ясалган атамалар бихисап. Берсен генә мисалга китереп үтик. Әйтик, Каргат шәһәре. Ул Каргат елгасы буенда урнашкан. Борынгы төрки телдә “кара җиләк”, “карлыган” дигән мәгънәне белдерә. Чынлыкта да, әлеге елга буенда бүген дә кыргый карлыган күп үсә.

Шул рәвешчә, “Көрнәле” атамасы мүк җиләге күп үскән урынны белдереп, башта елга исеменә, аннан авыл исеменә күчкән булса кирәк. Коры Көрнәле исемендәге беренче компонент авыл урнашкан әлеге елганың сай сулы, ягъни башланган урынына ишарә дип уйларга кирәк. Шул ук елганың Чулманга коя торган җирендә урнашкан икенче бер авылның Юеш Көрнәле дип аталуы әлеге фикерне тагын бер кат раслап тора.

[1] Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге. Ике томда. I том. – Казан: Мәгариф - Вакыт, 2015 – 454 б.

## Көрнәленең язмышына ташлар шаһит...

*(Коры Көрнәле авылындагы ташъязма истәлекләр)*

Тарихи аң һәм хәтер белән бәйле чыганаклар арасында Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы чорларына караган татар эпиграфик истәлекләре – кабер ташъязмалары мөһим роль уйный. Гарәп язуында төрле ташларга уеп язылган бу төр истәлекләрдә инде ничәмә-ничә гасырлар дәвамында татарның дәүләтчелек тарихына караган, халкының сәяси, экономик, мәдәни яшәешенә мөнәсәбәтле мәгълүматлар сакланып килә. Бу ташъязма истәлекләрнең игътибар үзәгенә алырлык тагын бер ягы – аларның теге яки бу төбәктә борынгы чорлардан ук халкыбызның төп җирле халык икәнен дәлилләп торучы чыганаклар булуында дип тә әйтергә мөмкин.

Татар эпиграфикасын өйрәнүче галимнәр фикеренчә, мондый ташъязмалар Болгар, Алтын Урда, Казан һәм башка татар ханлыкларының мәдәни үзәкләрендә күпләп куелган булган, әмма бүген, төрле сәбәпләр аркасында, бар җирләрдә дә сакланып калмаган. Бу җәһәттән караганда, Коры Көрнәле авылы ташъязмаларның кыйммәте икеләтә арта.

Коры Көрнәле ташъязма истәлекләре эпиграфика фәнендә Сәет Вахиди, Альфред Халиков, Николай Старостин, Евгений Казаков, Равил Фәхретдинов, Һарун Йосыпов, Фәрит Хәкимҗанов, Марсель Әхмәтҗанов, Җәмил Мөхәммәтшин, Нурулла Гариф кебек галимнәр тарафыннан өйрәнелгән.

Беренче тапкыр бу һәйкәлләрне күренекле археографчы галим Сәет Вахиди исәпкә ала. Ул 1928 елның җәй айларында халыктан тарихи материаллар, кулъязмалар җыю максаты белән, Болгар төбәге авылларына экспедициягә чыга. Фәнни эзләнүләре барышында галим Коры Көрнәле авылына да туктала һәм биредәге ташъязмалар турында тәфсилләп үзенең

куен дәфтәренә теркәп куя. Кызганыч ки, Сәет Вахидигә аларны матбугатта бастырып киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим итү насыйп булмый. Татарның бу фидакарь галиме шәхес культы елларында кулга алына һәм атып үтерелә, ә куен дәфтәрендәге язмалары озак елларга билгесезлектә кала.

Сәет Вахиди Коры Көрнәледә 7 кабер ташын язып алган. Шулардан бишесенең язылу рәвешен төгәл күрсәтә, икесен гомуми мәгълүмат буларак теркәп куя. Урта гасырларга караган бу ташлардан тыш, 1831 елда Рәхимкол бине Сөләйманга куелган ташъязма турында да искәртеп уза.

Алга таба бу тарихи табылдыкларга югарыда исемнәре телгә алынган галимнәр мөрәҗәгать итә. А.Халиков, Е.Казаков, Н.Старостин авылда XIV гасырга караган 4 таш һәм берничә фрагмент булуы турында болай дип язалар: “Авылның төньяк читендә, зиратта XIV йөзгә караган 3 кабер ташы һәм берничә ватык кисәкләр бар. […] Бер тирәдә торган бу ташлардан төньяк-көнбатышка таба 100 метр ераклыкта аерым гына торучы тагын бер куфи язулы, әмма язуы инде җуелган бер таш бар. Ул типологик яктан XIV гасырга карый”[1].

Шулай ук, Коры Көрнәле ташъязмаларын өйрәнүдә зур эш башкаручылардан тарихчы, эпиграфист галим Һарун Йосыпов һәм тел галиме Фәрит Хәкимҗановны искә алу урынлы булыр. Һарун Йосыпов 1960 елларның беренче яртысында Коры Көрнәлегә килеп эпиграфик һәйкәлләрне өйрәнә, фотога төшерә. Экспедициясенең эш хисабы, фотоларның негативлары бүген Татарстан Фәннәр Академиясе Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге

[1] Казаков Е.П., Старостин П.Н., Халиков А.Н Археологические памятники Татарской АССР. - Казань. Татарское книжное издательство, 1987. – С. 74

фондларында саклана[1].

Югарыда әйтеп үтелгән галимнәрнең хезмәт тәҗрибәләре, ысуллары һәм эш нечкәлекләре турында да сүз әйтеп китәргә кирәктер. Аларның бу юнәлештәге эзләнүләре, иң беренче чиратта, шушы авылда яшәүче кешеләр белән әңгәмәләшүләрдән башланган, әлбәттә. Аңлашыла ки, алар тарафыннан табылган борынгы ташъязмаларга зур хөрмәт күрсәтелгән һәм мүкләрдән арындырганда да зур саклык белән эш алып барылган. Әгәр дә, таш үз авырлыгы белән җиргә күмелгән булса, эш барышында ул казып алынып әүвәлге торышына кайтарылган. Эпиграфик һәйкәлләрнең аскы өлеше чама белән утыз-сиксән сантиметр тирәнлеккә урнаштырылып, җир белән күмелгән булган. Мүкләнгән яисә гасырлар дәвамында "пычранган" ташларны ышкып-шомартып төрле таплардан тазарткannар. Кояш нурлары яктылыгында, бөтен язу-бизәкләре яхшы күренгән вакытта, фоторәсемгә төшерү чараларын күргәннәр.

Әлеге ташъязма истәлекләр 2017 елда Татарстан Фәннәр Академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты фәнни хезмәткәрләре Венер Усманов һәм Илһам Гомәровлар тарафыннан да өйрәнелделәр. Коры Көрнәледә булып үткән экспедиция барышында XIV гасырга караган ташъязмалар кабат барланды, аларның төгәл үлчәмнәре, фотолары алынды, координаталары билгеләндә, текстларының элеккеге укылышларына аерым бер төгәллекләр кертелде, график рәсемнәре – прорисовкалары эшләнде. Барлыгы XIV гасырның беренче чирегенә караган 5 таш, 2 датасыз һәм 1 XX гасыр башында Хөснелгата ибне мулла Фәтхеддин Ваһаповка куелган ташъязма исәпкә

[1] Татарстан Фәннәр Академиясе Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге. 72 фонд, 1 тасвирлама, 296 сакл. берәмл.

алынды.

Шунысын да искәртеп үтик, бу эпиграфик һәйкәлләр фәнни әдәбиятта Болгар чоры ташъязмалары дип бирелсә дә, сүз Алтын Урда дәүләтенең бер олысы булган Болгар иле турында бара. Шуңа күрә, әлеге кабер ташларын Болгар ташъязма культурасы традицияләрендә эшләнгән Алтын Урда чоры эпиграфик истәлекләре дип атау дөресрәк булыр дип уйлыйбыз.

Әлеге ташъязмаларның куелу шартларына килгәндә, төрле фикерләр бар. Аерым бер очракларда бу ташлар мондагы җирле халыкка түгел, узгынчы сугышчыларга куелган дигән фикерләр дә очраштыргалый. Әмма бу хакыйкатькә туры килми, чөнки, бердән, ташъязмаларның текстларында сугыш вакыйгаларына мөнәсәбәтле фактлар очрамый, терминнар кулланылмый; икенчедән, Болгар культурасына караган археологик ядкәрләрдән керамик чүлмәк ватыклары, иске акчалар һ.б. еш табылу бу урында Болгар шәһәрчеге яки зур бер авылы булганлыгы, ташларның шуңа мөнәсәбәтле икәнлеген ачык раслый.

Чынлыкта да тарихчылар һәм археологлар бүгенге Коры Көрнәле авылы урнашкан җирдә зур авыл яисә шәһәрчек булган дип фараз итәләр. Әлеге ташъязмалар анда әле монгол яуларыннан соң да кешеләр яшәве, аларның зират культурасының югары дәрәҗәдә булуы турында сөйли.

Бүген бу авылда мишәр кавеменнән булган татарлар яшәп көн күрә. Алар тарафыннан эпиграфик ядкярләргә карата зур хөрмәт күрсәтелә һәм шул ташларның күбесе тимер чардуганнар белән уратып алынган. Аңлашыла ки, Коры Көрнәле елгасының сул ягында тереклек итү өчен йорт биләмәләре булса, уң ягында элеккедән килгән гадәт буенча борынгы “мәңгелек йорт” - каберстан урнашкан булган.

Эпиграфик һәйкәлләрнең хәрефләре уеп чокып “бозык күфи” язуына охшаш язу рәвешендә башкарылган, текстлары ташларның ал ягында гына бар. Коры Көрнәле ядкярләрендә сөлес язуы күренмәде. Кайбер кабер ташларының “михраб” өлешендә алты яисә сигез таҗлы бадъян (кашкарый) чәчкәсе уеп ясалган.

Эш барышында ядкярләрнең төгәл кайда урнашу координаталары да күрсәтелеп барылды. Шулай ук Сәид Вахиди тарафыннан искәртелгән, әмма аннан соңгы галимнәр хезмәтләрендә күренмәгән бер ташъязма фрагменты да эзләп табылды һәм бу тарихи чыганаклар белән бергә фәнни әйләнешкә тәкъдим ителде.

Бу төбәктәге Алтын Урда дәвере эпиграфик һәйкәлләре нинди материалдан ясалган соң? Безнең көннәргә кадәр килеп җиткәннәренә нигезләнеп, еш очракта – известьташ, сирәк булса да, шушы ташның төрләреннән булган – мәрмәр ониксы һәм мәрмәр, шулай ук комташ кулланылган дип уйларга кирәк. Бу материлларның табигый цементы известьле яки балчыклы маддәләрдән булгандыр дип аңлашыла. Урта Идел буенда известьташ ятмаларының булуы, әлбәттә, “таш язу” сәнгатенең барлыкка килүенә һәм үсешенә зур йогынты ясаган. Еш очракта, ташлар Идел вә Чулман ярларындагы карьерлардан чыгарылган.

XIV гасырга караган борынгы ташлардан тыш Коры Көрнәле авылы зиратындагы тагын бер үзенчәлекле корылманың булуы игътибарга лаек. Бу – мөридләр нәселенә бәйле бер каберлек өстендә агачтан корылган һәм өйгә охшатып салынган төрбә – мавзолей. Димәк, татар дөньясында мавзолей-төрбәләрнең, таш вә кирпечтән башка, бүрәнәдән төзелгәннәре дә булган дип фаразларга нигез бар.

## Беренче ташъязма һәйкәл



Ташның язуы күренми диярлек. Ярты өлеше җир астында калган. Ул җирендәге язулары укылмый. Датасы юк.

*Үлчәмнәре:* Калынлыгы – 19 см; киңлеге – 38 см; биеклеге – 69 см.

*Координатасы:* N 55° 08. 809
E 50° 01. 759

*Гарәп язуындагы тексты:*

الحكم لله
العلى الكبير
...

*Транслитерация:*
Әл-хөкм лилләһи
әл-Гали әл-Кәбир
...

*Бүгенге татар теленә тәрҗемәсе:*
Хөкем бөек,
олуг Аллаһ [хөкемендә]
...

## Икенче ташъязма һәйкәл





*Үлчәмнәре:* 19 х 49 х 100 см.
*Координатасы:* N 55° 08. 815
E 50° 01. 746
*Гарәп язуындагы тексты:*

الحكم لله العلى الكبير
حاجى حسين آول حوُم
عُمَر بَلوُي كُ رحمَة الله
عَلَيه رَحمَةٌ وَاسِعَةٌ وَفا
تُ بَلطوُي ثَارِيخُ جِيَاتِ
جوُر جِيرم آلطِيِى جَال
صَفَر آيِ جِيرم آلطِيِى
كُوَان آتِ

*Транслитерация:*
Әл-хөкм лилләһи әл-Гали әл-Кәбир
Хаҗи Хөсәен улы хум
Гомәр бәләвике рәхмәтуллаһи
галәйһи рәхмәтән васигатән вафа-
т балтуй тарихү җийәти

жур жерем алтысы җал
сафәр айхы җерем алтысы
күән әте
*Бүгенге татар теленә тәрҗемәсе:*
Хөкем бөек, олуг Аллаһ [хөкемендә].
Хаҗи Хөсәен улы
Гомәр ташбилгесе. Аңа Аллаһының
киң рәхмәте ирешсен. Вафа-
т булды тарих җиде
йөз егерме алтынчы ел[1].
Сәфәр аеның егерме алтынчы
көне иде.

## Өченче ташъязма һәйкәл





*Үлчәмнәре:* 20 x 53 x 122 см.
*Координатасы:* N 55° 08. 817
E 50° 01. 742

[1] Текстта дата мөселман календаре – һиҗри ел исәбе белән бирелгән. Милади ел исәбе белән 1326 елның 9 февраленә туры килә.

*Гарәп язуындагы тексты:*

الحكم لله العلى الكبير
عثمآن اولِ عيسى زيار
ت ى رَحمَة الله عليه
رحمة وٓاسعة تاريخ
وفات جور جيارم توا
م جال ذولحجه
ايخ ون سكر كوان
ات

*Транслитерация:*
Әл-хөкм лилләһи әл-Гали әл-Кәбир
Госман улы Гайсә зыярә-
те рәхмәтуллаһи галәйһи
рәхмәтән васигатән тарих
вафат җур җиарем тәва-
м җал зөльхиҗә
аих ун сикер күән
әте
*Бүгенге татар теленә тәрҗемәсе:*
Хөкем бөек, олуг Аллаһ [хөкемендә].
Госман улы Гайсә зыярә-
те. Аңа Аллаһының
киң рәхмәте ирешсен. Вафат булу
тарихы җиде йөз егерме дүр-
тенче ел[1], зөльхиҗҗә аеның
унсигезенче көне
иде.

[1] Милади ел исәбе белән 1324 елның 14 декабре.

# Дүртенче ташъязма һәйкәл





*Үлчәмнәре:* 17 x 72 x 126 см.
*Координатасы:* N 55° 08. 838
E 50° 01. 742

*Гарәп язуындагы тексты:*

الحكم لله العلى الكبير
...
...
تاريخ [جِيَاتِ] ...
جوُر ...
...

*Транслитерация:*
Әл-хөкм лилләһи әл-Гали әл-Кәбир
...
...
тарих [җийәти]
җур ...

*Бүгенге татар теленә тәрҗемәсе:*
Хөкем бөек, олуг Аллаһ [хөкемендә].
...
...
тарих [җиде]
йөз ...

## Бишенче ташъязма һәйкәл



Бу ташның язуы юк.
*Үлчәмнәре:* 17 х 38 х 23 см.
*Координатасы:* N 55° 08. 654
E 50° 01. 985

## Алтынчы ташъязма һәйкәл



Ташның язуы юк.
*Үлчәмнәре:* 13 х 44 х 49 см.
*Координатасы:* N 55° 08. 911
E 50° 01. 697

# Җиденче ташъязма һәйкәл





Бу ташның өске өлеше генә сакланып калган. Типологик яктан алдагы 1324 һәм 1326 елларга караган ташлар белән охшаш. Язуы – чокып язылган матур куфи язуына якын. Башкаларыннан аермалы буларак, бу таш бүген зыйрәт эчендә саклана.

*Үлчәмнәре:* 20 x 42 x 50 см.

*Координатасы:* N 55° 08. 796

E 50° 01. 876

*Гарәп язуындагы тексты:*

هو الحى الذى لا يموت

...

*Транслитерация:*

Һуа әл-хәййү әлләзи лә йәмүт

...

*Бүгенге татар теленә тәрҗемәсе:*

Ул [Аллаһ] мәңге үлемсез

...

# Сигезенче ташъязма һәйкәл.









*Үлчәмнәре:* 12 x 28-34 x 120 см.
*Координатасы:* N 55° 08. 788
E 50° 01. 885

*Гарәп язуындагы тексты:*

معلّم
حسن العطا
ابن ملا فتح الدين
وها يف 58
ياشند ه 1338 سنه
شعبان 12 نده 1922 سنه
روميه ماى برنده
وفات رحمه الله
رحمة وَاسعة

*Транслитерация:*
Мөгаллим
Хөснелгата
ибне мулла Фәтхеддин
Ваһапов 58
яшендә 1338 сәнә
Шәгъбан 12 ндә 1922 сәнә
Румия май берендә
вафат рәхәмәһу Аллаһ
рәхмәтән васигатән

*Бүгенге татар теленә тәрҗемәсе:*
Мөгаллим
Хөснелгата,
мулла Фәтхеддин улы
Ваһапов. 58
яшендә, 1338 ел
шәгъбән аеның 12 ндә, милади белән
1922 елның беренче маенда
вафат. Аңа Аллаһының
киң рәхмәте ирешсен.

# Тугызынчы ташъязма һәйкәл



Таш табылмады. График рәсеме китаптан карап эшләнде. Югалган булу ихтималы зур.

*Гарәп язуындагы тексты:*

بسم الله العلى العظيم
1883 نچى [سنه]
وفات
مرحوم سعيد بن حميد
لا اله الا الله محمد الرسول الله

*Транслитерация:*
Бисмилләһи әл-Галие-л-Газыйм
1883 нче [сәнә]
вафат
мәрхүм Сәгыйд бине Хәмид
лә иләһә илләә Аллаһи Мөхәммәд әр-рәсүлаллаһи

*Бүгенге татар теленә тәрҗемәсе:*
Бөек һәм Олуг Аллаһының исеме белән.
1883 нче [елда]
вафат
мәрхүм Сәгыйд бине Хәмид
Аллаһыдан башка илаһи зат юк һәм Мөхәммәд аның илчесе.

### *Коры Көрнәле ташлары турында*
### *1928 елда С.Вахиди язганнардан*

Коры Көрнәле авылы фәкыйрь генә бер мөселман авылы, халкы мишәрчә сөйләшәләр. Көрнәле турында бу авылның картлары болай сөйлиләр: Безнең Коры Көрнәле авылы тирәсендә Шәһре Болгар заманасында бер авылмы, шәһәрме булган икән. Әнә безнең авылыбызның кырыенда булган кабер ташлары шул заманнан калган. Безнең басуыбызның бер җирендә бик күп чулман ташлары таралып яталар. Ул урыннан иске акчалар, элгәри тәңкәләр дә табыла. Бу акчаларның язулары мөселманча. Аннан башка бизәк әйберләре һәм хәнҗәр, ук очы кебек нәрсәләр дә табыла. Шуңардан ул урында борынгы заманда я шәһәр, я авыл булуын болай да уйлап белергә мөмкин диләр.

Әнә ул иске шәһәрме, авылмы, инде ул нинди сәбәп беләндер, беткән. Аның әсәре[1] булып кабер ташлары, чүлмәк ташлары, башка шундый иске әсәрләр генә калганнар. Шуннан соң күпме еллар үткәндер, бу урыннар тагын кап-кара калын урман булып киткәннәр. Казан шәһәрен урыслар алгач, безнең мөселманнарга авыр тормышлар башланган. Әнә шул чакта безнең Көрнәле бабай урысларның җәбер-золымыннан котылу уе белән Пенза ягыннан килеп, менә шушы урынга утырган да, шуннан соң үрчи-үрчи менә шушы безнең Көрнәле авылы килеп чыккан. Көрнәле ике авыл: берсе безнең авылыбыз – Коры Көрнәле – Сухой Курнали диләр. Икенчесе Юеш Көрнәле – Мокрый Курнали диеп йөртелә, диләр.

Коры Көрнәле авылы 1921 нче елның 7 нче маенда бөтенләй янып беткән. Бу янгында барлыгы бер йөз сиксән йорт янган. Картларның әйтүенә караганда, әнә шул янгында халык кулында булган бик күп кулъязмалар утта янып юкка

[1] Әсәре – эзе.

чыкканнар.

Бу авылда хосусый мосәхабә итәрлек[1] кеше дә булмады. Мосахәбәгә артык эш тә булмады.

Бу авылның картлары моннан утыз ел алда Гыйләҗетдин Фәйзрахман улында, язган бер тарих китабы барлыгын сөйләделәр. Хәтта бу тарих китабын укыган кешеләр дә әле исән икән. Алар бу китапта Казан, Болгар ханлыклары турында бик күп нәрсә язылганлыгы турында сөйлиләр. Шулай ук бу авылның картлары Шәһре Болгардан Биләргә барышлый Рәбига абыстайның кыз шәкертләре шул тирәдән үтеп йөри торган булганнар дип сөйлиләр.

Коры Көрнәледә борынгы каберстан һәм кабер ташлары

Коры Көрнәле авылының җәнүб ягында тау битендә борын заманнарда аерым иске каберстан булып, хәзер инде кайбер ташлар урамда, кайберләре ындыр артында, берәрсе хәзерендә дә үлекләр күмә торган каберстанда калган, бер каберлек булган. Коры Көрнәле авылының мулласы Габдеррахман Хәмзинның әйтүенә караганда, борын заманнарда бу каберстан зур бер мәйданны эченә алган чирәмлек булып, аның ташлары да күп санда булган. Хәзер инде каберстанның мәйданына урам корылып, йортлар эшләнгән, ташларның да байтагысы юкка чыккан инде, ди.

Бу ташларны урыннарына барып язуларын укып, зурлыкларын диккать илән тәфтиш иттем[2]. Ул ташлар турында тәртип белән монда язачакмын.

Беренче таш. Ташның зурлыгы: биеклеге – тугыз сөям, киңлеге – дүрт сөям, калынлыгы – дүрт вершок[3]. Бу таш Коры Көрнәле авылының урамында, рәшәткә эчендә тора, ләкин инде ташның язуы тәмам беткән.

---

[1] Мөсахәбә итәрлек – сөйләшерлек, әңгәмә корырлык.

[2] Тәфтиш иттем – тикшердем.

[3] Вершок – борынгы озынлык үлчәү берәмлеге. 1 вершок = 4,445 см.

*Икенче таш.* Ташның зурлыгы: биеклеге – җиде сөям, киңлеге – өч сөям, калынлыгы – биш вершок. Таш ак төстә булып, инде бер саргайган каты таш. Михрабында алты канатлы бадъян[1] бизәге бар. Язуы – хатты куфи[2], казылып язылган. Ташның язуы:

الحكم لله العلى الكبير
غشار آول محسن بلوي
مك رحمة الله عليه
رحمة واسعة تاريخ
حيات جور جيال توا
تم جال ذى الحجه
ايخ وز سكر كواز
ات

Ташның  язуы “ати” сүзе белән тәмам була. Әмма ташта язу беткәннән соңда җиде вершок буш урын калдырылган. Иске Рәҗәб авылында тарихы язылмаган бер ташта шундый язылмыйча калдырылган буш урын булганлыгын язып киткән идек. Бу ташта тарихы булдыгы хәлдә буш урын калган. Бу ташның беренче юлындагы сүзләрнең ас-өс (билгеләре) һәм нокталары беткән. Икенче юлының беренче сүзе “гашар” дип “гайн” – каты “гайн” (غ), “шин” – урта “шин”, ра – ялгыз “ра” хәрефләре белән язылган. Башка Болгар ташларының имляләрендә күренә торган кагыйдә буенча, бу ташның язуында да “йай” хәрефенең астында ике нокта, мәсьәлән “ي” шәкелендә, “ра” хәрефенең астында бер нокта, мәсьәлән “ر” кебек күзгә бәрелгән аерымлыклар бар. Өченче юлында беренче сүзе булып “мәк” (“مك”) дип укырга мөмкин булган бер билге языла. Моның турында инде бераз язып киткән идек, шуның өчен яңадан тукталып тормыйбыз. “Тарих” сүзенең соңгы хәрефе булган “ха”ның алдындагы “йай”

[1] Бадъян бизәге – кашкарый чәчәге бизәге.

[2] Хатты куфи – куфи язуы, стиле.

хәрефенең астына куелырга тиешле ике нокта астлы-өстле итеп (“:”) куелганнар.

*Өченче таш.* Ташның зурлыгы: биеклеге – алты сөям, киңлеге – унбер вершок, калынлыгы – дүрт вершок. Таш бераз саргайган. Башта ак төстә булган. Михрабында сигез канатлы бадьян бизәге. Язуы – казылып язылган хатты куфи.

الحكم لله العلى الكبير
حاجى حسين آول حاجي
عمر بلوي ك رحمة الله
عليه رحمة واسعة وفا
ت يلطويه تاريخ جيات
حور جير مر الطيم جال
صفر آيح جير مر الطشم
كوان آت

Өченче ташның язуы шуның белән тәмам була. Язулары тәмам булгач, ташның түбән тарафында биш вершок язылмый калган буш урыны бар. Таш урынында нык вә мәхкәм торган. Бозылган урыннары күренми. Таш каты, бераз саргайган. Тирәсендә бернәрсә дә юк, бөтенләй ачык бер мәйданда утыра. Бу ташны киртә белән тирәләп алырга Көрнәле агайларына әйтеп калдырдым. Тарихи әйберне саклау кирәклек хакында сөйләдем.

Кечкенә изах: ташның язуында “син” хәрефе астында өч нокта – “س” сурәтендә, “йай” хәрефе астында ике нокта – “ي” сурәтендә, “ра” хәрефенең астында бер нокта – “ر” сурәтендә языла. Байтак сүзнең хәрәкәсе куелган. “Гомер” сүзе белән “бәләуи” (сүзе) арасында хатты куфинең “кяф” хәрефе – “ک” рәвешендә бер билге куелган. Ташта барлыгы сигез юл язуы бар.

*Дүртенче таш.* Ташның зурлыгы: биеклеге – бер аршин[1], киңлеге – ярты аршин, калынлыгы – өч вершок.

الحكم لله
العلى الكبير
كل نفس ذائقة ا
لموت ثم اليناثر
حعور

Шуннан соң бу ташның язуы танылмый. Ташның кашкасында, ягъни иң югары михраб урынында кечкенә генә дүрт канатлы бадъян бизәге. Башка зур ташлардагы кебек, бу ташның даирәләндерелеп ясалган михраб өлеше юк. Таш кечкенә.

*Җиденче таш.* Бу таш бөтен түгел, бары михраб өлеше белән бер юл язуы гына калган. Ташның башка өлеше ватылып юкка чыккан. Михрабында даирә эчендә алты канатлы бадъян бизәге бар. Язуы:

هوَ الالحى الذي لا يموت

Моннан башка Коры Көрнәле авылының урамында бер таш ята. Бу ташны Нуретдин мулла Сәгыйэддин углы дигән кеше, шул урыннан кабер чыкканлыгыннан, кабер иясенә әҗре барып торсын өчен, авыл халкына, балта, пычак кебек нәрсәләрне чарлар өчен (ышкып үткенәйтү өчен), шул урынга китереп куйган иде, дип халык сөйләде. Вакыйган бу таш, кяшки[2], тегермән ташы.

Мәзкүр Көрнәле авылының хәзерендә мәетләрен дәфен итә торган каберстанында Рәхимкол бабаның өстенә куелган бер таш бар. Бу ташның язуы урыс истилясы соңындагы ташларда очрый торган тарызда[3] язылган. Ташның язуы:

---

[1] Аршин – борынгы озынлык үлчәү берәмлеге. 1 аршин = 71,2 см.

[2] Кяшки – мөгаен.

[3] Тарызда – формада, рәвештә.

بسم الله الرحمن الرحيم
قال الله تعالى كل من عليها
حان و يبقى وجه ربك ذو الجلال
و الاكرام تاريخ هجريه
1247 نجى يلدا ذالحجه نك
9 نجى يومنده رحيم قل بن سليمان
56 ياشنده دار الفنادان
دار البقايه رحلة قيلدى

1. Бисмилләһир-Рәхманир-рәхим
2. Калә Аллаһу Тәгалә көллү мән галәйһа
3. Фанин вә йәбка вәҗһү Раббикә Зөл-Җәлали
4. Вәл-икрами. Тарих һиҗрия
5. 1247 нче сәнә йылда зөлхиҗҗәнең
6. 9 нчы йәүмендә Рәхимкол бине Сөләйман
7. 56 яшендә дарелфәнадән
8. Дарелбәкая рихләт кылды, 1831

Бу ташның ике як кабыргасында, калкытыб сызылган сызыкның ике ягына дәхый озын юл итеп язу язылган: *“Әнбияләр әүлияләр тормады ай әмал / Кичде Адәм һәм Мөхәммәд әнбияләр бит-тәмам”*.

Менә бу кадәр язу ташының кабыргасының беренче юлында. Икенче юлы ачык танылмаганлыгыннан язып алмадым. Ул юлның да мәфһүме[1] беренче юлының мәфһүме белән бер үк.

Авылдан ике чакырым шәрекъ ягында, Казанчы дип йөртелә торган елга буйларында һәр төрле мөселманча язылуы иске акчалар вә башка шундый тарихи әйберләр табылып килгәнлеген миңа хәбәр иттеләр. Риваятьләргә караганда, мона бу ташларның хуҗалары яшәгән кечкенә бер болгар шәһәре шушы иске акчалар табыла торган җирдә булган имеш.

Июньнең унтугызында өйләдә соң Коры Көрнәле авылыннан, Көеккә кайтып киттек.

[1] Мәфһүме – мәгънәсе.

# Коры Көрнәле мәхәлләләре һәм мәчетләре тарихы

Татар авыллары тарихында үзәк урыннарның берсен авыл мәчетләре, аның мәхәллә тарихлары биләп тора. Бу Казан губернасы Спасс өязе Левашев волосте (аңа кадәр Коры Көрнәле, Олы Тигәнәле волостьләре) Коры Көрнәле авылы елъязмасы мисалында да ачык күренә.

Коры Көрнәле авылы мәчетләре һәм мәхәлләләре тарихы рәсми рәвештә XVIII гасыр азагында, ягъни Оренбург Мөселман Диния Нәзарәте оешкач теркәлә башлый. Әмма бу факт әлеге авылда аңа кадәр мәчет булмаган дигән сүз түгел. Инде XVIII гасыр азагында Коры Көрнәледә өч зур мәхәлләнең яшәп килүе, аңа кадәр берничә йөз ел дәвамында ук биредә мәчет булуы турында сөйләргә мөмкинлек тудыра. Рус елъязмаларындагы аерым бер чыганакларда Коры Көрнәле (авылның исеме Каурляне дип күрсәтелгән) мәчетенең якынча 1685 нче еллар тирәсендә салынуы хакында мәгълүматлар бар.

1788 елның 22 сентябрендә Россия патшабикәсе Екатерина II фәрманы белән Оренбург Мөселман Диния Нәзарәте оешканнан соң мөселманнарның тормышы, руханыйларның эшчәнлеге белән бәйле хезмәтләр барысы да диярлек әлеге оешма аша башкарыла, аның тарафыннан җитәкчелек ителә, рәсми документларның төп нөсхәләре шунда теркәлә башлый. Бигрәк тә илдә Николай I идарә иткән һәм бюрократик традицияләр көчәйгән чорда язмалар тәфсилле рәвештә тутырыла, исәпкә алына башлыйлар. Алар бүген төрле архивларда, шул исәптән, Татарстан Республикасы Милли архивы фондларында да саклана. Әлеге төр чыганаклар арасында Коры Көрнәле мәчетләре һәм мәхәлләләре тарихының XVIII йөз азагы – XX йөз

башы дәверенә караганнары да байтак[1]. Аларга нигезләнеп, Коры Көрнәле мәчетләре елъязмасын, авыл халкының рухи тормышын, мулла һәм мөдәррисләренең эшчәнлеген тулырак күзалларга, биредәге мөселман җәмгыятенең үсеш һәм үзгәреш баскычларын төгәлрәк ачыкларга мөмкин.

Шунысын да искәртү урынлы булыр: узган гасырлар дәвамында Коры Көрнәле авылында берничә тапкыр көчле янгыннар булып уза. 1865, 1883, 1885, 1904, 1907, 1921 еллардагы янгын фаҗигаләре турында мәгълүматлар бар. Шулардан 1883 елгы пожар вакытында авылның ике мәчете дә янып көлгә кала. Коры Көрнәлегә 1927 елда археографик һәм эпиграфик экспедициягә килгән татар галиме Сәет Вахиди үзенең көндәлекләренә авыл турында болай дип теркәп куйган: “Коры Көрнәле авылы 1921 нче елның 7 нче маенда бөтенләй янып беткән. Бу янгында барлыгы бер йөз шиксән йорт янган. Картларның әйтүенә караганда, әнә шул янгында халык кулында булган бик күп кулъязмалар утта янып юкка чыкканнар”[2]. Чыганаклардан күренгәнчә, көрнәлелеләр бу мәчетләрне янәдән торгыза, аларны салырга рәсми рөхсәт алу юлындагы каршылыкларны җиңә-җиңә яңасын төзи.

Югарыда искәртелгәнчә, Коры Көрнәле мөселман җәмәгатьчелеге Октябрь инкыйлабына кадәр өч мәхәлләгә бүленеп тормыш иткән. Бу исә авылның көчле, халкының күп булуы турында сөйли. Патша Россиясе Эчке Эшләр Министрыгының Үзәк статистика Комитеты исәпкә алган мәгълүматларга караганда, 1859 елда Ногай юлының сул ягында урнашкан Коры Көрнәле авылында 3 мәчет булган, 214 хуҗалыкта барлыгы 1366 кеше яшәгән. Шуларның 702-се

[1] Татарстан Республикасы Дәүләт Архивы. 2 нче фонд, 2 нче тасвирлама, 1729, 2863, 2864, 3230, 3599, 6462, 7931, 8359, 8482, 8588, 9013, 9829, 10581, 10713 нче саклану берәмлекләре

[2] Татарстан Фәннәр академиясе Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге. 53 нче фонд, 1 нче тасвирлама, 58 нче саклау берәмлеге.

хатын-кызлар, 664-е ир-егетләр[1]. Мәчетләр һәм мәхәлләләр рәсми кәгазьләрдә тәртип саны белән аталсалар да, географик яктан урнашуларына карап, халык арасында Тау башы мәчете Урталык мәчете, Яңа рәт мәчете дип йөртелгәннәр. Мөселман авылы икәнлеге ерактан ук беленеп торсын дип, бабайлар мәчетләрне авылның уртасынарак яки калку урынга салу җаен караганнар, янган очракта да мәчет урынын изге санап, аны үзгәртмәскә тырышканнар.

Алга таба әлеге мәхәлләләр һәм мәчетләр тарихына аерым тукталып үтик.

### *Беренче мәхәллә*

Авылда берничә мәчет һәм мәхәллә булган очракта, гадәттә, аның борынгырагы беренче номер белән билгеләнгән. Коры Көрнәле авылы мисалында да шулай ук дип уйларга нигез бар.

Беренче мәхәллә мәчетенең агач бинасы искереп, дини йолаларны үти алмаслык хәлгә килгәннән соң, 1857 елда аны яңартып салалар. Алга таба ул берничә тапкыр яна (1883, 1904 еллар) һәм 1885 елда рөхсәтсез генә, 1908 елда рәсми рәвештә рөхсәт алып яңадан торгызыла. 1904 елда янганнан соң мәхәллә халкы өч ел дәвамында намазларын мәчет каршындагы мәктәптә укый, дини бәйрәмнәрне дә шунда уздырырга мәҗбүр була. 1907 елның 7 октябрендә узган Коры Көрнәле авылы җыенында янган мәчет урынына яңасын төзү турында карар кабул итеlә. Шунда ук әлеге мәсьәлә буенча губернаторга мөрәҗәгать итү, төзелешкә рөхсәт алу эшләрен

[1] Списки населенных мест Российской империи, составленные и издаваемые Центральным статистическим комитетом Министерства внутренних дел. Т. XIV. Казанская губерния. Список населенных мест по сведениям 1859 года / издан Центральным статистическим комитетом Министерства внутренних дел; обработан старшим редактором А.И. Артемьевым. – СПб.: в типографии Карла Вульфа, 1866. – LXXIX. - С. 90

башкару өчен үз араларыннан Авзалетдин Төхфәтуллин исемле кешене вәкил итеп билгелиләр. Алдагы елда бу карар губернатор тарафыннан расланып, беренче мәхәллә мәчете яңадан төзелә.

Статистик мәгълүматларга караганда, беренче мәхәлләдә 1885 тән алып 1913 елга кадәр ир-ат мөселманнарның саны арта баруы күзәтелә. 1885 елда барлыгы 202 ир кеше булса, 1907 елда аларның саны 293 кә, 1913 елда 388 гә җитә. Бу Октябрь инкыйлабына кадәр әлеге мәхәлләнең зурая һәм көчәя баруы турында сөйли. Биредә муллалар тарафыннан мөселманнарның туу, үлү һәм никяхлану фактларын теркәгән рәсми документлар – метрика кенәгәләре 1833 елдан алып барыла башлаганнар.

Беренче мәчеттә исемнәре безгә мәгълүм булган имам һәм мөгаллимнәрдән иң әүвәлгесе – Габдеррәхим Сөләйман улы (Габдеррәхим Сөләйманов). Ул бу мәхәлләдә 1825 елның 3 июнь көненнән алып имамлык итә башлый.

Мәхәлләнең икенче мулласы – Габдеррәхим хәзрәтнең улы Сафиулла Сөләйманов. Архив кәгазьләренә караганда, ул 1833 елда дөньяга килә, Оры Шәриф (бүген Арча районына керүче Түбән Оры авылы булса кирәк) авылының Сибгатулла хәзрәт хозурында гыйлем туплый. Мәхәллә халкы аны 1862 елның 14 августында әлеге мәчетнең икенче мулласы итеп билгеләп куя. Берникадәр вакыттан соң атасы урынына имам була. Вафаты – 1912 елның 13 январендә. Шул рәвешчә, беренче мәхәлләдә 87 ел дәвамында аталыуллы Сөләймановлар имамлык итәләр.

Мәчетнең азанчысы булып Мөхәмматгәрәй Хөсәенов хезмәт куя. Әмма ул өченче мәчеткә мөәззин булып киткәч, мәхәллә халкы аның урынына Чистай өязе Иске Җирекле (бүген Тукай районына керә) кешесе, 1833 елның 2 ноябрендә туган Минһаҗетдин Гыйләҗетдин улы Сираҗетдиновны

билгеләүне сорап, Губерна Идарәсенә мөрәҗәгать юллый. Әлбәттә, көче ташып торган, Әлмәт авылында мәшһүр ишан Гобәйдулла Кизләвинең оныгы Хәйрулла Ишан хәзрәтләрендә белем алган бу яшь егетнең яхшы азанчы булачагына берәүнең дә шиге булмый. Әмма Губерна Идарәсендә башкача хәл итәләр: карар мәхәллә җыены кагыйдәләрен бозып кабул ителгән – җыенда катнашкан һәм тавыш бирү хокукына ия кешеләрнең саны мәхәлләдәге хуҗалык санының 2/3 өлешен тәшкил итми дигән сәбәп белән кире кагыла. Чынлыкта да, бу җыенда беренче мәхәлләгә караган 95 хуҗалыктан 55 кеше генә катнашкан була. Шуңа күрә, берникадәр вакыттан соң, әлеге мәсьәлә буенча кабат җыен ясала һәм анда 80 нән артык кеше катнашып приговор кабул итә. Ул Губерна Идарәсендә раслана, ә Минһаҗеддин Гыйләҗетдин улы 1887 елның 31 мартында Оренбург Мөселман Диния Нәзарәте каршында мөәззинлеккә имтихан тота һәм беренче мәчеткә азанчы, мөгаллим итеп тәгаенләнә.

Минһаҗетдин Гыйләҗетдин улының тормышында моңа охшаш вакыйга тагын да була. Инде Сафиулла хәзрәтнең сәламәтлеге какшап, имамлык кылуы авырая башлагач, 1904 елда Минһаҗетдинне аңа ярдәмгә икенче мулла итеп билгеләп куялар. Тора-бара мәхәлләнең имам башкара торган бар эшләре аның җилкәсенә төшә башлый. 1912 елда өлкән мулла бакыйлыкка күчә, Минһаҗетдин хәзрәт мәхәлләдә бердән-бер руханый булып кала. Шул вакытта мәхәллә картлары аны үзләренә имам-хатыйп итеп билгеләүне сорап, Губерна Идарәсенә мөрәҗәгать итәләр. Әмма үтенеч кире кагыла, Минһаҗетдин Гыйләҗетдин улына имам-хатыйп дәрәҗәсе бирелми.

Аңа да карамастан Минһаҗетдин хәзрәт намус белән халыкка хезмәт итүен дәвам итә. Мөселманнарның дини һәм рухи мәнфәгатьләрен канәгатьләндерү белән бергә, мәчет

каршындагы аерым бинада урнашкан мәктәптә иллегә якын шәкерт тәрбияли. Хатыны Фәхрибану абыстай да Коры Көрнәле авылының 38 кызына белем бирә.

Минһаҗетдин Гыйләҗетдин улы Сираҗетдиновның Октябрь инкыйлабыннан соң да муллалык итүе турында мәгълүматлар булса да, кызганыч ки, алдагы язмышы безгә мәгълүм түгел.

### *Икенче мәхәллә*

Икенче мәхәлләнең агач мәчетенә 1840 елда нигез салына. Ул да, беренче мәхәллә мәчете кебек үк, берничә тапкыр янгыннар тарафыннан юк ителә һәм кабаттан торгызыла. Әйтик, 1865 елда янып бетә, 1868 елның 24 апрелендә Губерна Идарәсе яңаны салырга рөхсәт бирә. 1883, 1907 елгы пожарлар вакытында тагын яна. 1885, 1909 елларда аны яңадан төзиләр.

Кешеләр саны буенча әлеге мәхәллә калганнары белән чагыштырганда иң зурысы саналган. Биредә 1915 елда барлыгы 991 кеше (шуларның 507 се – ир-ат, 484 – хатын-кыз), 1916 елда 983 кеше (514 ир-ат, 469 хатын-кыз) исәпкә алынган. Мәхәлләнең метрика дәфтәрләре 1829 елдан тутырыла башлаган.

XIX гасырның I яртысында бу мәчеттә Хисаметдин Салихов исемле кеше имам булып тора. Ул Диния Нәзарәтеннән 1826 елның 22 гыйнварендә указ ала. Алга таба гыйлеме, кылган гамәлләре белән мөселманнар арасында дан һәм шөһрәт казанып, мөхтәсиб дәрәҗәсенә ирешә.

Икенче мәхәлләнең мөәззине – Коры Көрнәле кешесе Бәшир Әббазовның (1780-1845) улы Әхмәтша Бәширов. Ул 1842 елның 30 маеннан башлап, Хисаметдин хәзрәт белән бергә, озак еллар дәвамында авыл мөселманнарына хезмәт күрсәтә. Сүз уңаеннан шунысын да әйтик, Әхмәтша Бәширов

– әлеге китапны дөньяга чыгаруга зур көч куйган Зиннур Закир улы Бәшировның дүртенче буын нәселдәше.

Хисаметдин хәзрәт олыгаеп, мәчет эшләрен башкару авырая башлагач, мәхәллә халкы аңа ярдәмгә дип төп чыгышы Лаеш өязе Юеш Көрнәле авылыннан булган Нуретдин Сәйфетдин улы Хәмзинны билгеләп куя. Ул Диния Нәзарәте каршында имтихан тотып, 1870 елның 16 сентябрендә рәсми рәвештә икенче мәчетнең имам-хатыйбы, мөгаллиме итеп тәгаенләнә һәм 1916 елга кадәр шул урында хезмәт куя.

Нуретдин муллага алмашка аның улы Хафиз Хәмзин килә. Ул Казанда “Госмания” мәдрәсәсен (1894-1901 еллар), Рус-татар укытучылар мәктәбен (1901-1904 еллар) тәмамлый, мәсләктәшләре һәм авылдашлары арасында үз чорының алдынгы карашлы кешесе буларак таныла. Хафиз Сәйфетдин улы  1916 елның 31 июлендә Диния Нәзарәте каршында имам-хатыйп һәм мөгаллимлеккә имтихан тапшыра, әмма бу эшкә керешә алмый, армиягә карала.

Коры Көрнәле халкына Хафиз Хәмзин башка яктан да яхшы таныш шәхес. Ул – шагыйрь Һади Такташның беренче хатыны, утызынчы елларда Үзбәкстан Юстиция Халык комиссары булып торган Гөлчәһрә Хәмзина һәм язучы Касыйм Хәмзинның этисе. Биредә Гөлчәһрәгә бәйле бер вакыйганы сөйләп үтү дә урынлы булыр. Егерменче елларда кыз Мәскәүдә юридик институтта укыганда, аны мулла кызы булуда гаепләп, уку йортыннан куарга җыеналар. Шул вакытта Һади Такташ һәм Гөлчәһрә төрле рәсми кәгазьләр юнәтеп, этисенең “мулла түгел”леген дәлилләүгә ирешәләр. Эшнең ни рәвешле булуын ачыклавы хәзер инде мөмкин түгел диярлек, әмма ничек кенә булмасын, Хафиз Хәмзинның үз вакытында аздан гына муллалыкка рәсми рәвештә билгеләнми калуы кызының киләчәк язмышында хәлиткеч роль уйнамагандыр дип әйтүе кыен.

Татар дөньясына шундый күренекле шәхесләр тәрбияләгән бу могътәбәр затның Октябрь революциясеннән соңгы язмышы бөтенләй диярлек мәгълүм түгел. Бары тик 1940 елларда Ташкент шәһәрендә бакыйлыкка күчүе һәм шунда ук җирләнүе билгеле.

Икенче мәхәлләдә мөәззин Әхмәтша Бәширов үлгәннән соң, азанчы вазифаларын үтәү Мөхәммәдгәрәй Хөсәен улы Бакировка йөкләнә. Ул Коры Көрнәле авылында 1862 елның 15 мартында дөньяга килә, Урта Тигәнәле мәдрәсәсендә мулла Шәмселвәли Бикбулат углы хозурында дини гыйлемнәргә өйрәнә. 1884 елның 31 октябрендә указ ала һәм мәчеттә хезмәт итә башлый. Мөхәммәдгәрәй Бакиров русча әйбәт кенә укый-яза белүе белән бергә, кешене яхшы тануы, башлаган эшен азагына кадәр җиткерә алуы, максатчанлыгы белән аерылып торган күрәсең, 1908 елда яңа мәчет салу өчен рөхсәт алу эшләрен мәхәллә халкы аңа йөкли, аны Казанга юллый. Бу юлда аңа шактый гына кыенлыклар да күрергә туры килә, чөнки Казан Губерна Идарәсенең төзелеш бүлеге, булачак мәчетнең урыны йортларга якын дип, озак кына вакыт рөхсәт бирми тора. Әмма Мөхәммәдгәрәй Бакиров бу киртәләрне үтеп, 1909 елда мәчет төзелешенә рөхсәт алуга ирешә.

Икенче мәхәлләдә балаларга белем бирү юнәлешендә дә эзлекле рәвештә эш алып барылган. Биредә озак еллар дәвамында аерым бинада мәктәп-мәдрәсә эшләп килә. Сиксәннән артык ир бала мәктәп укытучысы Хөснелгата Фәхретдин улы Ваһаповтан дини һәм дөньяви гыйлемнәргә өйрәнә. Кыз балаларга аң-белем бирү белән Сәгъдия абыстай – алдарак искә алынган имам-хатыйп Нуретдин Хәмзин кызы шөгыльләнә.

### *Өченче мәхәллә*

Өченче мәхәллә башкалары белән чагыштырганда яңарак оешкан санала. Аның агач мәчете 1835 елда салынган булган. Шулай ук берничә тапкыр януга (1885, 1908 елларда) дучар була. 1886, 1908 елларда кабат торгызыла.

1905 елда өченче мәхәлләдә барлыгы 516 кеше (264 ир-ат, 252 хатын-кыз), 1915 елда 630 кеше (321 ир-ат, 309 хатын-кыз), 1916 елда 130 йортта 640 кеше (322 ир-ат, 318 хатын-кыз) исәпкә алынган. Бу мәхәлләдә метрика дәфтәрләре 1852 елдан алып барыла башлый.

Өченче мәхәллә мәчетенең имамы Сәгъдетдин Сәйфетдин улы (Сәйфетдинов) Диния Нәзарәтеннән 1869 елның 26 ноябрендә муллалыкка указ ала. Спасс өязе Полиция Идарәсенең 1897 нче елгы кәгазьләренә караганда, ул халык санын исәпкә алуга каршы оешкан баш күтәрүләрдә катнашкан дигән сәбәп белән, Казан Губерна Идарәсе тарафыннан муллалыктан алына, имамлыкка указыннан мәхрүм ителә.

Эш шунда ки, патша Россиясендә халык санын исәпкә алулар ким дигән егерме елга бер тапкыр уздырыла торган була. Бу эшләр гасырлар дәвамында дәүләтнең көчләп чукындыру сәясәте, милли-дини изүе астында яшәгән татар мөселманнары арасында шик-шөбһә уята, фетнә-чуалышлар килеп чыгуга сәбәп булган. Шундый чуалышларның берсе 1897 елгы халык санын исәпкә алу барышында Спасс өязендә булып уза. Архив документларыннан күренгәнчә, әлеге хәлләрдән соң Полиция Идарәсе муллаларның бу фетнәләрдә катнашу-катнашмавы турында мәгълүматлар җыя башлый, гаеплеләрне ачыклап җәзага тарту юлына баса. Коры Көрнәле мулласы Сәгъдетдин хәзрәт шундый язмышка дучар була. Ул Казан Губерна Идарәсе карары белән килешмичә, Эчке Эшләр Министрлыгына һәм Сенатка мөрәҗәгатьләр юлласа

да, теләгенә ирешә алмый, әлеге карар үз көчендә кала.

Бу вакыйгадан соң мәхәллә халкы мәчетнең имам-хатыйбы итеп 1870 елның 26 мартында Лаеш өязе Имәнкискә авылында туган Шакир Гарифуллинны билгеләп куя. Ул Цивильск шәһәр училещесенең рус классын тәмамлый, Диния Нәзарәте каршында имам-хатыйп һәм мөгаллим дәрәҗәсен алу өчен уңышлы рәвештә имтихан тота һәм Казан Губерна Идарәсенең 1899 ел, 24 июнь карары белән өченче мәчеткә тәгаенләнә. Шакир Гарифуллин биредә ун ел дәвамында муллалык итә дә, соңыннан Лаеш өязе Олы Елга авылының икенче җәмигъ мәчетенә имам булып күченеп китә.

1909 елның 22 июлендә өченче мәхәлләнең имам-хатыйбы итеп Коры Көрнәле кешесе Габделхәмит Габит улы Барышев (1864 елның 21 ноябрендә туган) билгеләнә. Ул Казан шәһәренең 4 нче мәчете – Зәңгәр мәчет мәдрәсәсендә мулла һәм мөдәррис Ибраһим Закир улы Хәмитовта белем ала. Шул ук чорда Апанай мәчете каршында эшләп килгән рус классында укый, аны 1895 елда уңышлы тәмамлый. 1909 елның 25 июнендә Диния Нәзарәте каршында имам-хатыйп һәм мөгаллимлеккә имтихан тапшыра.

Габделхәмит Габит улы Барышев – фаҗигале язмышка ия шәхес. Советлар власте егерменче-утызынчы елларда илкүләмендә “антисовет элементлары” дип, руханый катлам вәкилләренә каршы репрессия чаралары башлагач, террор сәясәте Габделхәмит Габит улы шәхесен дә читләтеп үтми. Ул 1930 елда кулга алына һәм НКВД “өчлеге” карары белән үлем җәзасына хөкем ителә. Соңыннан үлем җәзасы 10 елга ирегеннән мәхрүм итү, мал-мөлкәтен конфискацияләп, туган-тумачасын сөргенгә сөрү белән алыштырыла. Габделхәмит Габит улы Барышевнең гаепсез исеме 1989 елның 27 июлендә аклана.

Өченче мәхәллә мәчетендә төрле елларда мөәззин булып эшләгән кешеләрдән Мөхәммәтгәрәй Хөсәенов һәм Гомәр

Сәйфетдинов исемнәрен атап үтәргә мөмкин. Мөхәммәтгәрәй Хөсәенов (1862 елның 12 октябрендә туа) мәчеткә рәсми рәвештә азанчы итеп 1884 елның 25 октябрендә куела. Ул 1888 елда үз теләге белән икенче мәчеткә шул ук хезмәткә күчә. Аннан соң азанчы вазифаларын Гомәр Сәйфетдинов үти башлый.

Бу мәхәлләнең шулай ук үз мәктәбе була. XX гасыр башында 35 шәкерткә Габделхәмит Барышевнең улы, 40 тан артык кыз балага Сәгъдетдин Сәйфетдиновның җәмәгате – Мәсрүрә абыстай белем бирә.

* * *

Коры Көрнәле авылының өч мәхәлләсе буенча мәгълүматларны карагач, аларның әхлакый яктан ныклы нигезгә корылганлыгы, Көрнәле халкының үз дини хокуклары өчен һәрдаим көрәшеп яшәүләре, ут-су китергән табигать казаларын мөэмин-мөселман өстенә төшкән дөньяви сынаулар рәвешендә кабул итеп, авырлыклар алдында сынмыйча-сыгылмыйча яши бирүләре ачык күренә. Өч мәхәлләдә дә аерым мәктәп-мәдрәсәләр эшләп килү, аларны тәмамлаган шәкертләрнең алга таба үз чорының күренекле имам һәм мөдәррисләрендә белем алулары, бу төбәктә дини һәм дөньяви белем бирүнең ныклы нигезләре булуы турында сөйли. Мәхәллә халкының һәрвакытта да авыл тормышының әхлакый яктан саф булуын кайгыртып яшәвен күрсәтә.

Әлбәттә, мәхәлләләрдә ничәмә-ничә гасырлар дәвамында барган вакыйгаларны барлап бетерү мөмкин эш тә түгел. Шуңа күрә, аларның кайберләрен тасвирлаган документлар белән танышуны китап укучының үз хозурына калдыру дөрес булыр.

# Беренче мәхәллә тарихына караган документлар
# 1 нче документ

***Приговор***

1907 года, Октября 7 дня, мы, нижеподписавшиеся крестьяне Казанской губернии, Спасского уезда, Левашевской волости Сухо-Курналинского сельского общества, состоящего из селения д. Сухих Курналей числящиеся в 604 ревизских мужского пола душах и живущие в 296 домах, быв на сельском сходе в числе 186 человек, из числа домохозяев, имеющих право голоса на сходе, в присутствии нашего Сельского Старосты Хайруллы Меняфова, где имели суждение о том, что нам необходимо построить мечеть для 1-го прихода в замен сгоревшей 3 года тому назад, так как прихожане этого прихода лишившись мечети ведут Богослужение в школе, что мы находим крайне неудобным, по обсуждении сего мы единогласно постановили: избрать из среды односельчан крестьянина Абзялетдина Тохватуллина, которого уполномачиваем ходатайствовать о разрешении приходу произвести постройку новой мечети. В том подписуемся:

1. Исмагил Исхаков
2. Сайфутдин Хисамутдинов
3. Усман Сайфутдинов
4. Фатхутдин Гайнутдинов
5. Нургали Гайнутдинов
6. Зайнулла Насибуллин
7. Нигметзян Вахапов
8. Сафиулла Тухватуллин
9. Гиниятулла Нигматуллин
10. Шарафутдин Фаткуллин
11. Хисматулла Атауллин
12. Миндубай Нигматуллин
13. Шигабуддин Гайнутдинов
14. Мулюк Вахапов
15. Самигулла Гиниятуллин
16. Шайхутдин Сайфутдинов
17. Миргазиз Хайруллин
18. Зяшахей Галимов
19. Шайхутдин Хисамутдинов
20. Гилязетдин Курманчиев
21. Кабир Зяббаров
22. Хисиятулла Нигматуллин
23. Фатхутдин Хисматуллин
24. Гайфулла Гиззятуллин
25. Хасан Ахсанов
26. Нурутдин Карабашев
27. Фатхутдин Карабашев
28. Сибатулла Сайфутдинов
29. Адиулла Валиуллин
30. Залялетдин Карабашев

31. Давлетша Миндубаев
32. Гирей Галиев
33. Шайхутдин Мухутдинов
34. Галиулла Гиззатуллин
35. Ганиулла Валиуллин
36. Мияссар Галимов
37. Гимадый Фаизов
38. Хисмятулла Рязяпов
39. Валиулла Хусаинов
40. Галим Рахимов
41. Хуснулла Хусаинов
42. Минникей Рахимов
43. Галиулла Хусаинов
44. Сайфулла Хуснутдинов
45. Нургалей Галиев
46. Зябир Вахидов
47. Аглиулла Сайфутдинов
48. Зяббар Хакимов
49. Шакур Мазитов
50. Хузя Вильданов
51. Исхак Хамзин
52. Халимулла Сайфутдинов
53. Сафиулла Зяббаров
54. Маннап Зяббаров
55. Ханяфей Зарифов
56. Ахметсафа Гайнутдинов
57. Хафиз Камалитдинов
58. Гата Шамсетдинов
59. Хайрулла Сабитов
60. Садик Сагитов
61. Ахметша Мухаметзянов
62. Зиганша Мухаметзянов
63. Хасанша Валитов
64. Фахурдин Фаткуллин
65. Нурутдин Шамсутдинов
66. Шигай Сягдиев
67. Хуснулла Сибуханкулов
68. Гафиятулла Гайнуллин
69. Хамидулла Сайфутдинов
70. Мазип Зяббаров
71. Исмагил Шарипов
72. Зайдулла Зяббаров
73. Мумин Сайфутдинов
74. Гилязетдин Камалитдинов
75. Сафаргалей Сайфутдинов
76. Нургалей Сайфутдинов
77. Шарафутдин Мухутдинов
78. Ильяс Насыров
79. Сибатулла Абдурахимов
80. Нурутдин Зиганшин
81. Хафиз Зиганшин
82. Гиниятулла Ахметшин
83. Абдуррахман Хусаинов
84. Шайдулла Ахметшин
85. Асадулла Ахметшин
86. Гиниятулла Валиуллин
87. Гайфулла Гайнуллин
88. Шайхутдин Фатхутдинов
89. Гимазитдин Камалитдинов
90. Юсуп Валитов
91. Залялитдин Шамсутдинов
92. Хаким Зяббаров
93. Кашаф Шавалеев
94. Гайнулла Нигматуллин
95. Назметдин Шамсутдинов
96. Галим Мрясов
97. Хуснутдин Шамсутдинов
98. Мисбах Шамсутдинов
99. Ахметша Казаков
100. Асадулла Хабибуллин
101. Фахуртдин Хасанов
102. Гиниятулла Гафиятуллин
103. Шайхутдин В.....ий (?)
104. Сыдык Сафиуллин
105. Ибрай Фахурдинов
106. Юсуп Галимов
107. Галим Кабиров
108. Мумин Хакимов

109. Зямалей Мифтахутдинов
110. Мифтахутдин Хасанов
111. Хусаин Хасанов
112. Хатип Сафиуллин
113. Галей Сафиуллин
114. Валей Хамзин
115. Хайрулла Гибадуллин
116. Ахметсафа Шамсутдинов
117. Сафа Шамсутдинов
118. Юсуп Гиниятуллин
119. Гайнутдин Хисамутдинов
120. Галей Вафин
121. Гильмутдин Миняфов
122. Кабир Вахитов
123. Садык Нафигов
124. Ярулла Хайрушин
125. Фатих Гумеров
126. Камалитдин Миняфов
127. Зайдулла Атауллин
128. Сибатулла Хабибуллин
129. Исхак Фаткуллин
130. Ибрай Фаткуллин
131. Салахутдин Шамсутдинов
132. Гильмутдин Хисамутдинов
133. Идиятулла Насибуллин
134. Хайрулла Хайбуллин
135. Хайрутдин Ахметов
136. Залялетдин Хисамутдинов
137. Хамидулла Зяббаров
138. Шарафутдин Хисамутдинов
139. Ибрай Шарипов
140. Ахмет Иксанов
141. Хусаин Миняфов
142. Исмагил Галимов
143. Ибрай Галимов
144. Абдулганей Зяббаров
145. Габит Хамитов
146. Сафа Шарипов
147. Валиахмет Вильданов
148. Гата Шарипов
149. Мухамметзян Нугуманов
150. Зариф Мухамедрахимов
151. Хафиз Габитов
152. Исмагил Файзутднов
153. Хасан Валитов
154. Юсуп Вафин
155. Галей Сайфутдинов
156. Садык Мусин
157. Гатиятулла Габбязов
158. Хузя Багаутдинов
159. Зариф Габитов
160. Насретдин Мирзияпов
161. Залей Рахматуллин
162. Вагиз Мусин
163. Нигматулла Хабибуллин
164. Мазидулла Шайхуллин
165. Мансур Хайруллин
166. Киям Шамсутдинов
167. Набиулла Сафиуллин
168. Хусаин Хасанов
169. Шахалей Зиганшин
170. Гильман Ризванов
171. Юсуп Сатдаров
172. Гата Хамзин
173. Исмагил Хамзин
174. Шайдулла Зяббаров
175. Замалей Фаизов
176. Якуп Ибрагимов
177. Каюм Кабиров
178. Хуснутдин Шамсутдинов
179. Ярулла Калимуллин
180. Сафиулла Калимуллин
181. Шамсутдин Ахметов
182. Мингач Фахурдинов
183. Юнус Ахметов
184. Фатых Набиуллин
185. Хайрулла Миняфов (староста)
186. Хасан Хакимов

Настоящий приговор к свидетельству в Левашевском волостном правлении Спасского уезда явлен что и удостоверяется подписом с приложением печати. 1907 года Октября 11 дня. Старшина Никитин. Писарь Каинов.

*[**Документка искәрмә:** документ Татарстан Дәүләт архивы фондында саклана*[1]*. «Приговор» авыл старостасының түгәрәк, шәмәхә төстәге мөһере белән беркетелгән. Анда «Печать Сельс. Стар. Сухих Курналей Левашевской волости» дигән сүзләр укыла].*

## Икенче мәхәллә тарихына караган документлар
## 1 нче документ

***Приговор***

1908 года, ноября 27 дня, мы, нижеподписавшиеся, крестьяне-собственники Казанской губернии, Спасского уезда, Левашевской волости, прихожан 2-ой соборной мечети деревни Сухих Курналей заключающего в себе 400 душ и 131 домохозяев, имеющих право голоса, быв сего числа в общем собрании на сельском сходе, в присутствии нашего Сельского Старосты Хайруллы Меняфова в числе 132 человек, т.е. не менее 2/3, имеющих право голоса на сходе, где имели суждение о том, что наша приходская 2-я соборная мечеть 15 декабря 1907 года сгорела, взамен которой нам необходимо возвести новую таковую же, а потому мы прихожане 2-ой соборной мечети единогласно постановили: Ходатайствовать перед Казанским Губернским правлением о разрешении нам возвести новую взамен сгоревшей мечеть, и для этой цели на предмет ходатайства о возведении новой мечети избрать избраника из среды своего прихода мазина нашего прихода Мухаметгарея Хусаинова Бакирова в том и подписуемся:

[1]ТР ДА. 2 нче фонд. 2 нче тасвирлама. 7931 нче саклану берәмлеге. 5-7 нче кгз.

1. Илян Насыров
2. Нурутдин Зиганшин
3. Хафиз Зиганшин
4. Шайдулла Зяббаров
5. Гафиятулла Абдулгалимов
6. Нурулла Гиниятуллин
7. Гиниятулла Ахметшин
8. Галиулла Гизятуллин
9. Абдрахман Хусаинов
10. Асядулла Ахметшин
11. Шайдулла Ахметшин
12. Вахит Абдурашитов
13. Тагир Вахитов
14. Исмагил Шахфатуллин
15. Фатых Хамзин
16. Юсуп Сатдаров
17. Сафа Хасанов
18. Нурутдин Камалетдинов
19. Гафиятулла Вахитов
20. Багаутдин Серазетдинов
21. Гильмутдин Серазетдинов
22. Насыбулла Залялетдинов
23. Сытдык Залялетдинов
24. Хисматулла Рязапов
25. Идиятулла Ибрагимов
26. Замалей Фаизов
27. Хамет Тахветуллин
28. Хариз Зямалетдинов
29. Ярулла Аглиуллин
30. Камил Кабиров
31. Мифтахутдин Файзутдинов
32. Аглиулла Фахрутдинов
33. Шакирзян Ибрагимов
34. Хуснутдин Шамсутдинов
35. Муртаза Себетуллин
36. Гиниятулла Себетуллин
37. Гаяз Себетуллин
38. Зарыф Тохветуллин
39. Исмагил Исхаков
40. Ибрай Исхаков
41. Хамет Иксанов
42. Шавалей Багаутдинов
43. Шарафутдин Зямалетдинов
44. Хаметша бакиров
45. Галей Фахрутдинов
46. Шайхутдин Багаутдинов
47. Садык Габитов
48. Фахрутдин Файзутдинов
49. Мифтахутдин Шамсутдинов
50. Муртаза Файзутдинов
51. Себетулла Ганиятуллин
52. Мухаметзян Нугуманов
53. Зарыф Мухаметрахимов
54. Гата Мухаметрахимов
55. Нигматулла Хабибуллин
56. Мазидулла Шайдуллин
57. Мансур Хайруллин
58. Киямутдин Шамсутдинов
59. Набиулла Сафиуллин
60. Файзутдин Шамсутдин[ов]
61. Хуснулла Хасанов
62. Бадретдин Гилязетдинов
63. Хуснулгата Шавалеев
64. Якуп Ибрагимов
65. Гимран Ризванов
66. Мифтихан Ризванов
67. Гиниятулла Сенегатуллин
68. Гильмутдин Зямалетдинов
69. Гильман Ризванов
70. Билян Хабибуллин
71. Фатых Нигматуллин
72. Исмагил Иксанов
73. Мингазетдин Гилязетдинов
74. Хасан Валитов
75. Исмагил Файзутдинов
76. Зинятулла Миндубаев
77. Зарыф Габитов
78. Галей Сайфутдинов

79. Ганиятулла Габязов
80. Хикмятулла Сафиуллин
81. Хузя Багаутдинов
82. Шаймардан Ахметов
83. Фарахгият Фахрутдинов
84. Хайрулла Ахметов
85. Фатых Набиуллин
86. Сафиулла Калимуллин
87. Ярулла Калимуллин
88. Ганус Ахметов
89. Хамидулла Ахметов
90. Хамит Хакимов
91. Файзутдин Мухаметшин
92. Абзал Шамсутдинов
93. Камалетдин Шамсутдинов
94. Зарыф Зяббаров
95. Сытдык исхаков
96. Хасан Мухутдинов
97. Валей Губайдуллин
98. Гарифулла Гафиятуллин
99. Фасах Шавалеев
100. Ярулла Гайнуллин
101. Абдулгалей Валеев
102. Гиниятулла Гайнуллин
103. Галим Абдуллатыпов
104. Шайхутдин Дарман
105. Хуснутдин Шамсутдинов
106. Галим Шамсутдинов
107. Мисбахутдин Шамсутдинов
108. Хисамутдин Шамсутдин
109. Шарафутдин Зарепов
110. Назматдин Шамсутдинов
111. Гайнулла Нехматуллин
112. Фахрутдин Мухутдинов
113. Кашафутдин Шавалеев
114. Вафа Мухаметшин
115. Хаким Зяббаров
116. Хуснутдин Шамсутдинов
117. Сенегатулла Хабибуллин
118. Зялялетдин Шамсутдинов
119. Миндубай мухутдинов
120. Хуснулгата Валеев
121. Шавалей Ахметов
122. Шарафутдин Хуснутдинов
123. Гилязетдин Хуснутдинов
124. Асядулла Хабибуллин
125. Зиганша Ахметшин
126. Хазип Зялялетдинов
127. Хариз Хакимов
128. Галиулла Гайнуллин
129. Загидулла Зяббаров
130. Исмагил Хамзин
131. Мухаметгарей Бакиров
132. Харис Зиганшин

При сем находился сельский староста Хайрулла Меняфов.

Того же числа настоящий приговор к свидетельству в Левашевском Волостном правлении явлен. Кандидат в старшин: Крашениников. Писарь: Каинов

*[**Документка искәрмә:** документ Татарстан Дәүләт архивы фондында саклана*[1]*. «Приговор»га авыл старостасы һәм волость старшинасының берсе түгәрәк, берсе овал, шәмәхә төстәге мөһерләре сугылган. Староста мөһерендә «Печать Сельс. Стар. Сухих Курналей Левашевской волости» дигән сүзләр укыла. Старшина мөһере укылмый].*

[1] ТР ДА. 2 нче фонд. 2 нче тасвирлама. 8482 нче саклану берәмлеге. 4-5 об. кгз.

## 2 нче документ

***В Казанское Губернское Правление***
***Доверенного общ. дер. Сухих Курналей***
***Мухаметгарея Бакирова***
***Левашевской волости Сапсского уезда***

***Прошение.***

Доверителям моим желательно взамен сгоревшей мечети построить новую мечеть, на постройку которой по имеющемуся плану я подавал Прошение в Губернское Правление в середине Октября месяца, но ответа нет до сего времени. Покорнейше прошу Губернское Правление разрешить доверителям моим построить мечеть. Место для постройки предназначается старое и если нужно будет или нет быть расширено на столько, на сколько требуется каноном.

Ноября 1 дня 1908 года

Доверенный Мухаметгарей Бакиров

*[**Документка искәрмә:** документ Татарстан Дәүләт архивы фондында саклана[1]. 2 нче кәгазьдәге бу документ кара язу белән язылган. Кәгазьнең югары уң почмагына Казан Губерна Идарәсенең 1908 нче ел, 11 нче ноябрь белән даталанган дүртпочмаклы, шәмәхә мөһере сугылган. Шулай ук, мөһер эченә 3541 номеры куелган].*

[1]ТР ДА. 2 нче фонд. 2 нче тасвирлама. 8482 нче саклану берәмлеге. 1 нче кгз.

## 3 нче документ

***Рапорт.***

С представлением переписки доложу Спасскому Уездному Полицейскому Управлению, что мною вновь осматривалось место отведения под постройку мечети в деревни Сухих Курналях, Левашевской волости, которое требование 159 статьи Устава Строительного не отвечает. По объяснениям прихожан деревни Сухих Курналей ими подано прошение в Казанское Губернское Правление по строительному отделению с ходатайством не представиться ли возможным разрешить им приступить к постройке мечети на этом растоянии, которое указано мною в акте от 23 Января сего года без переноса училища, так как последнее заменяет у них в настоящее время молитвенный дом, а по оканчании постройки мечети обязуются снести.

*[**Документка искәрмә:** документ Татарстан Дәүләт архивы фондында саклана*[1]*. Кара язу белән язылган. Кәгазьнең аскы сул почмагына Казан Губерна Идарәсенең 1909 нчы ел, 2 нче март белән даталанган дүртпочмаклы, шәмәхә мөһере сугылган. Шулай ук, мөһер эченә 650 номеры (№ 650) куелган. Аскы уң почмакта "Настоящую переписку Спасское Уездное Полицейское Управление представляет в Казанское Губернское Правление. Февраля 21 дня 1909 г. № 43631." дигән язулы штамп беркетелгән].*

[1] ТР ДА. 2 нче фонд. 2 нче тасвирлама. 8482 нче саклану берәмлеге. 1 нче кгз.

# Өченче мәхәллә тарихына караган документлар
## 1 нче документ

**Его Превосходительству**
**Господину Казанскому Губернатору**

**Спасского Уездного**
**Полицейского Управления**

***Рапорт.***

Представляя при сем приговор общества крестьян деревни Сухих Курналей, Левашевской волости Спасского уезда, от 30 июня 1909 года, ходатайствующих об определении к их 3-й соборной мечети названной выше деревни муллой крестьянина деревни Сухих Курналей Абдулхамита он же Хамит Габитова Барышева, вместо муллы той же деревни Шакира Гарифуллина, и документы его: 1. Метрическую выпись о рождении. 2. Свидетельство Оренбургского Магометанского Духовного Собрания от 25 июня 1909 года за № 5727 в знании Барышевым правил магометанской религии. 3. Удостоверение Казанского Уездного Училищнего Совета от 30 августа 1905 года за № 292 в знании русского языка. 4. Удостоверение указного муллы 4-й соборной мечети города Казани Халитова от 18 июня 1909 года за № 220. 5 удостоверение Левашевского волостного правления от 3-го июля 1909 года за № 1790, о несудимости Барышева и 6. Свидетельство о явке к исполнению воинской повинности за № 10, Полицейское Управление доносит Губернскому Правлению, что Барышев во время татарских волнений проживал в городе Казани, и что удостоверение о неучастии в таковых будет представлено дополнительно, по получении сведений о Барышеве от Пристава 5-й части города Казани, в которой проживал Барышев.

Полицейский исправник: Колч… *(имза танылмый). Июля 7 дня 1909 г.*

*[**Документка искәрмә:** документ Татарстан Дәүләт архивы фондында саклана[1]. Машинкада басылган. Кәгазьнең өске өлешенә Казан Губерна Идарәсенең 1909 нчы ел, 24 нче июль белән даталанган дүртпочмаклы, шәмәхә мөһере сугылган. Шулай ук, мөһер эченә 2148 номеры (№ 2148) куелган.*

## 2 нче документ

***Приговор***

1909 года, Декабря 10 дня, мы, нижеподписавшиеся, крестьяне-собственники Казанской губернии, Спасского уезда, Левашевской волости Сухо-Курналинского общества, третьего прихода состоящего из 96 домохозяев быв сего числа в общем собрании на приходском сходе, в присутствии местного Сельского Старосты Исмагила Файзутдинова, в числе 96 человек, где по надлежащем обсуждении постановили: ходатайствовать пред Казанским Губернским Правлением о назначении старшим муллой "хатыпом" к мечети 3 прихода, избранного нами и утвержденного Губернским Правлением младшего муллу Абдулхамита Габитова Барышева, получившего свидетельство на право быть муллою 31 июля сего 1909 г. за № 3407 и приговор этот представить через Спасское Уездное Полицейское Управление; при этом присовокупляем, что документы требуемые при назначении муллы пункт 3 циркуляра Казанского Губернского Правления полицейским управлениям от 7 марта 1908 г. за № 1336 – представлены в Спасское Полицейское Управление при рапорте Левашевского Волостного Правления от 6 июля за № 1803. К сему подписуемся:

[1] ТР ДА. 2 нче фонд. 2 нче тасвирлама. 8359 нче саклану берәмлеге. 1 нче кгз.

1. Исхак Фаткуллин
2. Ибрай Фаткуллин
3. Салахутдин Шамсутдинов
4. Нурутдин Ахметов
5. Идиятулла Насыбуллин
6. Гильмутдин Хисамутдинов
7. Хайрулла Хайбуллин
8. Шайхутдин Сайфутдинов
9. Хайрутдин Ахметов
10. Зялялетдин Хисамутдинов
11. Халитша Зяббаров
12. Вагап Хакимов
13. Шарафутдин Хисамутдинов
14. Ахмет Иксанов
15. Хайрулла Меняфов
16. Абдулганей Зяббаров
17. Габит Хамитов
18. Сафа Шарыпов
19. Насретдин Тарзиманов
20. Зяйней Рахматуллин
21. Вагиз Мусин
22. Асядулла Сялимзянов
23. Хафиз Габитов
24. Юсуп Вафин
25. Мингалей Вафин
26. Хусаин Хасанов
27. Киямутдин Нафигин
28. Хисматулла Гибадуллин
29. Сафиулла Негаметзянов
30. Валей Хамзин
31. Нурутдин Зигангиров
32. Гилязетдин Гимадетдинов
33. Бадретдин Гилязетдинов
34. Муртаза Шамсутдинов
35. Ахметсафа Шамсутдинов
36. Юсуп Гатиятуллин
37. Гайнутдин Гилязетдинов
38. Гайнутдин Хисамутдинов
39. Гильмутдин Меняфов
40. Садык Нафигин
41. Фахурдин Шамсутдинов
42. Ярулла Хайруллин
43. Фатых Гумеров
44. Абдулла Хуснутдинов
45. Халитгалей Валиев
46. Шайхутдин Хуснутдинов
47. Камалетдин Меняфов
48. Сагид Ситдыков
49. Хаметвалей Хабибуллин
50. Зайдулла Атауллин
51. Сибатулла Хабибуллин
52. Халиулла Атауллин
53. Гумер Сайфутдинов
54. Адиулла Ганиятуллин
55. Вагап Хакимов
56. Халиулла Себегатуллин
57. Сафа Шамсутдинов
58. Ибетулла Ганиятуллин
59. Гариф Мухаметшин
60. Гата Фахрутдинов
61. Зябир Кабиров
62. Фасах Нафигин
63. Садык Мусин
64. Зялялетдин Мифтахутдинов
65. Ибрагим Фахрутдинов
66. Юсуп Равилов
67. Галиулла Себегатуллин
68. Давлетша Ахметшин
69. Ситдык Сафиуллин
70. Шайхутдин Зарипов
71. Ганиятулла Гафиятуллин
72. Фахрутдин Хасанов
73. Ахметша Казаков
74. Завзихан Шагимуратов
75. Зямалетдин Мифтахутдинов
76. Гата Мифтахутдинов
77. Мулюк Хакимов
78. Шайхутдин Хасанов

79. Мифтахутдин Хасанов
80. Гиляз Казаков
81. Шайхутдин Сайфутдинов
82. Зялялетдин Камалетдинов
83. Нурутдин Рязяпов
84. Миндубай Насыров
85. Садык Габитов
86. Хасан Валитов
87. Хуснулла Хасанов
88. Муртаза Файзутдинов
89. Фахрутдин Файзутдинов
90. Зиниятулла Миндубаев
91. Усман Галиев
92. Гатиятулла Габбязов
93. Хасан Хакимов
94. Хатып Сафиуллин
95. Галей Хакимов
96. Исмагил Файзетдинов (старш.)

Приговор лично на месте проверен Левашевским Волостным Старшиною, при чем при проверке все домохозяева, подписавшиеся в приговоре, ходатайство подтвердили.

Волостной Старшина: Кришенинников

Писарь: Каинов

*[**Документка искәрмә:** документ Татарстан Дәүләт архивы фондында саклана*[1]*. «Приговор» авыл старостасының почмаклары кисек дүртпочмаклы, шәмәхә төстәге мөһере белән беркетелгән. Анда «Сельс. Стар. Сухо-Курналинскаго общества Левашевской волости Спасского Уезда» дигән сүзләр укыла. Шулай ук документка волость старшинасының түгәрәк, шәмәхә төсле мөһере дә басылган].*

[1] ТР ДА. 2 нче фонд. 2 нче тасвирлама. 8588 нче саклану берәмлеге. 3-4 нче кгз.

# Нәселебезне барлаганда...

## *(Коры Көрнәле авылы метрика дәфтәрләреннән)*

Соңгы елларда нәсел тарихы белән кызыксынган, ата-бабаларның ерак буыннары турында мәгълүматлар тупларга теләгән кешеләр көннән-көн арта бара. Бу аңлашыла да, чөнки кешелек аңы үскән, камилләшкән саен, инсан да үзенең тарихи хәтерен тергезергә, анда үз эзен һәм урынын билгеләргә омтыла. Бу җәһәттән караганда, нәсел тарихын барлауда ярдәмгә килә торган ышанычлы чыганакларның берсе, һичшиксез, метрика язуларыдыр.

Метрика язулары (метрика дәфтәрләре, метрика кенәгәләре) – XIX гасыр башыннан алып мәхәллә халкының тууы, үлеме, никяхлануы яки аерылышуы турында, аерым бер документ рәвешендә, мәчет муллалары тарафыннан теркәлеп барган мәгълүматлар җыелмасы. Рус метрикә кенәгәләре формасында язмалар алып бару, аларны бер урынга җыеп саклау Россия патшасы Николай I нең 1829 елгы указы нигезендә башкарыла, Оренбург Мөселман Диния Нәзарәте тарафыннан гамәлгә куела. Шуңа күрә татар метрикаларындагы мәгълүматлар, башлыча, 1828-29 еллардан башлана. “Дүрт нөсхәдә тутырылган метрикә дәфтәрләренең берсе – имам-хатыйпта, берсе – Диния нәзарәтенә, калганнары өяз һәм губерна идарәләренә тапшырылган. Николай I указы чыгу белән, кайбер авылларда 1830 елдан тутырылган кенәгәләр бүген Башкортстан Дәүләт архивының И-295 нче фондында саклана. Әлеге дәфтәрләрнең сакланыш дәрәҗәләре шактый югары. Яхшы сыйфатлы кәгазь, бозылмый торган кара һәм муллаларның матур һәм хатасыз язулары кирәкле мәгълүматны табуны җиңеләйтә.

Шунысы да күренә: XIX гасырның 80 нче елларына кадәр метрикә дәфтәрләре махсус төзелгән бланк графаларга язылмый. Алар имам хатыйпларның үз куллары белән сызылып, кулъязма вариантта тутырыла. Ә инде XIX гасырның 80 нче елларыннан Россия хөкүмәте һәм Диния нәзарәте карары буенча, типография ысулы белән махсус кенәгә бастырыла, метрикә алып бару тәртипкә салына”.[1]

[1] Мөхәммәтшин З. Метрикә дәфтәрләре – хәтер сагында // http://matbugat.

Коры Көрнәле метрика язулары өлкән муллалар тарафыннан 1 нче мәчеттә 1833 елдан, 2 нче мәчеттә 1829 елдан, 3 нче мәчеттә 1852 елдан алып барыла башлаганнар. Бу документлар бүген Башкортстан Дәүләт архивы, Татарстан Республикасы Дәүләт архивы фондларында саклана. Сүз уңаеннан шунысын да әйтергә кирәк, аерым бер еллар арасында өзеклек тә күренә, ягъни бу елларның метрика кенәгәләре ниндидер сәбәпләр белән сакланмаган яисә юкка чыкканнар. Мисал өчен, Татарстан республикасы Дәүләт архивында 1885, 1889, 1907, 1917 елларга караганнары бар.

Бу чыганакларга нигезләнеп авылның демографик хәлен, нәсел-гаилә бәйләнешләрен, чит яки күрше тирәдәге авыллар белән багланышларны (Коры Көрнәле халкы Олы Тигәнәле, Яңа Салман, Иске Салман, Юеш Көрнәле, Олы Елга һ.б. авыл кешеләре белән кияү-килен алмашып, туганлашып яшәгәннәр), кешеләрнең туу-үлү даталарын ачыкларга, култамга буларак куелган нәсел тамгаларын һәм башка бик күп мөһим фактларны күзәтергә мөмкин.

Шунысына да игътибар итик, бөтен муллалар да бу эшкә бертигез җаваплылык белән якын килмәгәннәр. Шуңа күрә, әлеге язмаларда аерым бер затларның туу яки вафат булу фактлары теркәлмәгән яисә тиешле дәрәҗәдә язылмаган (яңа туган баланың атасының исеме күрсәтелмәгән, туу датасы буш калган, язганннар мулланың култамгасы белән беркетелмәгән һ.б.) очраклар да күренгәләп китә. Әйтик, 1885 елга караган метрика кәгазенең бер урынында Диния Нәзарәте казые тарафыннан “Көрнәледә имам Шәмседдин мулла Габдеррәфыйк углының һич җирдә имзасы юк” дигән искәрмә язып куелган.

Әлбәттә, бу китапта Коры Көрнәле авылының барлык елларга караган метрика язуларын китерү мөмкин түгел. Биредә, нәсел тарихы белән кызыксынучыларга файдалы булыр дип, авылыдагы өч мәхәлләнең дә 1885 елга караган метрика язмалары, гарәп хәрефләреннән бүгенге язуга күчерелеп, укучылар игътибарына тәкъдим ителә.

---

ru/news/?id=8325 [Мөрәҗәгать итү датасы: 01.08.2018].

## Спасс өязе Коры Көрнәле авылының 1865 елгы метрика дәфтәреннән
## Беренче мәхәллә мәчете метрикә дәфтәре
## Әүвәл җөзье [1] вә әүвәлге фасыл. Вөҗүдә [2] килгәннәр хакында

| Мөзәккәр[3] | Мөәннәс[4] | Вөҗүдә килгәннәрнең исемнәре кемнәрдүр | Кайу айда вә кайу көндә вөҗүдә килмешдер | Кайу җенесдән аларның ата вә аналары | Нә өяздә вөҗүдә килмешләр |
|---|---|---|---|---|---|
| | 1 | Хөснеддин Гыйззәтулла углының кызы Бибимәмдүдә | 3 нче гыйнварда | атасы зирагатьче[5], анасы Гадилә | Ыспас өязендә Сухой Көрнәледә тугды |
| 1 | | Шәкүр Габделмәҗид углының углы Мөхәммәдфатих | 5 нче гыйнварда | атасы зирагатьче, анасы Таибә. | Шул ук Көрнәледә тугды |
| 2 | | Урта Тигәнәле Габделхәким баласы Габделваһаб | 10 нчы гыйнварда | атасы зирагатьче, анасы Гайшә | Көрнәледә тугды |
| 3 | | Мөхәммәдшәриф Шәммаз углының углы Исмәгыйль | 15 нче гыйнварда | атасы зирагатьче, анасы Ләтыйфә. | Көрнәледә тугды |

[1] Җөзье – кисәк, өлеш, бүлек
[2] Вөҗүдә – дөньяга.
[3] Мөзәккәр – ир.
[4] Мөәннәс – хатын-кыз.
[5] Зирагатьче – игенче.

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | 2 | Насыйбулла Сәйфулла углының кызы Бибиһаҗәр | 26 нчы гыйнварда | атасы зирагатьче, анасы Ләтыйфә. | Көрнәледә тугды |
| | 3 | Габделвәли Габделхәким углының кызы Бибигафия | 30 нчы гыйнварда | атасы зирагатьче, анасы Хәкимә. | Көрнәледә тугды |
| 4 | | Нигъмәтулла Фәйзулла углының углы Гомәр | 15 нче февральдә | атасы зирагатьче, анасы Мәхүбҗәмал. | Көрнәледә тугды |
| 5 | | Вилдан Мөхеддин углының углы Гыйльман | 24 нче февральдә | атасы зирагатьче, анасы Галимә | Көрнәледә тугды |
| | 4 | Шәмседдин Садыйк углының кызы Бибигафифә | 28 нче февральдә | атасы зирагатьче, анасы Миңкә. | Көрнәледә тугды |
| | 5 | Гыйльмеддин Һибәтулла углының кызы Фәрхиҗәмал | 25 нче мартта | атасы зирагатьче, анасы Гөлсахибә. | Көрнәледә тугды |
| | 6 | Хисамеддин Салих углының кызы Бибигарифә | 29 нчы мартта | атасы зирагатьче, анасы Ләтыйфә. | Көрнәледә тугды |
| | 7 | Габделҗәббар Габделхәким углының кызы Бибигадилә | 22 нче майда | атасы зирагатьче, анасы Сажидә. | Көрнәледә тугды |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | 8 | Мөхәммәджан Габденнасыйр углының кызы Бибинәгыймә | 29 нчы майда | атасы зирагатьче, анасы ... | Көрнәледә тугды |
| | 9 | Хисамеддин Мөрәс углының кызы Шәмсениса | 13 нче июньдә | атасы зирагатьче, анасы Бәдерниса. | Көрнәледә тугды |
| 6 | | Хисамеддин Корбангали углының углы Фәтхеддин | 4 нче июльдә | атасы зирагатьче, анасы Миңсахибә. | Көрнәледә тугды |
| | 10 | Хөсәен Мөрас углының кызы Гөлҗәмал | 16 нчы июльдә | атасы зирагатьче, анасы Гөлбәдьян. | Көрнәледә тугды |
| 7[1] | | Исхак Әхмәд углының углы Габделгани | 23 нче июльдә | атасы зирагатьче, анасы Гыйззәтбану. | Көрнәледә тугды |
| | 11 | Равил Раим улының кызы Мөхүбҗәмал | 23 нче июльдә | атасы зирагатьче, анасы Сәрвиҗәмал. | Көрнәледә тугды |
| 9 | | Шәмседдин Корбангали углының углы Гыйләҗеддин | 13 нче августта | атасы зирагатьче, анасы Зөләйха. | Көрнәледә тугды |
| | 12 | Кәмаледдин Фәйзеддин углының кызы Бибитаибә | 1 нче сентябрьдә | атасы зирагатьче, анасы Сахибҗәмал. | Көрнәледә тугды |

[1] Җидедән соң килүче сигезенче тәртип саны ялгыш төшереп калдырылган.

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 10 | | Гыйззәтулла Габдеррәшид углының углы Гыйниятулла | 10 нчы сентябрьдә | атасы зирагатьче, анасы Миңҗәмал. | Көрнәледә тугды |
| 11 | | Сәйфеддин Хисамеддин углының углы Әхмәдвәли | 5 нче октябрьдә | атасы зирагатьче, анасы Бибифатыйма. | Көрнәледә тугды |
| 12 | | Сафиулла Гобәйдулла углының углы Хәмидулла | 14 нче октябрьдә | атасы зирагатьче, анасы Зөләйха. | Көрнәледә тугды |
| 13 | | Габделҗәббар Габделвахид углының углы Габделмогыйн | 12 нче ноябрьдә | атасы зирагатьче, анасы Бәдриҗәмал. | Көрнәледә тугды |
| 14 | | Гыйльмеддин Фәйзеддин углының углы Нургали | 17 нче ноябрьдә | атасы зирагатьче, анасы Бибигатия. | Көрнәледә тугды |
| | 13 | Гатаулла Монасыйб углының кызы Бибигайшә | 29 нчы ноябрьдә | атасы зирагатьче, анасы Һадия. | Көрнәледә тугды |
| 15 | | Хәсән Вәлид углының углы Хөснулла | 30 нчы ноябрьдә | атасы зирагатьче, анасы | Көрнәледә тугды |

*Көрнәледә указной имам Сафиулла мулла Габдеррәхим углы кулым куйдым*

## Икенче җөзье, әүвәлге фасыл. Никях улынган кемсәнәләр хакында

| | Ни кеше вә кем илән никях улыналар | Кайсы айда вә кайсы көндә | Вәли вәкилләр кемнәр булдылар | Никяхның баш шартлары, укыган кемдер | Никях хөтбәсене укыган кемдер |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Казан губернасы Ыспас өязе Сухой Көрнәле карьясендә Корбангали Уразмәт углының кызы Бибинасихәне шул ук өязнең Үргә Агар карьясендә Габделмәҗид Гали углына никяхландырылды. Кыз 35 нче яшендә, кияү 38 нче яшендә. | 5 нче февраль | Кыз тарафыннан кызның атасы Корбангали Уразмәт углы вәли вәкил булды, кияү тарафыннан кияү Габделмәҗид Гали углы үз-үзенә вәли вәкил булып әлимза кылды[1] | Мәһәр мөсәмма[2]: кырык сум кәгазь берлән. Бер тун тышы, бер кием күш бирмәкче булды вә һәм тулмаганына бер кыла байтал куйды. | Ыспас өязендә Сухой Көрнәле карьясендә имам-хатыйб вә мөдәррис Сафиулла мулла Габдеррәхим углы хөтбәи никяхны укыдыкыма кулым куйдым. |
| 2 | Шул ук Ыспас өязе Көрнәле карьясендә Мифтахеддин Габделваһаб углының [кызы] Бибиләтыйфәне шул ук өязнең Олуг Тигәнле карьясендә | 1 нче апрель | Кыз тарафыннан кызның мөрәбби атасы Габделхәким Габделҗәлил углы вәли вәкил булып әлимза кылды вә | Мәһәр мөсәмма: сиксән сум, әсбабе зәнан[3]. Көллесе[4] хәзер. Тулмагаена бер красгы (?) куйды. | Ыспас өязендә Сухой Көрнәле карьясендә имам Сафиулла мулла |

[1] Әлимза кылды – кулын куйды.
[2] Мәһәр мөсәмма – бирелгән калым.
[3] Әсбабе зәнан – хатын-кыз әйберләре, кирәк-яраклары.
[4] Көллесе – барысы да.

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Мөхәммәдсадыйк Сөбханкол углына никяхландырылды. Кыз 17 нче яшендә, бакирә[1]. Кияү 24 нче яшендә, никях сани[2]. | | кияү тарафыннан кияүнең туган җизнәсе Билаледдин Биктимер углы вәли вәкил булып әлимза кылды. Зәүҗәеннең ризалыкларының шаһидләре Хисамеддин Мөрәс углы, Габделҗәббар Габделвахид углы. | | Габдеррәхим углы хөтбәи никях укыдыкыма кулым куйдым. |
| 3 | Шул ук Көрнәле карьясендә Ишмөхәммәд углының кызы Бибигалимәне шул ук Көрнәле карьясендә Җәмаледдин Хәмит углына никяхландырылды. Кыз 17 нче яшендә, бакирә. Кияү 50 нче яшендә, тол. | 4 нче июльдә | Кыз тарафыннан кызның әнкәсе берлән бертугма мөрәбби агасы Сибгатулла Сәйфеддин углы вәли вәкил булды вә кияү тарафыннан кияү үзе вәли вәкил булып әлимза кылды. Зәүҗәеннең шаһидләре Хәбибулла Әбүзәр углы, Шаһидулла Шәмседдин углы. | Мәһәр мөсәмма: ике йөз сум акчалата, екерме сум көмеш берлән. Әсбабе зәнан. Көллесе хәзер килгән. Тулмаганына бер ... чибәр сыер куйды. | Шул ук Көрнәле карьясендә имам-хатыйб Сафиулла мулла Габдеррәхим углы хөтбәи никях укыдыкым кулым куйдым. |

[1] Бакирә – гыйффәтле кыз.
[2] Сани – икенче.

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Казан губернасы Ыспас өязе Тигәнле волосте Сухой Көрнәле иленең Фәтхеддин Фәтхулла углының хатыны Фәхренниса Шәмседдин кызын хәлегъ кылды[1]. | - | Фәтхеддин Фәтхулла углының хатыны Фәхренниса иренең әмрене инкяр итеп, әҗнәбләрнең[2] өйләренә йөрдеке сәбәпле ма бәенләрендә[3] мәхәббәтләре юклыгыннан хәлегъ булынды. | Хәлегъ лафзы хозурында[4] улан шаһидләр әүвәл Насыйбулла Сәйфулла углы тамгам салдым, Нәҗмеддин Әхмәд углы тамгам салдым. | Көрнәледә имам-хатыйб вә мөдәррис Сафиулла мулла Габдеррәхим углы хәлгы хатынны[5] язганга кулым куйдым. |

*Указной мулла Габдеррәхим Сөләйман углы кулым куйдым.*

## Өченче җөзье, әүвәлге фасыл. Вафат улынан кемсәнәләр хакында

| Мө-зәк-кәр | Мө-ән-нәс | Вафат уланнарның исемнәре кемдер | Кайсы айда, касы көндә вафат | Ничә яшендә | Кайсы зәхмәт илән вафат улгандыр | Ни урында дәфен улынды |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | Сәгъдеддин Сәйфеддин углының углы Шәйхеддин | 3 нче гыйнварда | 1 айлык | зыяндаш зәхмәте[6] илән вафат булды | Ыспас өязендә Көрнәледә дәфен улынды |

---

[1] Хәлегъ кылды – аерды.
[2] Әҗнәбләрнең – чит, ят кешеләрнең.
[3] Ма бәенләрендә – ике араларында.
[4] Хәлегъ лафзы хозурында – аеру турында әйтелгән сүзләр вакытында.
[5] Хәлгы хатынны – хатын аеруны.
[6] Зыяндаш зәхмәте – эпилепсия авыруы.

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 2 | | Сәгъдеддин Сәйфеддин углының углы Шәрәфеддин | 15 нче гыйнварда | 5 атналык | кату зәхмәте илән вафат булды | Көрнәледә дәфен улынды |
| | 1 | Мөхәммәдрәхим хатыны Сахибҗәмал | 30 нчы гыйнварда | 41 нче яшендә | эч авыруы илән вафат булды | Көрнәледә дәфен улынды |
| 3 | | Вилдан Мөхәммәд Мөхеддин углының углы Гыйльман | 29 мартта | 5 атналык | зыяндаш зәхмәте илән вафат булды | Көрнәледә дәфен улынды |
| | 2 | Мохтар хатыны Сәгыйдә | 7 нче майда | 91 нче яшендә | кату зәхмәте илән вафат булды | Көрнәледә дәфен улынды |
| | 3 | Кәмаледдин Габделфәез углының кызы Миңлеҗәмал | 8 нче майда | 11 айлык | зыяндаш зәхмәте илән вафат булды | Көрнәледә дәфен улынды |
| | 4 | Гобәйдулла Нигъмәтулла Углының кызы Мәүлиҗәмал | 11 нче майда | 2 яшьлек | зыяндаш зәхмәте илән вафат булды | Көрнәледә дәфен улынды |
| 4 | | Рәҗәб Рәфыйк углы | 15 нче июньдә | 65 яшьлек | эч авыруы илән вафат булды | Көрнәледә дәфен улынды |
| 5 | | Фәтхеддин Фәтхулла углының углы Мөхәммәдфатих | 2 нче сентябрьдә | 2 яшьлек | зыяндаш зәхмәте илән вафат булды | Көрнәледә дәфен улынды |
| 6 | | Мөхәммәдрәхим Мөхәммәди углының углы Мөхәммәдҗан | 5 нче октябрьдә | 9 яшьлек | баш авыруы илән вафат булды | Көрнәледә дәфен улынды |
| | 5 | Гатаулла Монасыйп углының кызы Бибигайшә | 7 нче декабрьдә | 1 атналык | зыяндаш зәхмәте илән вафат булды | Көрнәледә дәфен улынды |
| 7 | | Гайнеддин Салих углы | 13 нче декабрьдә | 55 нче яшендә | тир зәхмәте илән вафат булды | Көрнәледә дәфен улынды |

*Көрнәле карьясендә имам-хатыйб вә мөдәррис Сафиулла мулла Габд[еррәхим] углы кулым куйдым*

## Икенче мәхәллә мәчете метрикә дәфтәре[1].

## Җөзье әүвәл. Вөҗүдә килгәннәр хакында

| Мөзәккәр | Мөэннәс | Вөҗүдә килгәннәрнең исемнәре кемдер | Кайу айлык вә кайу көндә | Кайюсынын эткәсе вә анының һәм әнкәсе | Нәмә җирдә вөҗүдә килмешдер |
|---|---|---|---|---|---|
| | 1 | Габделләтыйф Йәһүдә углының кызы Фәрхиҗәмал | гыйнварның 3 нче көнендә | эткәсе игенче Габделләтыйф Йәһүдә углы, әнкәсе Сәрвиҗәмал | Коры Көрнәле илендә вөҗүдә килде |
| | 2 | Хәбибулла Әбүзәр углының кызы Шәмсебанат исемле | гыйнварның 5 нче көнендә | эткәсе игенче Хәбибулла Әбүзәр углы | Көрнәледә вөҗүдә килде |
| | 3 | Габделләтыйф Нәби углының кызы Бибиәминә исемле | гыйнварның 9 нчы көнендә | эткәсе игенче Габделләтыйф Нәби углы, әнкәсе Гөлзәгыйфә исемле | Көрнәледә вөҗүдә килде |
| | 4 | Мөхеддин Хәмзә углының кызы Миңсахиб исемле | гыйнварның 15 нче көнендә | эткәсе игенче Мөхеддин Хәмзә углы, әнкәсе Гөзәйдә Урта Тигәнле кызы | Көрнәледә вөҗүдә килде |
| 1 | | Габделгафур Сөбханкол углының углы Мөхәммәдгариф исемле | гыйнварның 19 нчы көнендә | эткәсе игенче Габделгафур, әнкәсе Фәхренниса исемле | Көрнәледә вөҗүдә килде |

[1]Икенче мәхәлләгә караган өлешнең башына метрикә дәфтәрен тикшерүче казыйның “Көрнәледә имам Шәмседдин мулла Габдеррәфыйк углының һич җирдә имзасы юк” дигән култамгасы бар.

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 2 | | Гыйляҗеддин Гыймадедин углының углы Гайнеддин | гыйнварның 21 нче көнендә | эткәсе игенче Гыйляҗеддин, әнкәсе Бәдриҗәмал Түбән, Көрнәле кызы | Коры Көрнәледә вөҗүдә килде |
| 3 | | Мөхеддин Тупикъ Әхтәм углының углы Хөснеддин исемле | гыйнварның 23 нче көнендә | этләсе Мөхеддин Әхтәм углы, әнкәсе Бәдриҗәмал, Яңа Чаллы кызы | Көрнәледә вөҗүдә килде |
| 4 | | Насыйбулла Әбүзәр углының углы Һадиулла | гыйнварның 24 нче көнендә | этләсе игенче Насыйбулла, әнкәсе Бәдреннниса Бәкай Салих кызы | Көрнәледә вөҗүдә килде |
| 5 | | Әбдери Бәшәр углының углы Габделтаһир исемле | гыйнварның 29 нчы көнендә | этләсе игенче Әбдери Бәшәр углы, әнкәсе Бәлхисбану Исхак кызы | Көрнәледә вөҗүдә килде |
| | 5 | Гафиятулла Әхмәдҗан углының кызы Шәмсеҗиһан исемле | февральнең 3 нче көнендә | этләсе игенче Гафиятулла Әхмәдҗан углы, әнкәсе Шәмсе.... кызы | Көрнәледә вөҗүдә килде |
| 6 | | Шәрәфеддин Казаков Хәсән углының углы Фәсахеддин исемле. Бер исемдә бу икенче баласы | мартның 9 нчы көнендә | этләсе игенче Шәрәфеддин Казаков, әнкәсе Бибимәхфүзә исемле | Шул ук Көрнәле илендә вөҗүдә килде |
| 7 | | Җиһангир Фәхреддин углының углы Мостафа исемле | мартның 17 нче көнендә | этләсе игенче Җиһангир Фәхреддин ... углы, әнкәсе Фатиха Рамазан Хәсән [углының] кызы | Шул ук Көрнәле илендә вөҗүдә килде |
| 8 | | Габделвахид Сөбхәнкол углының углы Гатиятулла исемле | мартның 20 нче көнендә | этләсе игенче Габделвахид, әнкәсе Сахилә Ядкәр кызы, Шонталы | Көрнәледә вөҗүдә килде |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 9 | | Фәтхеддин Рамазан Хәсән углының углы Гыйләҗеддин исемле | апрельнең 15 нче көнендә | әткәсе игенче Фәтхеддин Хәсән углы, әнкәсе | Көрнәледә вөҗүдә килде |
| 10 | | Гыйбадулла Нигъмәтулла углының углы Җарулла исемле | май мисиченең[1] 29 нчы көнендә | әткәсе игенче Гыйбадулла Нигъмәтулла углы, әнкәсе Бибигайшә, Тикәнле кызы | Көрнәледә вөҗүдә килде |
| 11 | | Шәүвәли Ташәхмәд углының углы Кәшшафеддин исемле | июльнең 25 нче көнендә | әткәсе игенче Шәүвәли Ташәхмәд углы, әнкәсе Фәрзана, Казак Хөсәен кызы | Көрнәледә вөҗүдә килде |
| | 6 | Исхак Хисамеддин углы кызы Бибимәмдүхә исемле | августның әүвәл көнендә | әткәсе игенче Исхак, әнкәсе Мәрфуга Мөхәммәдҗан кызы | Көрнәледә вөҗүдә килде |
| | 7 | Гатаулла Хәбибулла углының кызы Бибитаибә исемле | октябрьнең 9 нчы көнендә | әткәсе игенче Гатаулла, әнкәсе Хәйренниса Сабавый кызы Балаукүл | Көрнәледә вөҗүдә килде |

[1] Мисиченең – дөресе: месяцының, аеның.

## Никях улынан кемсәнәләр хакында

| | Ни кеше вә кем илән никях улыналар | Кайсы айда вә кайсы көндә | Вәли вәкилләр кемнәр булдылар | Никяхның баш шартлары, укыган кемдер |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Казан губернасы Ыспас өязенең Иске Тикәнле волосте Сухой Көрнәле иленең Төхфәтулла Рәхмәтулла углының кызы Гыйльменисаны вә шул уку Көрнәле иленең Гыймадеддин Сәбай углына никяхландырылды. Кияү 40 яшендә, тол вә кыз 33 яшендә, бу һәм тол. | апрельнең 15 нче көнендә | Кыз тарафыннан кызның әткәсе берлән бер тугма кардәше Хәбибулла Рәхмәтулла углы вәли вәкил булды. Вә кияү үз-үзенә вәли вәкил булып әлимза кылды. Гыймадеддин Сөбханкол углы зәүҗәсенең ризалыкларының шаһидләре Әхмәд Рәхмәтулла углы янә Гафиятулла Әхмәдҗан углы, Сафиулла Нигъмәтҗан углы, Гобәйдулла Фәтхулла углы, Габделгафур Сөбханкол углы. | Мәһәр мөсәммасе: йөз кырык сум акчалата, сигез сум көмеш янә түшәк ястык, биш сум көмеш бирелде янә урыс камзул эче берлән бирелде янә тун бирелде янә читек кәвеш янә ак башлы кара сыер, бәһасе ун сум көмеш, янә бер сарык, бәһасе сигез сум кягазьләр бирелеп никях кылынды. |
| 2 | Казан губернасы Ыспас өязе Олуг Тикәнле волосте Сухой Көрнәле иленең Гыймадеддин Бәзир углының кызы Маһруйны шул ук Көрнәле иленең Сөләйман Хәбибулла углына никяхландырылды. Кияү 24 нче яшендә вә кыз һәм 20 яшендә, җанибәйн бакир вә бакирә[1]. | апрельнең 25 нче көнендә | Кыз тарафыннан кызның әткәсе Гыймадеддин Бәзир углы вәли вәкил булып әлимза кылды. Вә кияү тарафыннан агасы Хөсәен Сөбханкол углы вәли вәкил булды, зәүҗәсенең ризалыкларының шаһидләре Гыйләҗеддин Гыймадеддин углы вә Җиһангир Фәхреддин углы янә Олуг Тикәнле Хәбибулла Миңлебай углы янә Шәмседдин Маннур углы | Мәһәр мөсәммасе: ике йөз илле сум. Акчалата егерме сум көмеш бирелде янә әсбабе зәнан йөз сумлык бирелде янә кыз аллы-аклы чобар сыер куелды, бәһасе кырык кәгазь янә кырык сумы мәзкүрә Маһруй Гыймадеддин кызы сораган вакытта бирмәк булып, мин, кияү Сөләйман Хәбибулла углы имза кылдым. |

[1] Җанибәйн бакир вә бакирә – икесе дә гыйффәтле.

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 3 | Казан губернасының Ыспас өязенең Олуг Тикәнле волостенең Сухой Көрнәле иленең Халид Хәмид углының кызы Маһиҗәмалны шул ук Казан губернасының Ыспас өязе Матак волосте Яңа Салман иленең Габдулла Исай углына никяхландырылды. кияү 25 яшендә вә кыз һәм 24 яшендә. Җанибәйн[1] толлар. | июньнең әүвәл көнендә | Кыз тарафыннан кыз берлән тугма кардәше Хәмид Хәлид углы вәли вәкил булды вә кияү үзе вәли булды. Зәүҗәсенең ризалыкларының шаһидләре Сәлимҗан Тимербай углы янә Хөснеддин Тапикъ углы янә Габделхәким Әхмәд углы Салих Габделваһаб углы | Мәһәр мөсәммасе: йөз сум. Әсбабе зәнан көллисе бирелде, етмеш сумлык. Янә калган утыз сумга бер кара сыер куелды. Тамгасы – сул колагы эченнән кискән.<br><br>Вә шул ук Көрнәле иленең указный имам Шәмседдин Габдеррәфыйк углы никях хөтбәсене укыдым. |

## Өченче җөзье, әүвәлге фасыл. Вафат улынган кемсәнәләр хакында

| Мө-зәк-кәр | Мө-ән-нәс | Вафат уланнарның исемнәре кемдер | Кайсы айда, касы көндә вафат | Ничә яшендә | Кайсы зәхмәт илән вафат улгандыр | Ни урында дәфен улынды |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1 | Казаков Җәмали хатыны Гыйльмеҗәмал | гыйнварның 3 нче көнендә | 26 нчы яшендә | бала тудыра алмас вафат | Сухой Көрнәледә дәфен кылынды |
| 1 | | Казаков Юлдаш углы Нигъмәтулла | гыйнварның 5 нче көнендә | 40 яшендә | чахуткы зәхмәте илән вафат | Көрнәледә дәфен кылынды |

[1] Җанибәйн – икесе дә

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 2 | | Таш Җиһанша углы Мостафа исемле | февральнең әүвәл көнендә | 1 яшендә | чәчәк илән вафат | Көрнәледә дәфен кылынды |
| | 2 | Фәтхулла Әбүзәр углының кызы Биби Мәхфүзә исемле | мартның 4 нче көнендә | 1 яшендә | кызамык илән вафат | Көрнәледә дәфен кылынды |
| | 3 | Гафиятулла Хәмәджан углының кызы Шәмсеҗиһан исемле | мартның 5 нче көнендә | 2 айлык | чәчәк илән вафат | Көрнәледә дәфен кылынды |
| | 4 | Кәсмай хатыны Шәрифә исемле | апрельнең 3 нче көнендә | 70 яшендә | кату зәхмәте илән вафат | Көрнәледә дәфен кылынды |
| 3 | | Мостафа Җиһангир углы | Майның 16 нчы көнендә | 2 ай ярым-лык | чәчәк илән вафат | Көрнәледә дәфен кылынды |
| 4 | | Тубикъ Мөхиддин Әхтәм углы | май мисячының 17 нчы көнендә | 27 нче яшендә | ютәл зәхмәте илән вафат | Көрнәледә дәфен кылынды |
| 5 | | Ир углан Җарулла исемле | июльнең 2 нче көнендә | нәкъ бер айлык | чәчәк илән вафат | Көрнәледә дәфен кылынды |
| 6 | | Хөснеддин Казаков Хөсәен углының углы Миңлегата исемле | ноябрьнең 15нче көнендә | 3 нче яшендә | зыяндаш илән вафат | Көрнәледә дәфен кылынды |

## Өченче мәхәллә мәчете метрикә дәфтәре

### Беренче җөзье, әүвәлге фасыл. Вөҗүдә килгәннәр хакында

| Мө-зәк-кәр | Мө-ән-нәс | Вөҗүдә килгәннәрнең исемнәре кемнәрдүр | Кайу айда вә кайу көндә вөҗүдә килмешдер | Кайу җенесдән аларның ата вә аналары | Нә өяздә вөҗүдә килмешләр |
|---|---|---|---|---|---|
| | 1 | кыз углан Бибисәгыйдә | гыйнварның 15 йәүмендә[1] | атасы Сөнгатулла мулла Хисамеддин углы, анасы Бибимәхфүзә | Ыспас өязе Көрнәледә вөҗүдә килмешдер |
| | 2 | кыз углан Бибигафифә | гыйнварның 20 йәүмендә | атасы Кәмаледдин Җәмаледдин углы, анасы Җомабикә | Ыспас өязе Көрнәледә вөҗүдә килмешдер |
| 1 | | ир углан Госман | гыйнварның 25 йәүмендә | атасы Мөхеддин Фазыл углы, анасы Фәхерниса | Ыспас өязе Көрнәледә вөҗүдә килмешдер |
| | 3 | кыз углан Бибитаибә | гыйнварның 27 йәүмендә | атасы Кәмаледдин Фәтхулла углы, анасы Гайниҗәмал | мәзкүр[2] карьясендә[3] тугды |
| 2 | | ир углан Фәтхеддин | гыйнварның 2 йәүмендә | атасы Сәйфеддин Габдессәлам углы, анасы Биби | мәзкүр карьясендә тугды |

[1] Йәүмендә – көнендә.
[2] Мәзкүр – әлеге, алда искә алынган.
[3] Карьясендә – авылында.

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 3 | | ир углан Гыйниятулла | гыйнварның 31 йәүмендә | атасы Рәхмәтулла Рахманкол углы, анасы Биби | мәзкүр карьясендә тугды |
| | 4 | кыз углан Мәрьямниса | 24 февраль | атасы Садыйк Мөхеддин углы, анасы Мәүлиҗәмал | мәзкүр карьясендә тугды |
| 4 | | ир углан Мөхәммәдсадыйк | 24 февраль | атасы Габделҗәббар Габденнасыйр углы, анасы *(язылмаган)* | мәзкүр карьясендә тугды |
| 5 | | ир углан Фәсахеддин | 27 февраль | атасы Габделвәли Габделфәиз углы, анасы Миңниса | мәзкүр карьясендә тугды |
| 6 | | ир углан Лотфулла | 6 март | атасы Хәйрулла Рәхмәтулла углы, анасы Мәрфуга | мәзкүр карьясендә тугды |
| | 5 | кыз углан Ганбәр | 27 март | атасы Гайнулла Муллагали углы, анасы Мөхибҗәмал | мәзкүр карьясендә тугды |
| 7 | | ир углан Мөхәммәдһади | 18 апрель | атасы Хөсәен Сөбханкол углы, анасы Гафия | мәзкүр карьясендә тугды |
| 8 | | ир углан Нуреддин | 19 июнь | атасы Хисамеддин Габдессәлам углы, анасы Сахибҗәмал | мәзкүр карьясендә тугды |
| 9 | | ир углан Мортаза | 20 июнь | атасы Нигъмәтулла Хәбибулла углы, анасы Лә[тыйфә] | мәзкүр карьясендә тугды |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 10 | | ир углан Миңлевәли | 22 июнь | Атасы Гайнулла Нигъмәтулла углы, анасы Бибигазизә | мәзкүр карьясендә тугды |
| | 6 | кыз углан Бибивәсимә | 27 июнь | Атасы Фәйзеддин углы | мәзкүр карьясендә тугды |
| | 7 | кыз углан Мәмдүха | 6 июль | атасы Шәмседдин Мостафа углы, анасы Фатыйма | мәзкүр карьясендә тугды |
| 11 | | ир углан Ибраһим | 8 июль | Атасы Мөхәммәдвафа Хәмзә углы, анасы Шәмсекамәр | мәзкүр карьясендә тугды |
| 12 | | ир углан Гыйльман | 1 сентябрь | атасы Габделмәҗид Тимербулад углы, анасы Хөсниҗәмал | мәзкүр карьясендә тугды |
| | 8 | кыз углан Бибигадилә | 2 сентябрь | атасы Мифтахеддин Сәйфеддин углы, анасы Ләтыйфә | мәзкүр карьясендә тугды |
| 13 | | ир углан Әһлиулла | 3 сентябрь | атасы Хәбибулла Сәфәргали углы, анасы Мәрхүбә | мәзкүр карьясендә тугды |
| 14 | | ир углан Сахибеддин | 7 сентябрь | Атасы Саләхеддин Шәмседдин углы, анасы Мәхфүзә | мәзкүр карьясендә тугды |
| | 9 | кыз углан Миңлевафа | 10 сентябрь | Атасы Габделбәдыйгъ Рәхмәтулла углы, анасы Гөлҗәмал | мәзкүр карьясендә тугды |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 15 | | ир углан Миңлегалим | 11 сентябрь | атасы Фәйзеддин Һади углы, анасы Гыйльмиҗәмал | мәзкүр карьясендә тугды |
| 16 | | ир углан Исхак | 11 сентябрь | атасы Габдессаттар Габделвахид углы, анасы Сабира | мәзкүр карьясендә тугды |
| 17 | | ир углан Мөхәммәдгата | 14 сентябрь | атасы Җиһанша Бәшир углы, анасы Хөсниҗәмал | мәзкүр карьясендә тугды |
| | 10 | кыз углан Маһруйҗәмал | 15 сентябрь | атасы Мөхәммәдрәхим Бохарай углы, анасы Шәрифҗәмал | мәзкүр карьясендә тугды |
| | 11 | кыз углан Бибиҗәмал | 27 сентябрь | атасы Гайнулла Хәбибулла углы, анасы Мөхибҗәмал | мәзкүр карьясендә тугды |
| 18 | | ир углан Мостафа | 2 октябрь | атасы Хәсән Сөбханкол углы, анасы Әсхабҗәмал | мәзкүр карьясендә тугды |
| | 12 | кыз углан Бибинәгыймә | 12 ноябрь | атасы Гайфулла Әхмәдҗан углы | мәзкүр карьясендә тугды |
| 19 | | ир углан Хөснулла | 2 декабрь | атасы Хәсән Вәлид углы, анасы Миңҗәмал | мәзкүр карьясендә тугды |
| | 13 | кыз углан Бибигафифә | 7 декабрь | атасы Җиһанша Хәбибулла углы, анасы Гобәйдә | мәзкүр карьясендә тугды |

## Икенче җөзье, әүвәлге фасыл. Никях улынган кемсәнәләр хакында

| | Ни кеше вә кем илән никях улыналар | Кайсы айда вә кайсы көндә | Вәли вәкилләр кемнәр булдылар | Никяхның баш шартлары, укыган кемдер |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Ыспас өязе Көрнәле иленең Хәбибулла Сәфәргали углының кызы Бибигазизәне Лаеш өязе Көрнәле иленең Сәйфеддин Вәлиулла углына никахландырылды. Кыз 21 яшендә вә егет 28 яшендә | гыйнвар-ның 7 йәүмендә | Кыз тарафыннан әткәсе Хәбибулла Сәфәргали углы вәли вәкил булды, вә кияү тарафындан атасы Вәлид Габид углы вәли вәкил булды. Вә шаһидин[1]: Хәйрулла Нигъмәтулла углы, Хәсәнша Мөхәммәдша углы, тамгасы илә | Мәһәре сими[2] өч йөз сум. Сәмән[3] йөз кырык сум янә әсбабе зәнан[4] йөз ун сум. Калган илле сумы мал илән: бер кара сыер вә һәм бер кортлы умарта куеп, мин кияүнең вәли вәкиле Вәлид Габид углы риза булыб тамгасы илә, янә кызның вәли вәкиле Хәбибулла Сәфәргали углы Бибигазизәнең ризалыгы илән риза булыб, тамгасы илә |

[1] Шаһидин – ике шаһите.
[2] Сими – көмеш акча.
[3] Сәмән – акча.
[4] Әсбабе зәнан – хатын-кыз әйберләре, кирәк-яраклары.

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2 | Ыспас өязе Көрнәленең Гобәйдулла Рәхмәтулла углының кызы Бәдерниса шул ук илнең зирагатьче[1] Габделвәли Әхмәр углына никяхландырылды. Кыз – 17 яшендә, вә кияү 35 яшендә. | гыйнвар-ның 11 йәүмендә | Кыз тарафыннан эткәсе Гобәйдулла Рәхмәтулла углы вәли вәкил булды. Вә кияү Габделвәли Әхмәр углы үзе хазир булды вә шаһидин Хәйрулла Рәхмәтулла углы тамгасы илә, янә Гобәйдулла Фатих углы тамгасы илә | Мәһәре сими ике йөз сум. Хәзер сәмән сиксән сум янә әсбабе зәнан сиксән сум. Калган кырык [сум мал] белән: бер кызыл сыер куеб, уң колагы ярган, сул колагы аркылы чапкан. Мин кияү Габделвәли Әхмәр углы риза булыб тамгасы илә, янә кызның вәли вәкиле Гобәйдулла Рәхмәтулла углы кызның ризалыгы илән риза булыб, тамгасы илән |
| 3 | Ыспас өязе Көрнәле иленең Мөхеддин Салих углының кызы Бибифаизә шул ук өязнең Урта Салман иленең Хәбибулла Габделхәннан углына никяхландырылды. Кыз – 20 яшендә вә егет 25 яшендә. | мартның 18 йәүмендә | Кыз тарафыннан тугма агасы Сибгатулла Габделмәҗид углы вәли вәкил булды вә кияү Хәбибулла Габделхәннан углы үзе хазир булды вә шаһидин Җәлаледдин Салих углы тамгасы белән, янә Сөнгатулла Хисамеддин тамгасы belә | Мәһәр сими ике йөз илле сум. Хәзер сәмән алтмыш сум, янә әсбабе зәнан туксан сум. Калган йөз малның кырык сумы кызыл сыер куеп, калган алтмыш сум малны мәзкүрә Фаизә сораган вакытта бирәчәк булып, мин кияү Хәбибулла Габделхәннан углы риза булып, тамгасы белә[2]. Янә кызның вәли вәкиле Сибгатулла Габделмәҗид углы Фаизәнең ризалыгы илән риза булып тамгасы белә |

[1] Зирагатьче – игенче.
[2] Белә – белән.

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 4 | Ыспас өязе Көрнәле иленең Сәйфеддин Гомәр углының кызы Гыйльменисаны шул ук илнең Мөхәммәдвафа Габделләтыйф зирагатьче углына никяхландырылды. Кыз 24 яшендә, кияү 26 яшендә. | июньнең 2 йәүмендә | Кыз тарафыннан әткәсе Сәйфеддин Гомәр углы вәли вәкил булды вә кияү тарафыннан ата бер тугма агасы Габделхәким Бохарай углы вәли вәкил булды вә шаһидин Хисамеддин Зөлфөкар углы тамгасы белә, янә Габделләтыйф Габденнафигъ углы тамгасы белә | Мәһәр сими өч йөз сум. Хәзер сәмән утыз сум, янә әсбабе зәнан йөз утыз сум. Калган йөз кырык сум малның йөз дә биш сумга бер туры алаша ат куеп, янә калган утыз биш малны мәзкүрә Гыйльмениса сораган вакытта бирәчәкбез булып, кияүнең вәли вәкиле Габделхәким Бохарай углы ризалатып тамгасы белә, янә кызның вәли вәкиле Сәйфеддин Гомәр углы риза булып тамгасы белә |
| 5 | Ыспас өязе Көрнәле иленең Шәмседдин Сәйфеддин углының кызы Фәхернисаны шул ук өязнең Иске Салман иленең зирагатьче Низамеддин Хөснеддин углына никяхландырылды. Кыз 26 яшендә, егет 28 яшендә. | декабрь-нең 19 йәүмендә | Кыз тарафыннан әткәсе Шәмседдин Сәйфеддин углы вәли вәкил булды вә кияү Низамеддин Хөснеддин углы үзе хазир булды вә шаһидин Сәлахеддин Шәмседдин углы тамгасы белә, янә Нигъмәтулла Хәбибулла углы тамгасы белә | Мәһәр сими ике йөз кырык сум. Хәзер сәмән кырык биш сум, янә әсбабе зәнан кырык биш сум. Калган илле сум мал: бер кызыл сыер куеп, мин кияү Низамедин Хөснеддин углы риза булып тамгасы белә, янә кызның вәли вәкиле Шәмседин Сәйфеддин углы кызның ризалыгы илән риза булып тамгасы белә |

## Өченче җөзье, әүвәлге фасыл. Вафат улынган кемсәнәләр хакында

| Мө-зәк-кәр | Мө-ән-нәс | Вафат уланнарның исемнәре кемдер | Кайсы айда, касы көндә вафат | Ничә яшендә | Кайсы зәхмәт илән вафат улгандыр | Ни урында дәфен улынды |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1 | Хатын кеше Гайшә | гыйнвар-ның 6 йәүмендә | 45 яшендә | бала тапмак зәхмәте илән вафат | Ыспас өязе Көрнәле илендә дәфен улынды |
| 1 | | Идрис Рамазан углының углы Җәмалетдин | мартның 26 йәүмендә | 3 яшендә | зыяндаш зәхмәте илән вафат | мәзкүр[31] карьясендә дәфен улынды |
| 2 | | Хәбибулла Рәхмәтулла углының углы Нурулла | апрель 9 йәүмендә | 19 яшендә | эч зәхмәте илән вафат булды | мәзкүр карьясендә дәфен улынды |
| | 2 | Гыйлаҗетдин кызы Мәрвәрсафа | 11 апрель | 28 яшендә | ютәл зәхмәте илән вафат булды | мәзкүр карьясендә дәфен улынды |
| 3 | | Хәйрулла Рәхмәтулла углының углы Лотфулла | 21 апрель | Икенче яшендә | зыяндаш зәхмәте илән вафат | мәзкүр карьясендә дәфен улынды |
| | 3 | Хәмзә Габбас углының кызы Сахибкәмал | 2 май | 33 яшендә | ютәл зәхмәте илән вафат булды | мәзкүр карьясендә дәфен улынды |
| | 4 | Хисамеддин Зөлфөкар углының кызы Хадимә | 3 май | 4 яшендә | зыяндаш зәхмәте илән вафат | мәзкүр карьясендә дәфен улынды |
| 4 | | Шәмседдин Халид углының углы Заһидулла | 11 май | Ике яшендә | зыяндаш зәхмәте илән вафат | мәзкүр карьясендә дәфен улынды |
| 5 | | Фазыл Зияд углының углы Хисамеддин | 16 май | 40 яшендә | эч зәхмәте илән вафат улды | мәзкүр карьясендә дәфен улынды |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 6 | | Габделләтыйф Әхтям углының углы Габделвәли | 24 май | 26 яшендә | ютәл зәхмәте илән вафат булды | мәзкүр карьясендә дәфен улынды |
| | 5 | Мөхәммәдша мулла Бәшир углының кызы Мөхибҗәмал | 15 июнь | 12 яшендә | эч зәхмәте илән вафат булды | мәзкүр карьясендә дәфен улынды |
| | 6 | Әбүбәкер Габделхәннан углының кызы Гадилә | 12 ноябрь | 5 айлык | зыяндаш зәхмәте илән вафат | мәзкүр карьясендә дәфен улынды |
| | 7 | Кәмалетдин Җәмаледдин углының кызы Бибигафифә | 10 декабрь | 1 яшендә | җен зәхмәте илән вафат булды | мәзкүр карьясендә дәфен улынды |
| 7 | | Нигъмәтулла Хәбибулла углының углы Мортаза | 16 декабрь | 7 айлык | кызамык зәхмәте илән вафат булды | мәзкүр карьясендә дәфен улынды |
| 8 | | Әхмәр Госман углының углы Нигъмәтулла | 22 декабрь | 68 яшендә | кату зәхмәте илән вафат булды | мәзкүр карьясендә дәфен улынды |
| 9 | | Фәхреддин Сәйфеддин углының углы Миңлегата | 29 декабрь | 2 атна-лык | зыяндаш зәхмәте илән вафат | мәзкүр карьясендә дәфен улынды |
| 10 | | Рәхмәтулла Сөләйман углының углы Әхмәд | 29 декабрь | 62 яшендә | кату зәхмәте илән булды | мәзкүр карьясендә дәфен улынды |

*Ыспас өязе Көрнәле иленең мәншүрле*[1] *имам-мөдәррис вә мөхтәсиб Хисамеддин Салих углы никях хотбәсене укыдыкыма кулым куйдым.*

[1] Мәншүрле – указлы.

# Авылыбызның күренекле шәхесләре

Коры Көрнәле авылы Татарстан табигатенең матур һәм тарихи бер почмагында, урманнарга, елга-күлләргә бай җирендә урнашкан. Тик шулай да авылның төп байлыгы – аның гади, киң күңелле, тырыш һәм хезмәт сөючән кешеләредер, мөгаен. Кемнәр генә юк алар арасында: игенче һәм механизатор дисеңме, укытучы һәм инженерлар, артистлар һәм генераллар, тагын бихисап күп һөнәр ияләрен, күренекле шәхесләрне илгә бүләк иткән Коры Көрнәле авылы. Аларның кайберләре белән китапның алдагы битләрендә инде танышып та үттек. Коры Көрнәле туфрагында туып, аның суын эчеп үскән кайбер шәхесләр эшчәнлегенә биредә аерым тукталуны мәгъкуль санадык. Сүзебез авыл тарихында гына түгел, ил һәм халык язмышында күренекле урын тоткан авлдашларыбыз турында...

### *Генерал Зәки Котлин*



Зәки Котлин (тулы исеме - Зәкиулла Йосыф улы Котлин) – Беренче бөтендөнья сугышы, Гражданнар сугышы, Бөек Ватан сугышларында катнашкан хәрби эшлекле, 270 нче укчылар дивизиясе командиры, генерал-майор.

Ул 1900 елның 17 ноябрендә Казан губернасы Спасс өязенең Левашев волостендагы Коры Көрнәле авылында игенче гаиләсендә дөньяга килә. Авылда озак

яшәми, гаиләсе белән Казан шәһәренә күченеп китә. 1914-16 еллар аралыгында Казан тимер юл станциясендә ремонтчы булып эшли. 1916 елда үз теләге белән Патша армиясенә алынып, Көнбатыш фронтта хезмәт итә. Октябрь инкыйлабы чорында большевикларга кушыла.

Зәки Котлинның хәрби карьерасы Гражданнар сугышы елларында башлана дисәк тә ялгыш булмас. Ул 1920 елда Казанда Мөселман командирлары курсын тәмамлап, Беренче Татар укчы полкына рота, соңрак батальон командиры итеп билгеләнә, шул сыйфатта Төркестанда Бохара тирәсендәге сугышларда катнаша. Яшь командир биредә күрсәткән батырлыклары өчен “Бохара йолдызы” ордены белән бүләкләнә.

Зәки Котлин үзенең сугышчан тәҗрибәсен баету, хәрби осталыгын үстерү өстендә даими кайгыртып яши: Мәскәүдә хәрби җитәкчеләр тәрбияләүче “Выстрел” мәктәбен (1925-1926 еллар), М.Фрунзе исемендәге Хәрби академияне (1928-1931 еллар) тәмамлый, берничә ел дәвамында әлеге уку йортында укытып та ала. Нәкъ шул чорда аңа, Оборона халык комиссары карары белән, полковник исеме бирелә (1940 ел).

Зәки Йосыф улының утызынчы еллардан соңгы тормышы һәм хәрби эшчәнлеге кабат Татарстан, Казан белән бәйле. Академияне тәмамлаганнан соң Беренче Казан укчы дивизиясенең штаб начальнигы ярдәмчесе, соңрак штаб начальнигы итеп билгеләнә. Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты 1932 елның февралендә – Казан дивизиясе үзенең унъеллыгын бәйрәм иткән көннәрдә, милли частьларның сугышчан сәләтен үстерү өлкәсендәге хезмәтен бәяләп, аны Мактау грамотасы белән бүләкли.

Бөек Ватан сугышы башлану белән Зәки Котлинга 270 нче укчы дивизиясе белән җитәкчелек итү вазифасы йөкләнә. Әлеге дивизия илбасарларга каршы сугышның иң

кайнар нокталарында – Кременчуг, Харьков, Красноград тирәләрендә барган бәрелешләрдә дошман хөҗүмнәрен кире кайтара, Барвенково-Лазовая юнәлешендә, сигез көн эчендә йөздән артык чакрым юл узып, җитмешләп торак пункт һәм станцияләрне фашистлардан азат итүгә ирешә. 1942 елның 29 гыйнваре кичендә яңгыраган Совет информбюро хәбәрләрендә "Иптәш Зәки Котлин җитәкчелегендәге гаскәрләр батырларча сугышып, дошманның 25 машинасын, 300 винтовкасын, 9000 снарядын, 50 атын, 2 паровоз белән 15 вагонын һәм азык-төлек складларын кулга төшерделәр" дип искә алына. Әлеге бәрелештә күрсәткән батырлыклары өчен Зәки Котлинга генерал-майор хәрби дәрәҗәсе һәм Ленин ордены бирелә, ә "котлинчы" сугышчыларның җиңүләре шигъри юлларга күчә.

Үзән, елга, тарлавыклар аша,
Днепрга барган юлларда
Котлинчылар бара сугышларга,
Автоматын кысып кулларга.
Кызганмыйлар көч һәм хезмәтләрен,
Гүзәл тормышларын яуларда:
Янә Ватанына кайтарыла
Авыл, шәһәр, елга, таулар да... –

дип яза алар хакында шагыйрь Джек Алтаузен[1].

Батыр сугышчы һәм оста полководец Зәки Йосыф улы Котлинга, кызганычка каршы, Җиңү көнен күрергә насыйп булмый. Ул 1942 елның 25 маенда дошман камалышыннан чыккан вакытта каты яралана һәм, аңына да килмичә, Харьков өлкәсенең Лозовенька авылы тирәсендә һәлак була.

[1] Бу шигырь 1942 елда рус телендә "Огонек" журналының март ае номерында басылып чыга.

Зәки Котлинның тормыш һәм хәрби эшчәнлеге Г.Йосыповның “Генерал Зәки Котлин” (1959 ел) һәм Н.Булатовның “Йолдызлы йолдызлар” (2000 ел) китапларында яктыртыла.

Бүген Коры Көрнәле авылының бер урамы Зәки Котлин исемен йөртә.

### *Зәки Котлинның тормышы һәм хәрби эшчәнлеге турында төп даталар* [1]

1900 ел. 17 ноябрь. – Казан губернасы, Спасс өязе Коры Көрнәле авылында туа.

1914-1916 еллар – Казан тимер юл станциясендә тимер юл эшчесе.

1916 ел, июль - 1917 ел, август – Патша армиясе солдаты (Көнбатыш фронт).

1918 ел, январь – Кызылгвардеец (Казан).

1918 ел, 15 нче август – РКП(б) членлыгына кабул ителә.

1918 ел, август – Мәскәү полкы кызылармеецы (Көнчыгыш фронт).

1918 ел, ноябрь – 1919 ел, февраль – Контузия алу сәбәпле госпитальдә ята.

1919 ел, март – 1919 ел, ноябрь – Тимер юл частьлары солдаты (Төньяк фронт).

1919 ел, ноябрь – 1920 ел, май – Мөселман командирлар курсы курсанты.

1920 ел, май – 1922 ел, июль – 10 нчы Төркстан (элекке 1 нче Татар) укчы полканың рота командиры ярдәмчесе, рота командиры.

1922 ел, август – 1925 ел, август – 11 нче Төркстан (элекке 2 нче татар) укчы полкының рота командиры, батальон командиры.

[1] Г.Йосыпов. Генерал Зәки Котлин. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1959. – 98-98 бб.

1925 ел – “Бохара йолдызы” ордены белән бүләкләнә.

1925 ел, сентябрь – 1926 ел, май – “Выстрел” мәктәбе курсанты.

1926 ел, май – 1928 ел, октябрь – 11 нче Төркстан укчы полкының батальон командиры, полк мәктәбе начальнигы.

1928 ел, октябрь – 1931 ел, май – М.В. Фрунзе исемендәге Хәрби академия тыңлаучысы.

1931 ел, июнь – 1931 ел, ноябрь – 1 нче Казан укчы дивизиясенең 2 нче укчы полк штабы начальнигы.

1931 ел, декабрь – 1933 ел, август – 1 нче Казан укчы дивизиясенең штаб начальнигы ярдәмчесе һәм шатб начальнигы.

1933 ел, сентябрь – 1934 ел, ноябрь – Ныгытылган район штабы начальнигы.

1934 ел, ноябрь – 1936 ел, июнь – Хәрби округ штабының бүлек начальнигы ярдәмчесе, бүлек начальнигы.

1936 ел, июнь – 1937 ел, август – 170 нче укчы полк командиры.

1937 ел, август – 1939 ел, июль – 57 нче Урал укчы дивизиясе командиры ярдәмчесе.

1938 ел – “XX лет РККА” медале белән бүләкләнә.

1939 ел, август – 1941 ел, июль – М.В. Фрунзе исемендәге Хәрби академия укытучысы.

1940 ел, 5 март – ОХК приказы белән полковник исеме бирелә.

1941 ел, июль – 270 нче укчы дивизия командиры итеп билгеләнә.

1942 ел, 27 март – СССР ХКС карары белән генерал-майор исеме бирелә һәм СССР Верховный Советы Президиумы Указы нигезендә Ленин ордены белән бүләкләнә.

1942 ел, 22-27 май, Көньяк-Көнбатыш фронтта немец-фашист илбасарларга каршы көрәштә һәлак була.

## *Советлар Союзы Герое*
## *Хәбибулла Хәйруллин*



Хәйруллин Хәбибулла Нәбиулла улы – Советлар Союзы Герое, Бөек Ватан Сугышында өлкән сержант, 1248 нче артиллерия полкының орудие командиры. Ленин ордены, “За отвагу” һәм башка медальләр иясе. Ул 1923 елның 14 февралендә Коры Көрнәле авылының имамы Нәбиулла Галиулла улы гаиләсендә дөньяга килә. 1938 елда авыл мәктәбенең җиде классын тәмамлаганнан соң, берничә ел колхозда эшли. Бөек Ватан сугышы башлану белән Алексеевск Хәрби Комиссариатыннан сугышка алына. 1942 елдан 1945 елга кадәр Сталинград камалышы сугышында, 3 нче Украина фронтында Никопольск-Криворожск (30 январь – 29 февраль, 1944 ел), Березнеговато-Снигеревск (6 – 18 март, 1944 ел), Одесса (26 март – 14 апрель, 1944 ел), 1 нче Украина фронтының 6 нчы армиясе составында Сандомирск-Силезк (12 январь – 3 февраль 1945 ел), Висло-Одер (февраль 1945 ел) стратегик хөҗүмнәрендә катнаша. Одер елгасының көнбатыш ярында, хәзерге Мальчице поселогы тирәсендә барган канлы бәрелешләрдә орудие командиры өлкән сержант Хәбибулла Хәйруллин, орудие наводчигы сержант В.К. Водовенко белән берлектә, зур батырлык күрсәтеп, соңгы ядрәләре беткәнче дошман һөҗүмен кире кайтаралар, шул рәвешле, безнең гаскәрләрнең Одер елгасын кичүен тәэмин итәләр. Снарядлары беткәннән соң кул сугышына күчәләр,

әмма чигенмиләр, сугышчан позицияләрен бирмиләр. Бу тиңдәшсез бәрелештә Х.Хәйруллин һәм В.Водовенко тарафыннан гитлерчыларның 100 дән артык солдаты һәм офицеры юк ителә.

1945 елның 22 февраль көнендә Хәбибулла Хәйруллин Бреслау (хәзер Польшаның Вроцлав шәһәре) янында барган бәрелешләрдә һәлак була, шундагы күмәк хәрбиләр каберлегенә җирләнә.

Өлкән сержант Хәбибулла Нәбиулла улы Хәйруллинга үлгәннән соң СССР Верховный Советы Президиумының Карары (10 апрель, 1945 ел) белән сугышта күрсәткән батырлыклары (“за образцовое выполнение боевых заданий командования на фронте борьбы с немецкими захватчиками и проявленные при этом отвагу и геройство”) өчен Советлар Союзы Герое исеме бирелә һәм Ленин ордены белән бүләкләнә.

Бөек Ватан сугышында Ил азатлыгы өчен гомерләрен биргән миллионлаган башка солдатлар кебек үк, Хәбибулла Нәбиулла улы кылган батырлыклар көрнәлелеләр, халкыбыз күңелендә бүген дә яши бирә. Алексеевскдагы Мемориаль комплекста аңа багышланган Мемориаль такта урнаштырылган, Коры Көрнәле авылы урамнарының берсе Хәбибулла Нәбиулла улы Хәйруллин исемен йөртә.

## *Касыйм Хәмзин*

Коры Көрнәле туфрагында туып үскән язучы, нәшрият хезмәткәре Касыйм Хафиз улы Хәмзин турында күпләребез белмидер дә, мөгаен. Әмма аның татар әдәбияты, мемуаристикасы һәм публицистикасы үсешенә керткән өлеше, әлбәттә, бәхәссез. Кызганыч ки, матбугат битләрендә әлеге шәхес турында мәгълүматлар юк диярлек, халкыбызның күп кенә күренекле уллары һәм кызларының тормышын,

эшчәнлеген яктырткан “Татар энциклопедия”сендә дә аның исемен очратып булмый. Шуларны да искә алып, бу китап битләрендә, кыскача гына булса да, Касыйм Хафиз улы Хәмзин турында язып үтүне дөрес булыр дип санадык.

Касыйм Хәмзин Коры Көрнәле авылы мулласы Хафиз Нуретдин улы Хәмзин гаиләсендә дөньяга аваз сала. Архив документларыннан күренгәнчә, Хәмзиннарның төп чыгышы ул чорда Лаеш өязенә караган Юеш Көрнәле авылыннан булып, Касыймның бабасы Нуретдин Сәйфетдин улы Хәмзин 1870 елның 16 сентябрендә Коры Көрнәленең икенче мәхәлләсе мәчетенә имам-хатыйп һәм мөгаллим итеп билгеләп куела[1]. Аның улы Хафиз Хәмзин 1894-1901 елларда Казанда “Госмания” мәдрәсәсендә белем ала, 1901-1904 елларда Казан татар укытучылар мәктәбендә укый, ә 1916 елның 31 июлендә, мәхәллә җыены карары белән, Коры Көрнәленең шул ук мәчетенә рәсми рәвештә мулла итеп тәгаенләнә[2].

Шундый зыялы гаиләдә тәрбияләнгән Касыйм Хәмзин үзе дә яшьтән үк әдәбиятка, иҗатка тартылып үсә. Моңа аның “егерменче еллар ахырларында Спас шәһәре мәктәбендә булачак язучы Абдулла Алиш белән, Казан педагогия институтында шагыйрь Шәйхи Маннур белән бер чорда укуы”[3] да сәбәп булгандыр күрәсең. Шулай ук апасы Гөлчәһрә Хәмзинаның күренекле шагыйрь Һади Такташның беренче хатыны булуы, Касыйм Хәмзинның шагыйрьне якыннан күреп-белүе, аның белән аралашуы уңай йогынты ясамый калмагандыр. Инде утызынчы елларда матбугат битләрендә

[1] Татарстан Республикасы Милли архивы. 2 нче фонд, 2 нче тасвирлама, 9829 нчы сакл. берәмлеге. 16 кгз.

[2] Татарстан Республикасы Милли архивы. 2 нче фонд, 2 нче тасвирлама, 9829 нчы сакл. берәмлеге. 4-6 кгз.

[3] Хәмидуллин Л. Күңелдә калганнар. – Казан: Сүз, 2007. – 186 б.

Касыйм Хәмзинның аерым бер шигырьләре һәм хикәяләре укучылар игътибарына тәкъдим ителә башлый.

Бөек Ватан сугышы чорыннан башлап җитмешенче елларга кадәр Касыйм Хәмзин иҗат эшеннән берникадәр читләшеп тора. "Моның сәбәпләрен аның киеренке партия эшенә бирелгәнлеге белән аңлатырга мөмкиндер, мөгаен. Авыл районнарында райком инструкторы, оештыру бүлеге мөдире вазифаларын үтәү аңа иҗат эшен ташлап торырга мәҗбүр иткәндер"[1]. Әмма иҗади һәвәслеге аны кабат әдәбиятка тартып китерә: узган гасырның җитмешенче-сиксәненче елларында төрле газета-журналларда нәшер ителгән хикәяләре ("Кадыйр бабай", "Бернәрсә дә бирмәде", "Махан бабай" һ.б.) укучылар күңеленә хуш килә. Тик шулай да Касыйм Хәмзинның таланты тулырак ачылган өлкә – публицистика, мемуар әдәбият юнәлеше дисәк, дөресрәк булыр. Татар укучысы нәкъ менә аның җылы истәлекләре аша Һади Такташ, Абдулла Алиш, Шәйхи Маннур, Габдерахман Минский кебек шагыйрь һәм язучыларыбызның тормыш, иҗат мизгелләре белән якыннанрак таныша.

Касыйм Хәмзин Казан, Ленинград шәһәрләрендә гомер итсә дә, туган авылы Көры Көрнәле турында гел кызыксынып, эзләнеп яши. Аның авыл тарихына, кешеләре язмышына караган фикерләрен туплаган "Көрнәле мишәрләре" исемле күләмле генә язмасы булуы да мәгълүм. Кызганыч ки, бу язма бүген югалган санала. Бәлки, киләчәктә табылып укучыларга ирешер, шуның белән бергә, Касыйм Хафиз улы Хәмзин да үз авылы тарихында лаеклы урынын алыр дип ышанасы килә.

[1] Шунда ук. – 186 б.

## *Сания Исмәгыйлева*



Коры Көрнәле авылыннан чыккан тагын бер талант иясе – Татарстанның халык артисткасы Исмәгыйлева Сания Нургали кызы. Ул 1931 елда колхозчы гаиләсендә дөньяга килә. Кечкенәдән үк матурлыкны тоя һәм күрә белеп, сәнгатьне яратып үсә. Бу табигый сәләте Сания Нургали кызын Казан Театр училищесына алып килә. 1951 елда аны уңышлы тәмамлап, Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында (ул чорда Республика күчмә театры) эшли башлый. Шул көннән алып ул меңләгән татар тамашачысының яраткан артисткасына әверелә. Сәхнәдә узган 35 еллык иҗат дәверендә Сания Исмәгыйлева тарафыннан 70 артык образ тудырыла. Шулар арасыннан татар әдәбияты классиклары Мәҗит Гафуриның “Кара йөзләр”ендә Галимә, Нәкый Исәнбәтнең “Рәйхан”ында Рәйхан, аның ук “Хуҗа Насретдин”ендә Сәхилә, Хәй Вахитнең “Беренче мәхәббәтендә” Камилә образлары артисткага зур танылу алып киләләр.

Сәхнәдәге уңышлары өчен 1979 елда Сания Нургали кызы Исмәгыйлевага “ТАССРның халык артисткасы” мактаулы исеме бирелә.

2015 елның 24 июнендә бакыйлыкка күчә.

## *Рәфгат Сафиуллин*

Сафиуллин Рәфгат Фәйзулла улы – партия-хуҗалык эшлеклесе, Татарстан Республикасы Кулланучылар җәмгыятләре берлеге идарәсе җитәкчесе, ТАССР Югары Советы депутаты, СССР халык депутаты, РСФСРның атказанган сәүдә хезмәткәре.



Ул 1929 елның 10 мартында Коры Көрнәле авылында Сафиуллин Фәйзулла Хикмәтулла улының ишле балалы гаиләсендә туа.

Бөек Ватан сугышының беренче көннәрендә үк атасы Фәйзулла агай үзе теләп фронтка китә, әмма аңа туган якларына кире әйләнеп кайтырга насыйп булмый, сугышта хәбәрсез югала. Атасыз калган биш балага, әниләренә сугыш һәм сугыштан соңгы авыр елларны узуы җиңелләрдән булмый. Әмма Рәфгат Фәйзулла улы сынаулар алдында куркып калмый: Куйбышев педучилищесендә белем алганнан соң Пединститутка укырга керә, аны уңышлы тәмамлап, авылда тарих укытучысы булып эшли башлый.

Һәр эштә камиллеккә омтылучан, гадел, үзенә һәм башкаларга таләпчән, тырыш егетне бик тиз күреп алалар, төрле җитәкче урынарда эш тәкъдим итәләр. Шул рәвешле, хезмәт юлын гади укытучыдан башлаган Сафиуллин Рәфгат Фәйзулла улы КПССның Алексеевск райкомы секретаре (1959-1962 еллар), халык депутатларының Чистай район Советы башкарма комитеты рәисе (1967-

1970 еллар) вазифаларын башкара. 1970 елда Татарстан Республикасы Кулланучылар җәмгыятләре берлеге идарәсе рәисе итеп билгеләнә һәм 22 ел дәвамында бу оешманың алыштыргысыз, легендар җитәкчесенә әверелә. Ул җитәкчелек иткән чорда республикада сәүдә-кулланучылар челтәре үсә һәм камилләшә, ил күләмендә алдынгы потребсоюз оешмаларының берсенә әверелә. Әлеге өлкәдә югары квалификацияле белгечләр һәм хезмәткәрләр әзерләү юнәлешендә дә Рәфгат Фәйзулла улы зур тырышлык куя. Ул 1987 елда Казан кооператив институтын ачуны кайгыртучы кешеләрнең берсе була.

Сафиуллин Рәфгат Фәйзулла улы 1963-1967 нче, 1971-1975 нче, 1980-1990 нчы елларда ТАССР Югары Советы депутаты, 1989-1991 нче елларда СССР халык депутаты итеп сайлана.

Алексеевск районы үзәгендәге бер урамга аның исеме бирелгән. Вафаты – 1995 елда.

## *Фәрит Шәйдуллин*



Шәйдуллин Фәрит Галимҗан улы – Әфган сугышы каһарманы.

Ул 1961 елда Алексеевск районы Коры Көрнәле авылында туып үсә. Кечкенәдән үк тыйнаклыгы, эш сөючәнлеге белән аерылып тора. Мәктәптә укыганда үзен тырыш, рәсем ясауга оста укучы итеп күрсәтә.

Узган гасырның сиксәненче елларында илдә искән “шомлы Әфган җилләре” Коры Көрнәле авылын да читләтеп үтми.

Шәйдуллин Фәрит, Гайнетдинов Мансур, Фассахов Равил кебек Көрнәленең асыл егетләре Әфган җиренә хәрби хезмәткә алыналар. Араларыннан Фәрит Галимҗан улы 1981 елның 29 октябрендә хәрби бурычын үтәгәндә соңгы патронына кадәр сугышып, тиңдәшсез бәрелештә батырларча һәлак була. Үлгәннән соң Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә.

Шәйдуллин Фәрит Галимҗан улы Алексеевск районы Халык депутатлары Советы Президиумының Карары белән 2002 елның 12 февралендә “Алексеевск районының шәрәфле гражданины” исеменә лаек була. Коры Көрнәледә аның истәлегенә Мемориаль такта ачыла, авылның бер урамына исеме бирелә.

### *Зиннур Бәширов*



Зиннур Закир улы Бәширов 1948 елның 20 апрелендә Коры Көрнәле авылында Мөхәммәтзакир белән Бәдерхәят гаиләсендә дөньяга килә.

Бәшировларның нәсел җепләре дүртенче буын бабалары Бәшир Әббазовка (1780-1842) барып тоташа, бүген йөртүче фамилияләре дә шушы шәхескә бәйле. Бәшир картның алты баласы булып, Җиһанша исемлесеннән әлеге нәсел үсеп киткән. Шунысын да искәртү урынлы булыр, архив документларына караганда, Бәшир Әббазовның Әхмәдша исемле улы 1842 елның 30 маеннан алып вафатына кадәр авылның 2 нче мәхәлләсе мәчетендә мөәззин булып торган.

Зиннур Закир улы Бәширов әүвәл Коры Көрнәле авылы мәктәбен, 1965 елда 6 нчы номерлы ГПТУны тәмамлаганнан соң, Казан электрон исәпләү машиналары заводына токарь булып эшкә урнаша. 1968 елдан алып 1973 елга кадәр А.Е. Арбузов исемендәге органик һәм физик химия Институтында токарь, өлкән механик хезмәтләрен башкара. Шул ук елларда Зиннур Закир улы белемен камилләштерү өстендә дә эшли: 1975 елда Казан инженер-төзелеш институтын тәмамлап, алга таба хезмәт юлын мастер, инженер, "Казанхимстрой" трестының бүлек җитәкчесе урынбасары, "Татплодовощхоз" оешмасының баш инженеры вазифаларында уңышлы дәвам итә.

1987 елда ул ТАССР Госагропром оешмасында бүлек начальнига, Халык Мәгариф министрлыгының төзелеш Идарәсе рәисе (1988 ел), КПО СВМ "Терминал"ның генераль директоры урынбасары (1989-1995 еллар), Казан шәһәре администрациясенең торак сәясәте Идарәсе башлыгы, 2006 – 2011 еллар аралыгында Казан шәһәре Авиатөзелеш районы җитәкчесенең беренче урынбасары булып эшли. Казан шәһәренең Башкарма комитеты рәисе киңәшчесе (2011-2014 еллар) булып тора. Нинди генә югары җитәкчелек урыннарында эшләсә дә, хезмәттәшләре Зиннур Закир улы Бәшировны кече күңелле, киң холыклы, гадел һәм ярдәмчел, көчле оештыру сәләтенә ия фидакарь шәхес һәм җитәкче булуын искә алалар.

Республикабыз алгарышы өчен озак еллар намус белән үтәгән хезмәтләрен исәпкә алып, Зиннур Бәшировка "Хезмәт ветераны", "Татарстан Республикасы торак-коммуналь хуҗалыгының атказанган хезмәткәре" мактаулы исемнәре бирелә. Ул күпсанлы Мактау кәгазьләре, "Казанның 1000 еллыгы истәлеге" юбилей медале белән бүләкләнә.



**Бәшировлар гаиләсе нәсел шәҗәрәсе.**
**Төзүче – З.З. Бәширов. 2018 ел.**

# Коры Көрнәле авылы кешеләре Бөек Ватан сугышында

## *Сугыш кырларында һәлак булган авылдашлар исемлеге*

1. Әбүзәров Габдулла Мөсалим улы
2. Әбүзәров Зәкиулла Зиннәтулла улы
3. Әсәдуллин Минневәли Әсәдулла улы
4. Әхмәтов Йосыф Юныс улы
5. Барышов Миңсәяр Нургали улы
6. Барышов Шәйхелислам Мөсләхетдин улы
7. Бакиров Мөбәрәкҗан Сафа улы
8. Бәширов Сәхабетдин Хөснелгата улы
9. Бәширов Хәбибрахман Габдрахман улы
10. Вәлиев Кәрим Вәлимөхәммәт улы
11. Вәлиев Мостафа Вәлимөхәммәт улы
12. Вәлиев Нургаяз Нургали улы
13. Вәлиев Рәшит Абдулгани улы
14. Вилданов Ибраһим Хуҗиәхмәт улы
15. Габитов Кәрим Габдулла улы
16. Галиев Миңнегол Мияссәр улы
17. Галиев Миңнеислам Миңсәяр улы
18. Галиев Нурһада Мияссәр улы
19. Галимов Нургали Корбангали улы
20. Галимов Нурмөхәммәт Корбангали улы
21. Галимов Нургаен Котбетдин улы
22. Галимов Кәрим Ибраһим улы
23. Гатауллин Зиннәтулла Хикмәтулла улы
24. Гатин Хәйдәр Гата улы
25. Гибатов Исхак Хәйрулла улы
26. Гыйләҗов Ибраһим Гыйләҗетдин улы
27. Гиниятуллин Галимҗан Нурмөхәммәт улы
28. Гиниятуллин Фәезхан Зиннәтулла улы

29. Гомәров Садыйк Фатыйх улы
30. Заббаров Габделхак Мәннан улы
31. Замалетдинов Хәмит Гыйлметдин улы
32. Зарипов Габдрахман Зарифулла улы
33. Зарипов Ибраһим Зарифулла улы
34. Ибәтуллин Гыйбадулла Ибәтулла улы
35. Ибәтуллин Миңгәрәй Ибәтулла улы
36. Ибәтуллин Нургаяз Ибәтулла улы
37. Ибәтуллин Хафиз Ибәтулла улы
38. Ибраһимов Садретдин Хәйретдин улы
39. Кәбиров Әсхать Зиннәтулла улы
40. Кәбиров Шәрифулла Галимулла улы
41. Казаков Гарәфетдин Фәрхетдин улы
42. Казаков Ислам Җәләлетдин улы
43. Казаков Миңнеһади Дәүләтхуҗа улы
44. Казаков Нурхада Нуретдин улы
45. Камалиев Нурислам Гаяз улы
46. Карабашев Харис Нуретдин улы
47. Котлин Зәкиулла Йосыф улы
48. Медведев Сәетнәсим Зиятдин улы
49. Медведев Габделхәмит Гыйльметдин улы
50. Медведев Фазулла Шәрәфетдин улы
51. Миндебаев Сәмигулла Миңнебай улы
52. Мусин Нәҗип Вазыйх улы
53. Мусин Шаһгаләм Садыйк улы
54. Нәҗмиев Бәдертдин Минһаҗетдин улы
55. Насыбуллин Ибраһим Заһидулла улы
56. Насыбуллин Шәфигулла Заһидулла улы
57. Нәфигин Фоат Зарифулла улы
58. Нуриев Гарифулла Нуретдин улы
59. Ризванов Сәмигулла Гыймран улы
60. Ризванов Хөснелгата Гилҗман улы

61. Сафиуллин Сәмигулла Сафиулла улы
62. Сафиуллин Фазулла Хикмәтулла улы
63. Салахиев Нурһада Гаяз улы
64. Сибатов Фәйзрахман Гаяз улы
65. Сираев Нәбиулла Сиражетдин улы
66. Ситдиков Әсхәт Нух улы
67. Ситдиков Мөдәррис Закир улы
68. Сөнгатуллин Галиулла Заһидулла улы
69. Сөнгатуллин Нигъмәтулла Сөнәгатулла улы
70. Сөнгатуллин Зиннәтулла Гыйззәтулла улы
71. Фәтхетдинов Фәрхетдин Фәтхетдин улы
72. Хәйдәров Нурхада Хәйдәр улы
73. Хәйдәров Хафиз Хәйдәр улы
74. Хәйруллин Хәбибулла Нәбиулла улы
75. Хәкимов Гариф Харис улы
76. Хәкимов Шакир Харис улы
77. Хисаметдинов Гыйләжетдин Җәләлетдин улы
78. Хисаметдинов Кәрим Җәләлетдин улы
79. Хөсәенов Гарифулла Ибәтулла улы
80. Хөсәенов Шәрифулла Ибәтулла улы
81. Хөсәенов Гыйбадулла Әсәдулла улы
82. Хөсәенов Кәлимулла Әсәдулла улы
83. Хөснуллин Галимҗан Нотфулла улы
84. Хөснетдинов Адиулла Лотфулла улы
85. Хөснетдинов Фәезхан Лотфулла улы
86. Хөснетдинов Кәлимулла Зиннәтулла улы
87. Хөснитдинов Фәрхетдин Шәмсетдин улы
88. Шәйдуллин Хафиздин Мәҗидулла улы
89. Шәйдуллин Гарифулла Мәҗидулла улы
90. Шәйдуллин Миңгәрәй Мәҗидулла улы
91. Шавгивәлиев Әбүбәкер Кәшафетдин улы
92. Шәйхетдинов Нургали Шәйхетдин улы
93. Шәйхетдинов Садертдин Сәхабетдин улы

### *Бөек Ватан сугышында катнашучылар исемлеге*[1]

1. Ахметов Минһаҗетдин Хәбибетдин улы (1924-2008)
2. Ахметов Мөстәкыйм Юныс ул (1903-1987)
3. Әбүзәров Зиннәтулла Насыйбулла улы (1892-1984)
4. Әбүзәров Насибулла Шәрифулла улы (1922 - 2000)
5. Бакиров Галимҗан Мөхәмәтсафа улы (1893-1968)
6. Барышев Садыртдин Бәдертдин улы (1914-1973)
7. Барышов Ислам Хөснелгата улы
8. Барышов Нурулла Гатаулла улы
9. Бәширов Закир Хөснелгата улы (1902-1960)
10. Бәширов Шакир Хафиз улы
11. Валиуллин Габдулхай Минневәли улы (1904-1984)
12. Вафин Харис Юсуп улы (1912-1988)
13. Вәлиев Мингата Нургали улы (1919-1989)
14. Вәлиев Нургаен Нургали улы (1926-1994)
15. Вәлиев Садыйк Закир улы (1919-2008)
16. Вәлиев Шакир Закир улы (1914-2005)
17. Габитов Хафиз Габидулла улы
18. Гайнетдинов Гарафетдин Сәгытдин улы (1918-1967)
19. Гайнетдинов Зиятдин Гайнетдин улы (1912-198?)
20. Гайнетдинов Минхаҗетдин Гайнетдин улы (1909-1988)
21. Гайнетдинов Сахабетдин Гайнетдин улы (1902-1979)
22. Гайнуллин Габдулла Галиулла улы (1914-1980)
23. Гайнуллин Зиннәтулла Ярулла улы (1908-1982)
24. Гайнуллин Хәбибулла Галиулла улы (1907-1999)
25. Галеев Нәҗип Госман улы
26. Галеев Хазип Госман улы
27. Галеев Харис Госман улы
28. Галиев Минсаяр Мияссар улы (1898-1981)

[1] Исемлек Фатыйхова Резидә Сәлахетдин кызы мәгълүматлары буенча төзелде.

29. Галиев Нургаяз Гәрәй улы (1902-1967)
30. Галимов Габделвәли Габделгани улы (1909-1989)
31. Галимов Миннегол Корбангали улы (1908-1996)
32. Галимов Фәсахетдин Фәрхетдин улы (1907-1983)
33. Ганиев Мөхамәтзакир Абдулгани улы (1892-1969)
34. Гатауллин Фазулла Хикмәтулла улы (1923-1997)
35. Гафиятуллин Касыйм Гафиятулла улы (1917-2000)
36. Гибатов Галимҗан Халиулла улы (1924-26.08.1959)
37. Гибатов Хәсән Хәйрулла улы (1905-1988)
38. Гибатов Хөсәин Хәйрулла улы (1909-1994)
39. Гиниятуллин Абдулла Зиннәтулла улы (1923-1993)
40. Гиниятуллин Миннулла Нигъмәтулла улы (1927-2001)
41. Гиниятуллин Мөбәрәкҗан Нурмөхәммәт улы (1923-1993)
42. Гиниятуллин Нигъмәтулла Гиниятулла (1898-1978)
43. Гиниятуллин Нурммөхәммәт Гиниятулла улы (1905-1998)
44. Замалиев Габделкадир Вагиз улы (1902-1974)
45. Замалиев Габделтаһир Вагиз улы (1906-1977)
46. Замалиев Садыйк Вазих улы (1913-1998)
47. Зәбиров Гатиятулла Гафиятулла улы (1893-1966)
48. Ибатуллин Идиятулла Ибәтулла улы (1906-1976)
49. Ибатуллин Хикмәтулла Ибәтулла улы (1904-1955)
50. Исмагилов Нургаен Нургаяз улы
51. Исмагилов Нургали Исмәгыйль улы (1895-1962)
52. Казаков Шахгаләм Нигъмәтша улы (1924-1949)
53. Камалиев Садрислам Гаяз улы
54. Карабашев Зыятдин Җәлалетдин улы (1898-1984)
55. Карабашев Сәлахетдин Җәлалетдин улы (1903-1978)
56. Кәбиров Закиулла Зиннәтулла улы (1926-2000)
57. Маханов Зиннәтулла Заһидулла улы (1902-1966)

58. Маханов Минһаҗ Заһидулла улы (1904-1979)
59. Маханов Нигъмәтулла Хәбибулла улы (1918-2003)
60. Мортазин Әхәт Абдулхак улы (1919-1999)
61. Мортазин Мөдәрис Мортаза улы (1906-1947)
62. Мортазин Хазип Мөзип улы
63. Музафаров Заһир Таһир улы (1904-1975)
64. Музипов Хазип Мөзип улы
65. Мусин Әхмәтвәли Вазих улы
66. Мусин Камил Кәрим улы
67. Мусин Касыйм Садыйк улы (1914-1984)
68. Мусин Хазип Вазих улы
69. Мусин Шәвәли Карим улы
70. Мускаев Хөҗҗәт Нурмөхәммәт улы (1923-1991)
71. Мухаметшин Котбетдин Хөснетдин улы (1923)
72. Мухаметшин Сагетдин Хөснетдин улы
73. Назмиев Фәрхетдин Минһаҗетдин улы
74. Нәбиуллин Минһаҗетдин Фатых улы (1911-2004)
75. Нуриев Нургаен Фәтхетдин улы
76. Нуруллин Нигъмәт Зиннәтулла улы (1924-1992)
77. Рәхимов Миннабин Галим улы (1901-1981)
78. Ризванов Нургата Гыйльман улы (1907-1986)
79. Сибатов Нигъмәтулла Галиулла улы (1907-1992)
80. Сираев Имаметдин Гыйльметдин улы (1906-1989)
81. Фассахов Минһаҗетдин Фәсахетдин улы (1901-1985)
82. Фассахов Садертдин Фәсахетдин улы (1898-1962)
83. Фассахов Фәттахетдин Котбетдин улы
84. Фәтхиев Талибулла Мизбахетдин улы (1923-1997)
85. Фәтхиев Хәбибулла Мизбахетдин улы (1925-2004)
86. Харисов Харас Харис улы (1905-1948)
87. Хәбибуллин Габдулла Асадулла улы (1909-.1982)
88. Хәбибуллин Зәйнулла Асадулла улы (1905-1976)
89. Хәйруллин Нәбиулла Хәйрулла улы (1893-1975)

90. Хисаметдинов Зыятдин (1896-1975)
91. Хисамов Ислам Хисам улы (1919-1997)
92. Хусаинов Заһидулла Асадулла улы (1915-1981)
93. Хусаинов Хадиулла Ибәтулла улы (1920-1990)
94. Хуснуллин Хәлиулла Хөснулла улы
95. Хуснутдинов Хикмәтулла Хөснетдин улы (1909-1979)
96. Шавалиев Зиннәт Мингали улы
97. Шамсутдинов Нургата Фәйзулла улы (1912-1997)
98. Шарипов Ильяс Якуп улы (1923-2006)
99. Шарипов Якуп Исмагыйль улы (1895-1976)
100. Шәйхетдинов Минһаҗ Сәхабетдин улы
101. Шигабетдинов Җәлалетдин Афзалетдин улы (1923-1990)
102. Юсупов Хаммат Йосыф улы
103. Яруллин Кәлимулла Ярулла улы (1898-1957)

# Кушымта. Коры Көрнәле авылы турында язмалар

### *Такташ каены*

Филология фәннәре докторы Гомәр абый Саттаров диплом эшләрен студентны кызганып яздыручылардан түгел. Ул үзе бер минут тик торуны белми. Лекцияләрендә, кем әйтмешли, авызыннан ут чәчә. Сөйләм тел осталары – чәчәннәр менә шундый булгандыр, мөгаен. Без аның авызына карап шаккатып утыра торган идек. Һәр җөмләсе безнең өчен бер яңа дөнья. Безне ул үзе дә, ул укыта торган фән дә бөтенләе белән җәлеп итте. Икенче курстан башлап микротопонимия, антропонимия буенча материаллар туплый башладык, күпме күләмдә, ничәмә тапкыр курс эшләре язылды. Моңа, әлбәттә, район газетасында эшләү дә ярдәм итә иде. Һәр авылда буласың, кемнәр белән генә сөйләшмисең, шушы юнәлештә авторлар туплыйсың, материалларын газетада бастырасың. […]

Алда дүрт айлык диплом чоры. Без тагын юлда. Әлки, Алексеевск районы авылларының тарихы, әрәмә-елга, тау-чокыр атамалары, кеше исемнәре, халыкның гореф-гадәтләре, үткәне һшм бүгенгесе – тагын әллә нәрсәкәй ләр шунда, берсе дә күз уңыннан ычкынмасын. Чыннан да шулай икән бит, аралашсаң – күпне беләсең, күпне ишетәсең, күп йөрсәң – тагын да күҗрәк күрәсең икән ич. […] Мисал өчен Алексеевск районындагы Коры Көрнәле авылына гына тукталып үтик.

Автор нәрсә әйтергә тели, Такташ каенын зарыгып көткәндә нигә боларны сөйләп тора, дип түземсезләнмәгез.

Авыл Кәрнәлке – Көрнәле елгасының ике ярындагы биек-биек таулар итәгенә һәм түбәсенә утырган. Бу җир элек сазлыклар һәм калын урманнар белән капланган була.

Авылның борынгы исеме Көртмәле (көртмәле – мүк җиләге (клюква). Татар теленең диалектологик сүзлеге, Татарстан китап нәшрияты, Казан, 1969, 276 бит) булган дигән караштa калу хаклырак шикелле. Әйткәнебезчә, көртмәле – мүк җиләге төшенчәсен белдерә, "рт" тезмәсе борынгы төрки телгә хас күренеш. Хәзерге татар телендә бу тезмәдәге "т" тартыгы төшеп калган. Борынгы төрки телдә: йомыртка, себертке, чыбырткы һ.б. хәзерге татар телендә: йомырка, себерке, чыбыркы һ.б. булып йөриләр. Көртмәле сүзендә дә "рт" тезмәсеннән "т" тартыгы төшеп калу нәтиҗәсендә, көрмәле, м-н борын авазлары чиратлашу аркасында, көрнәле әйтелеше барлыкка килгән. Көртмәле – Кәрнәле исеме башта мүк җиләге күп үскән сазлыкка (микротопонимга) бирелгән. Аннан авыл исеменә күчкән булырга тиеш.

Авыл халкы арасында мондый риваять тә саклана. Башлап урын карарга килүчеләр, таудан төшәләр дә, бер иркен әрәмәгә утырып ял итәләр. Янә киткән чакта борылып: "Утырган урын күренәме?" – дип бер-береннән сорашалар икән. Аннары барысы берьюлы: "Күренә әле, күренә", - диләр. Авылның исеме дә шуннан: күренәле дип аталган, имеш. Монда редукция күренеше. Табагач (таба-агач), алмагач (алма-агач) дигән сүзләрдә уртада килгән ике сузыкның берсе төшеп калса, монда да шулай: күренә-әле (күренәле). Беренче иҗектән соңгы сузык аваз "е" төшеп кала. Соңыннан Күрнәле-Көрнәле дип атала башлый, "ү" белән "ө" авазы чиратлашалар, дип тә аңлатырга мөмкин булыр иде. Әмма без беренче караштa калабыз.

Авылның шәҗәрәсе җиде буыннан тора. Әмма болар тулы буыннар түгел. Авыл бик борынгы. Андагы язулы кабер ташлары да моны раслыйлар. Аларның берсенә: "Әлмәле би Кюар", - дип язылган. Бу сүзләрне авыл картлары борынгы Кюар шәһәре падишасы исеме белән аңлаталар.

Коры Көрнәленең борынгысы гына түгел, безнең көннәре дә кызыклы. Авыл халкы бөек шагыйребез Һади Такташ истәлекләрен дә бик кадерләп саклый икән. Шагыйрьнең тормыш иптәше Гөлчәһрә (халык Гөлчирә, ди) ханым шушы авылда туып үсә. Бу истәлекләрне Хәлимә апа Мусина яхшы хәтерли.

“Без Гөлчирә белән бик дус кызлар идек, - ди Хәлимә әби ул вакытларны искә алып. – Укырга китәргә дә бергәләп җыендык. Әти-әниләрдән яшереп май саттык, юлга акча җыйдык. Ләкин мин түзә алмадым, качып киткән тәкъдирдә, ата-ана каргышыннан куркып, серне әтиләргә чиштем. Билгеле, алар мине укырга җибәрмәделәр. Гөлчирә яшертен генә авылдан чыгып китте. Аннары авылга еш кайтып йөри иде. Сөйләшә, серләшә идек. Бер очрашуда ул миңа Һади исемле егет турында сөйләде. Такмаклар чыгара, диде”.

Бердән-бер көнне алар икәүләшеп авылга кайтып төштеләр. Өйләнешмәгәннәр иде әле. “Гөлчирә егет күрсәтергә кайткан” дип сөйләнделәр авылда. “Әйдә ярар. Чәчен кистерер, балагын озайтыр” дип Һади турында сөйләүчеләр дә булды.

Без өчәүләп болынга чыктык. Озак йөрдек. Һади безгә такмаклар чыгарырга куша. “Теләсә ничек чыгарыгыз, аннары төзәтербез”, - ди ул. Без күп такмаклар әйттек. Ул, кайтты-кайтты да, авыл башындагы әнә шул (Хәлимә әби кулы белән төртеп күрсәтте) тау битендәге каен төбенә тезләрен чәнчеп утырып, озак итеп нәрсәдер язды. Аннары шул каенга сөялеп (хәзер дә “Такташ каены” дип йөриләр – Ә.Г.) безгә шигырь укыды. Анда “ак каен” дигән сүзләрнең еш кабатлануы хәтердә калган”.

Хәлимә әби ул вакытта Такташ төзәткәләп биргән шигырьләрне әле дә хәтерли, яттан белә. Дөрес, ул аларның күбесен оныткан, исендә калганнары мондыйлар:

Көзге кара төн иде,
Сызгыра каты җиле,
Шыбыр-шыбыр яңгыр ява,
Эч поша әллә нинди.

Кайта мужик чыланып,
Лап-лап басып урамнан,
Өсте юка, туңган мескен,
Кызганырлык моңланган.

Әйтә: анам карт минем
Көтә торгандыр мине.

Өйгә кайта тиянеп,
Бераз уйлый сөялеп,
Туңып кайтып өйгә керә,
Бер сүз дәшми оялып.

Тәрәзәләр карындык,
Идән чүпле абынырлык,
Өй үтәли җилләр өрә,
Алла бирсен сабырлык.

Әнекәем, инде бәхил бул,
Ни кылаем инде шул,
Фәкыйрьлегем каты шул!

Күк ачык, күк зәңгәр
Бер болыт йөзмидер,
Кичке төн, ай нурлы
Күзләрне дә кисмидер.

Шул чакта, тармакта
Куаклар астында,
Табигать патшасы мени
Сандугач тик сайрыйдыр.

Сайрый ул моңланып,
Урманны яңрата;
Ай тулы, ай нурлы
Дөньяңны яктырта.

Сүз дә юк, бу шигырьләрне без турыдан-туры Такташныкы дияргә җыенмыйбыз. Бәлки алар ул вакытта бәет формасында әйтелеп (бигрәк тә беренчесе) йөргәндер, аларны күпләр белгәндер. Телдән-телләргә күчүе дә ихтимал. Ләкин ни генә булмасын, Хәлимә апа әйтеп яздырган юлларга Такташ каләме тими калмаган. Такташ, Гөлчирә һәм Хәлимә апалар боларны өчәүләп җыр итеп көйләгәннәр. Һәм еш җырлаганнар.

*Әсрар Галиев*

## *Такташ һәм аның гаиләсе*[1]

Әйе, Такташның шигъри юллары бер укуда күңелдә кала. Чокыр-чакырга төшмисең, сүз түмгәкләренә абынмыйсың, сөртенмисең. Киресенчә, ләззәткә-рәхәткә чумасың.

Ул борчулы минутларда да үзенә ихтирам уята иде. Бервакыт шундый тамаша булып алды. 1927 ел. Такташның кәләше Гөлчәһрә Хәмзина яңа күлмәк сатып алып кайткан. Материясе дә шәп, төсе дә аллы-гөлле, әмма чабуы ертык. Нәкъ арт яктан ярты аршын чамасы икегә ярылган.

Кич. Театрга тамаша карарга барырга әзерләнәләр. Һади

[1] Мәкалә “Безнең Мирас” журналының 2015 ел, 2 нче санында дөнья күрә. Чыганак: http://beznenmiras.ru/taktash-hem-anyn-gailese/ [Мөрәҗәгать итү датасы: 02.08.2018].

сырланып тормый. 10-15 минутта киенеп, галстук тагып, тройной одеколон сөртенеп чыга. Әмма яшь кәләш назлана, тегесен сала, бусын ала.

– Галя, син нәстә, әллә ертык күлмәк киеп театрга, да?..

– Ертык түгел, яңа мода.

– Ташла, пожалуйста, сурьёзно әйтәм. Арттан күренә.

– Һади җаным, син не понимаешь, бу – французская мода.

Такташ тын гына басып тора. Елмая, күксел чәчен сыйпап ала, селкенеп куя. Бер адым Гөлчәһрәгә таба атлый. Ярык чабуга кулын тидереп ала.

– Каерма!

– Галя, тыңла. Ничек залдан үтәргә? Анда интеллигенция, Фатих Сәйфи, Нигъмәтиләр, Болак арты татарлары. Сал, кимә!

– Низачто!

Песи балалары идәндә бутала. Яшь кәләшнең чабуына сикерә. Аларга кызык. Ә Такташ рәхәтләнеп көлә.

– Брысь! Атеистлар! – ди Гөлчәһрә.

Ниһаять, чирек сәгатьтән бүлмәдә тынлык урнаша.

Икенче көнне «Җырым сиңа булсын» дигән шигырь туа. Ул яшь кәләшкә төбәп язылган.

«Әйтче, кызый, болай киенергә
Нинди шәйтан сине өйрәтте?
Инде тездән узган күлмәк итәкләрен
Ертык ясау нигә кирәкте?»

Шагыйрь – тәрбияче, педагог, мөгаллим, үгет-нәсыйхәтче.

Түбәндәге юллар Гөлчәһрәгә, хатынына, җәмәгатенә хат булып яңгырый. Ул гаиләнең бердәмлеген, бөтенлеген саклап калырга тырыша.

«Яшьлегемне үзем
теләп бирәм кулыңа,
Ләкин тыңла мине,

иптәш тә бул миңа,
Ана да бул минем улыма».

Бервакыт Такташ артлы урындыкка утырып, фотога төшә һәм карточканы Гөлчәһрәгә Мәскәүгә җибәрә.Фотоның артына шундый юллар яза:

«Кара, Галя, синең картың
Нинди матур булып утырган.
Кара, башкаларга аны алмаштырма,
Кадерен белеп яшә, чукынган».

Шагыйрь, үзеннән битәр, кешеләр турында кайгыртучан иде. 1928 ел иде булса кирәк. Шагыйрьнең каенанасы Зәкия Такташ фатирында кыш чыкты. Русия кышы салкын, ә Зәкия Үзбәкстан һавасына күнеккән. Казан урамына чыкса, бөрешеп, борын очын тотып кайта. Бу хәл Һадины борчый.

– Әни, әйдәле, магазинга. Татторгка, ерак түгел, Проломныйда гына.

– Нәрсәгә, Һади?

– Сиңа тун карыйбыз.

– Алла, акча юк бит, Һади.

– Бурычка алырбыз, минем кредиторлар байлар.

Шаян сүзләр сөйли-сөйли Һади кыска тун сыман нәрсә кия, Зәкия яшел ефәк үзбәк бишмәтен каптыра. Бер сәгать тә үтми, пыхылдап торган тун алалар.

Коръәннең бер аятендә шундый җөмлә бар: «Мин адәмне вә җеннәрне сынау өчен яралттым». Такташ та шундый сынау астында кала. Шагыйрьнең бертуган сеңлесе Хәнифәне уку йортыннан чыгаралар. Янәсе, кулак кызы, укырга хакы юк. Сеңлесен аклау өчен шагыйрь атна-айлар буе анда чаба, монда йөгерә. Тегеннән справка, моннан документ җыя. Ниһаять, Хәнифәнең әтисе Хәйрулла абзыйның, әниләре Шәмсениса апаның кулак булмавы ачыла. Уртадан түбән хуҗалыклы крәстиәннәр икән. Нәтиҗә шул: Хәнифә башка уку йортында

укуын дәвам итә. Шагыйрь тынычлана. Күтәренке күңел белән шигырь яза.

«Партиягә кертмәделәр инде,
Комсомолга дисәм, алмыйлар,
Пионерга яшең үткән диләр,
Менә ничек мине алдыйлар.

Әмма тынычлану кыска гомерле булды. Мәскәүдән, Гөлчәһрәдән хат килеп төште: «Һади! Мине мулла кызы дип, университеттан чыгарырга телиләр».

Мәсьәлә болай булган. Гөлчәһрәнең әтисе Хафиз үзбәкләрнең милли киемен киеп, фотога төшкән. Чапанга охшаган яшел буй-буй тасма бишмәт, чалмага охшаш бүрек, килешлерәк булсын өчен җиз кашлы таяк та тоткан. Портретның бер нөсхәсен Мәскәүгә, кызына җибәргән. Гөлчәһрә аны дус шәрикләренә күрсәтә. «Настоящий ишан, мулла» – ди берсе. Кызыл авызга шул җитә кала. Муллалар – сыйнфый дошманнар. Карточка комсомол комитетына, деканатка мәгълүм була. «Жаль, отличница была», – ди кемдер.

Гөлчәһрә: «Мин мулла кызы түгел. Әти үзбәк милли киемендә төшкән», – ди.

– Докажи! – диләр.

Такташ та, Гөлчәһрә дә документлар белән «коралланa» башлыйлар. Көрнәле дигән авылга да сәяхәт кылалар. Ниһаять, Гөлчәһрә аклана. Хафиз бервакытта да мулла булмаган. Ул – гап-гади укымышлы интеллигент. Кыз укуын дәвам итә һәм МДУны яхшы, бик яхшы билгеләренә генә тәмамлый.

Нишләмәк кирәк, сыйнфый көрәшнең кызган чаклары иде. Бу дөньяда хак та, ялган да кулга-кул тотынып йөриләр. Бигрәк тә өлкән затларга карата имеш-мимешләр күп була. «Казан утлары» журналының 1984 елгы 4 нче санында бер яшь

автор Такташ гаиләсе турында болай яза: «Өй җиһазларын шагыйрь үз күңеленә хуш килгәннәрен сайлап үзе сатып алган булган, чөнки аның беренче хатыны аерылышкан чакта соңгы урындыкка кадәр үзе белән алып киткән. Мәскәүгә барып урнашырга карар кылган…» һәм башкалар… Менә бу – берниниди киртәгә сыймый торган чеп-чи хата. Мин Такташ фатирында күп булдым. Анда күз төшә һәм бүлешә торган җиһаз юк иде. Булган тәкъдирдә дә Такташ һәм аның гаиләсе бу кыргыйлыктан югары тордылар. Автор Такташ музее турында яхшы фикер күрсәтә. Музей кирәк. Шагыйрь торган йорт урынында университет бинасы калкып чыкты. Хәсән Хәйри китабында 173 нче биттә шундый юллар бар: «Такташ яшәгән нигездә университетның яңа биек бинасы төзеләчәк һәм андагы ике бүлмә Такташ музеена биреләчәк икән». Яхшы фикер. Әгәр дә Татарстан хөкүмәте җиң сызганып уйлап караса, бик шәп булыр иде.

Дөрес, гаиләдә ниләр генә булмый. Тәкъдир, язмыш һәркемнең аяк астында йөри. Алар аерыла. Такташ Гөлчәһрә Мансуровага өйләнә. Уңган, чибәр, сабыр кыз була ул. Беренчесе дә, икенчесе дә Гөлчәһрә. Ләкин Һади икенче җәмәгате белән 12-13 ай гына торып кала – шагыйрь тиф авыруыннан дөнья куя. Без инде аның иҗатына да, гаиләсенә дә тел тидермик. Берсен күтәреп, икенчесен түбәнсетмик. Шагыйрьнең сеңлесе Хәнифә Такташева миңа болай диде:

«Гөлчәһрә Хәмзина Такташтан аерылып китүне гомер буе бәхетсезлек, дип санады. Соңыннан да безнең белән бәйләнеш-араны өзмәде».

Бу юлларга һичнәрсә өстәмим. Фәкать бер җөмлә белән чикләнәм. Ул төскә-биткә чибәр, урыс теленә оста, үткен зиһенле хатын-кыз буларак, горур иде. Артык төчеләнү булып тоелмасын, Такташ та, аның әти-әнисе дә, барлык туганнары да яшь кәләшкә олы мәхәббәт белән карады.

***

Бу язманы тәмамлап, радиога бармакчы идем. Кемдер ишек шакыды. Ачтым, ят кеше. Киеме мосафирларныкы. Аркасында – брезент капчык. Авыр булырга охшый.

– Мөмкинме?

– Пожалуйста.

Керде. Йөкне төшерде.

Чамалыйм, төсмерлим дә кебек, ләкин тел әйләндерергә кыюлыгым җитми. Вакыт уза тора. Ул миңа, мин аңа карыйм. Янәсе, сүзсез танышырга телибез, сынашабыз. Мосафир хәрәкәтчел, капчыгын төзәтә, җайлабрак куя, каешларын да рәтли. Секундлар чаба да, чаба.

– Танышсызмы, Касыйм әкә?

– Чамалыйм да кебек, но мин тәкә түгел, туган.

Елмая, фуражкасын сала, кая эләргә җай эзли.

– Тәкә, димим, әкә, дим.

– Ялгышаммы, юкмы, Сез Такташ бит?

– Әйе, Касыйм әкә, мин Такташ, Рафаэль Такташ.

Нишләптер, изрәп төштем. Кулъяулыгымны алып, маңгай тиремне сөртеп алдым. Әллә нәрсә булды үзем белән. Күз алдымнан яшь чагым, рабфакта укыган чагым, 3 яшьлек Рафаэльнең агач атка атланып төшкән рәсеме-портреты үтеп китте. Хәзер минем алдымда атасыннан ике мәртәбә олы, киң маңгайлы, зур башлы, ак сакаллы кеше басып тора. Йөзенә тагын бер карап алдым. Әйе, чырае нәкъ Такташныкы, этисенеке, ә күзләре, күзләре яшькелт, Гөлчәһрәнеке.

– Түргә уз, түргә, Рафаэль, әйдә, әйдә, – дидем. Мин аны беренче мәртәбә 1928 елларда күрдем. Менә хәзер 1990 ел. Күпме язлар, көзләр үткән, ничә мәртәбә тәңкә карлы кышлар узган.

– Касыйм әкә, йомшарырга ярамый, бөтен нәрсә ага, бөтен нәрсә үзгәрә, – диде Рафаэль.

Чирек сәгатьтән без сый-нигъмәт куйган өстәл тирәсендә идек.

– Туганнар каберстанына, әти каберенә чәчәкләр куйдым, – диде Рафаэль.

Мин үз белгәннәремне сөйләдем.

– Мин әтинең авылында, Сыркыдыда да булдым, – дип дәвам итте Рафаэль. – Өй сакланмаган. Мордовия җөмһүрияте дә, Татарстан хөкүмәте дә нигезне саклау өчен чара күрмәгән. Казан каласында да әти яшәгән бина сакланмаган…

Без төрле хәлләрне искә төшердек. Рафаэль әнкәсе карамагында үсә. Ленинград сәнгать академиясен тәмамлый. Үзбәкстанда Сәнгать академиясендә эшли. Үзбәкстанның атаклы сәнгать галименә әйләнә. Әмма үзе турында сөйләргә яратмый. Әнкәсе Мәскәү университетының юридик факультетын тәмамлагач, прокурор, җаваплы партия хезмәткәре булып эшләгән. Сугыш елларында Үзбәкстанның юстиция министры булып хезмәт иткән.

Без озак сөйләштек. Аннары ул Иделгә, дачага китте. Аның авыр йөге рәссам кораллары булган икән. Ул ясаган рәсемнәр, пейзаж, табигать күренешләре җәмәгатьчелеккә яхшы мәгълүм, сәнгать турында язган кайбер мәкаләләре чит телләргә дә тәрҗемә ителгән.

Соңгы сүз итеп шуны әйтик: тарихка фальш-ялган кермәсен. Зур шагыйрь вафат булганга 60 ел үтте. Әмма, ни кызганыч, бер матди истәлек тә юк. Шул да мәгълүм булсын: каенатасы Хафиз 1940 елда җир куенына керде (Ташкентта). Такташның җәмәгате Гөлчәһрә 1957 елда Мәскәүдә дәфен кылынды. Каенанасы Зәкия 1979 елда 81 яшендә Чаллы каласында вафат булды. Такташның нәселен ике улы – Рафаэль вә Аван[1] һәм шагыйрьнең оныклары дәвам итә.

Коръәндә бик кыска бер аять бар. «Адәм баласы һәрвакыт хәсрәт-кайгыда. Әгәр дә иман китерсә, хаклыкны, гаделлекне

[1] Һади Такташның уллары Рафаэль дә, Аван да инде вафат. – Ред.

васыять итсә, ул бәндәнең гамәле изге».

Менә шулай. Юкны – бар, димик, барны – юк, димик. Тагын мондый сүз дә бар: имеш, Такташка тәрәзәдән атканнар, диләр. Бу – нигезсез, уйдырма сүз.

*Касыйм Хәмзин*

### ***Касыйм Хәмзинның “Көрнәле мишәрләре”***

Касыйм Хәмзин яшьтән үк татар әдәбиятының байтак кына күренекле әдипләре белән якыннан аралашкан шәхес. Утызынчы елларда көндәлек матбугат битләрендә үзенең дә шигъри тәҗрибәләре, очерк һәм хикәяләре күренгәләп торган. Ләкин ул әдәбият дөньясына тулаем кереп китә алмаган. Бөек Ватан сугышы чыккан дәвердән башлап ул каләм хезмәтеннән берникадәр вакытка читләшеп тора. Моның сәбәпләрен аның киеренке партия эшенә бирелгәнлеге белән аңлатырга мөмкиндер, мөгаен. Авыл районнарында райком инструкторы, оештыру бүлеге мөдире вазифаларын үтәү аңа иҗат эшен ташлап торырга мәҗбүр иткәндер.

Җитмешенче, сиксәненче елларда исә, ялга чыккач, ул әдәбият мәйданына кабат әйләнеп кайтты, җилкенеп каләм тибрәтеп алды, кызыклы гына әсәрләр язып ташлады. Аның ул әсәрләре “Казан утлары”, “Азат хатын”, “Чаян” журналларында, газета битләрендә басылып чыктылар. Йөгерек тел белән язылган кыска-кыска хикәяләре, кызыклы эчтәлекле истәлекләре күпләрне үзенә җәлеп итте. Аеруча истә калган хикәяләреннән “Кадыйр бабай”, “Махан бабай”, “Бернәрсә дә бирмәде” һ.б. исемлеләредер, мөгаен.

Касыйм Хәмзин егерменче еллар ахырларында Спас шәһәре мәктәбендә булачак язучы Абдулла Алиш белән, Казан педагогия институтында шагыйрь Шәйхи Маннур белән бер чорда укыган. Габдерахман Минский белән бер үк елларда газета-журнал редакцияләрендә очрашкалап

торганнар. Минский белән аларның дуслашып китүенә Һади Такташ сәбәпче була.

Касыйм Хәмзинның соңгы елларда язган истәлекләре нигездә шушы шәхесләргә багышланган. Алар укучы өчен бик кызыклы, гыйбрәтле истәлекләр. Әмма аның бу жанрда иҗат иткән әсәрләреннән хатирәләргә иң бае, әлбәттә инде, җизнәсе Һади Такташка багышланганнары булыр. Җитмешенче еллар башында “Казан утлар” журналында дөнья күргән “Соңгарылган хат”та да сүз, нигездә, шул гаиләгә кагыла.

Сиксәненче еллар ахырында К.Хәмзинның хикәя һәм әдәби истәлекләр кулъязмасы тупланган ике папкасы Татарстан китап нәшриятына җибәрелә (автор бу вакытта Ленинград шәһәрендә яши иде). Машинкада басылган кулъязмаларның гомуми күләме 290 бит. Калынрак папка тышына “безнең бабайлар” дип исем куелган. Нәшриятның матур әдәбият редакциясе мөдире Фарваз Миңнуллин 1991 елның март башында ул ике папканы миңа тапшырды: шул әсәрләрне карап чыгып, мөхәррир фикерен язып бир, диде.

Ул кулъязмалар арасында күләмле “Соңгарылган хат”тан кала тагын өч истәлек язмасы күренекле шагыйребез Һади Такташ биографиясенә бәйле булып чыкты: “Такташ сукмаклары”, “Кунак”, “Такташның каенатасы”. Бу истәлекләр төрлесе төрле вакытта язылган. Бу әсәрләрне бергә туплап, фотолар, истәлекләрдә тасвир ителгән табигать күренешләрен өстәп, мәктәп балаларына багышлап “Такташ сукмаклары” исемендә аерым бер китапчык та эшләп булыр иде.

Күпләребезгә мәгълүм түгелдер, Такташның беренче хатыны Гөлчирә Хәмзина хәзерге Алексеевск районына кергән Коры Көрнәле авылында туып үскән. (1920 елларга чаклы авыл Спас өязе карамагында була). Касыйм Хәмзин истәлекләрендә авылның матур табигате, Гөлчирә үскән

мулла утарының иркен ишегалды, бакча күренешләре тасвир ителә. Такташларны каршы алырга яисә озататырга дип Камадагы Мурзиха пристанена сәяхәт кылулар яшүсмер Касыйм күңелендә онытылмастай бер күңелле сәяхәт рәвешендә сакланып калганнар.

Абдулла Алиш, Шәйхи Маннур һәм Габдерахман Минскийга багышланган истәлекләр дә бик кызыклы, аларда фәкать бу шәхесләргә генә хас сыйфатлар да матур тасвир ителә. әйтик, Шәйхи аганың дус-иш белән мөнәсәбәттә чак-чак кына киреләнеп алу мизгелләрен дә шахмат уенына бәйле рәвештә сиздереп куя автор. Такташка багышланган дүрт истәлеккә соңгы истәлекләрне кушып чыгарсаң да укучы күңеленә хуш килердәй 3-3,5 табаклы китап әзерләп була, билгеле. Әгәр инде сигез-ун табаклы җыентык чыгарасы булганда, ул җыентыкка мин түбәндәге хикәяләрне тәкъдим итәм: “Соңгы сый”, “Бер кашык май”, “Шиһап бабай”, “Кадыйр бабай”, “Махан бабай”, “Нурулла бабай”, “Минем әбием”, “Әтиләр язмышы”, “Сатучылар”. Аларның бер өлеше вакытлы матбугатта чыкканнар. Озынрак күләмле һәм беркадәр әдәби эшкәртү таләп ителгән хикәяләр рәтенә ярым истәлек жанрында язылган “Секретарьлар” (26 битле) белән “Карт мөгаллим”не (27 битле) өстәгәндә китап күләме ике табакка артачак. “Замана хатлары” исемле кыска әсәргә дә тагын бер кат каләм тидереп чыгару сорала. Бу әсәрләрне дә, авторга кайтарып тормастан, булачак китапны редакцияләү дәверендә эшләп чыгып була, минемчә. Хикәяләр эчтәлекләре белән дә, тасвирлау рәвеше белән дә бүгенге укучы күңеленә хуш килер дигән фикердә калам. Гыйбрәт алырдай хикмәтле вакыйгалар, матур-матур күренешләр ул хикәяләрне ялыкмыйча укырдай итә. Хәзер онытылып барган кайбер гореф-гадәтләр дә бу хикәяләрдә бик урынлы китерелә.

Җыентыкны чыгару планына кертәсе булсак, икенче папка тышына куелган исеме отышлырак булыр, минемчә.

“Көрнәле мишәрләре”ндә үзенә күрә бер сер, үзенчәлек тоемлана. Бу ике папкадагы кулъязмаларга карата минем төп фикерем: аларны сигез яки ун табаклы китап итеп бастырып чыгарырга бик кирәк. Кызыклы китап булачак. Ә Такташка һәм башка язучыларга багышланган истәлекләрне исә бераздан соң рәсемле кечерәк китапчык рәвешендә балалар әдәбияты редакциясенә тәкъдим итеп була.

Өлкән редактор Лирон Хәмидуллин. 28 март 1991 ел.

*Укенечле өстәмә.* 1996 елда Алексеевск районы башлыгы Алексей Иванович Демидов “Көрнәле мишәрләре” китабын нәшер итү өчен акча бүлеп бирергә ризалашкан иде. Ләкин китап нәшрияты архивында әлеге ике папканы табып булмады. Андагы әсәрләр, шулай итеп, юкка чыкты.

*Л.Хәмидуллин, 1991-2000.*

### *Вәлиуллин Габделхәй Миңневәли улы*



Декабрь башлары. Ниһаять дөньяны яктыртып кырпак кар явып китте. Агачлар азып киткән авыл урамнарын кар көртләре каплаганчы дип, ярым бушап калган урамнар буйлап зиратка таба юнәләм. Әнә без иртәдән кичке йолдызларга кадәр бияләйләребез бозланып катканчы чана шуып үскән тау итәкләре ятимләнеп, моңсуланып яталар. Анда бер генә бала да тау шумый шул... Без үскәндә 16 йортлы гөрләп торган тау башы урамында нибары ике йорт тырпаеп утыра, аның да берсендә яше 70тән узган ялгызак карт көн күрә. Нишләдең, авылым, кайда синең кешеләрең?

Шул сорауга җавап эзләгәндәй зират капкасын ачам. Менә шушы мәңгелек йортка күчтеләр шул мин белгән күп кенә авылдашларым. Күпләренең инде нәсел-нәсәбе дә бетеп бара. Авылда яшәп ятучылар (күпләре килен я кияү булып килеп калучылар) аларның кемлекләрен дә белеп бетерми. “Исәннәрнең кадерен, үлгәннәрнең каберен бел” гыйбарәсе нинди акыллы, мәгънәле гыйбарә. Тик киләчәк буыннарга өлкәннәр аңлатмаса, тарих җебе өзелер, кемнең кем икәнен, хәтта үзебезнең дә каян чыгышыбызны онытырбыз. Тизрәк, соңга калганчы нәрсә дә булса эшләргә кирәк....

Капкадан узып сукмак буйлап бераз баргач, затлы итеп эшләнгән ташлы, тимер чардуганлы каберләр янында туктап калам.Әтием белән икәүләп зиратка килүләребез искә төшә.

70нче елларның беренче яртысы. Социализмны инде кордык, коммунизмга да ерак калмагандыр дип хыялланып йөргән чаклар. Мулла балалары үзләренең кемлекләрен яшеребрәк йөргән чор. Каберләр өстендә дә әле ташлар юк. Әти балтасын култыгына кыстырып мине ияртеп зиратка, вакыт калса сәнәк-көрәк саплыгына дип Памистага да барып килә. Капкадан ерак түгел генә сиреннәре азып беткән ике каберне чистарта, шунда утырып дога кыла, шуннан соң гына үз әти-әнисе каберлегенә юнәлә. Мин гаҗәпләнеп:”Әти, син шулай ихтирам итәрлек кемнәр соң болар?” дим. “Кызым, болар тау башы мәчетенең мулласы имам-хатыйб Минһаҗетдин мулла абзый белән, Фәхрелбанат абыстай каберләре. Алар минем укытучыларым”,-ди. Мин шулай әтидән укытучыларны ихтирам итү, аларның олылыгын күңелдә йөртү сабакларын алам. Хәзер дә аякларым зират түрендә балкып утырган әти-әнием каберлегенә түгел, сул якка атлый. Бераз баргач Мөнәвәрә апа белән Нургата абый Ризвановлар, тагын бераз барсаң, Сафиуллина Нәҗия апа янына барып чыгасың. Хайруллин Нәҗип абый, Сара апа

белән Һади абый Хөсәеновлар да шушында җирләнгән. Болар һәрберсе турында китап язырлык, Көрнәледә туып-үсеп гомерләрен балалар укытуга багышлаган кешеләр. Тагын алга атлыйм. Менә минем бүген кулыма каләм алуыма сәбәпче булган мәрхүмнәр кабере: болар Коры Көрнәле авылының берничә буын баласына белем биргән, 50 елдан артык гомерен балалар тәрбияләүгә багышлаган Вәлиуллин Габделхәй Миңневәли улы белән аның томыш иптәше, шулай ук бик күп кенә Көрнәлеләрнең беренче укытучысы булу өстенә, 8 балага гомер биреп үстергән Гөлсем апа Мияссәр кызы.

“Коры Көрнәле мәктәбе” дигән сүзне ишетү белән Көрнәле халкының күз алдына рәшәткәле тәрәзәләре белән, Ёлка классы, Урта класс, Баганалы класс, Ленин бабай классы дип йөртелгән бүлмәләре белән, аркалы заллары белән, калай түбәле, күңелгә шулкадәр дә якын агач мәктәп һәм шул мәктәп баскычында бераз аска карап серле елмаеп торучы Вәлиуллин абый килеп баса, минемчә. Без аны барыбыз да шулай “Вәлиуллин абый” дип йөртә идек. Бу ул чорда укытучыны үзенә бер төрле хөрмәтләү ысулы булган инде.

Габделхәй Вәли улы 1932 елда Чистай педагогия техникумын тәмамлагач, Алексеевск районына юллама ала. Аңа Урта Тигәнәле, Кыр Шунталысы, Коры Көрнәле авылларында тарих укытучысы, укыту-тәрбия буенча директор урынбасары, мәктәп директоры вазифаларында хезмәт итәргә туры килә. 1937 елдан башлап гомеренең соңгы көненә кадәр тормышын ул Коры Көрнәле авылы белән бәйли. 22 яшендә Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган авылдашыбыз Хәбибулла Нәбиулла улы Хайруллинны да, Әфган сугышында батырларча һәлак булган Фәрит Шәйдуллинны да, башка бик күп хезмәт батырларын, кыю хәрбиләрне тәрбияләүчеләр дә алар була. 1946 елда

фронттан кайткач, сугыштан соңгы авыр елларда мәктәптә өчәр сменада балаларга белем бирү, мәктәпнең материаль - техник базасын ныгыту, янкормалар төзү, мәктәп яны бакчаларын төзекләндерү, пар белән җылыту системасына күчү һәм башка бик күп бетмәс-төкәнмәс эшләр барысы да Габделхәй Вәли улы тырышлыгы белән башкарыла. Мин моны һич икеләнмичә әйтә алам. Хәтта мәктәп директоры булып башка кешеләр, еш кына аның укучылары торганда да, зур эшләр башкарганда ул киңәшләре белән генә ярдәм итеп түгел, ә эшнең уртасында кайный иде. Без беркайчан да аны читтән күзәтеп, оештырып йөрүче сүрәтендә генә түгел, ә эш киемендә, көрәк, балта тоткан, пычкы, носилка башыннан тоткан хәлдә күрә идек. Вәлиуллин абый утырткан каен агачлары әле дә моңсу шаулап, элеккеге мәктәп тормышын искә төшереп торалар. Юк моңсу чорлар булмаган икән ул. Октябрь бәйрәмнәре генә ни тора!

7 ноябрь. Октябрь бәйрәме. Иртән торып өстәл янына киләбез. Әни бүген бәйрәм хөрмәтенә көндәлек коймак –кабартма белән генә чикләнмичә, өстенә шикәр комы сипкән күмәч, балан бәлеше, шомырт кайнатмасы кыстырып пешергән рулет та өлгерткән. Шулай булмыйча – бүген балаларның каникуллары башлана, олы бәйрәм көне дә. Сәгать 9да клубта бәйрәм башлана – чәй эчеп алгач шуңа җыена башлыйбыз. Әзерлек инде чәйгә кадәр үк башланды үзе, самавыр гел кайнап тормас – торуга галстукларны (ансыз бәйрәмгә бару юк!) кер сабыны белән юып, кайнар самавырга ышкып(үтүкләп) урындык башына элеп куйдык. Формаларны киеп, ак алъяпкычларны ябып, кызыл галстукларны таккач бөтенләй бәйрәм кыяфәте кереп китә үзебезгә. Итекләрне, бишмәтләрне киеп алгач, тирә-юне әле күптән түгел генә карга тавышларына чумып торган топольләр үсеп утырган электән калган мәчет бинасына урнашкан агач клубка юнәләбез. Клуб

әле ачылмаган да, ә аның тирә- ягы кара болыт төсле торган балалар чыр-чуына күмелгән. Шулай булмый: мәктәптә 5-6 класс бүлмәсе булуга карамастан, 200 дән артык бала укый ул чорда. Шунда уйнашып, әүмәкләшеп 9 тулганын көтәбез. Яңа яуган кар клуб тирәсендә тапталып юкка чыга. Ниһаять бинаның көнбатыш ягында урнашкан китапханәдән чыгып укытучылар, алар артыннан укучылар клуб эченә ургыла. Башлангычлар йөгереп алдагы рәт эскәмияләрдә урын ала. Олы класслар артта мәш килә. Клуб диварларына эленгән бөек юлбашчылар К.Маркс, Ф.Энгельс, В.И.Ленин портретларына күз иялəшкән. Ә менә түргә эленгән Аврора крейсеры сурәте төшкән плакат Октябрь бәйрәменең дәрәҗәсен тагын да арттырып җибәрә. Кызыл тукыма белән әйләндереп ябылган трибуна артына баскан Вәлиуллин абыйның 1-2 сәгатькә сузылган ялкынлы чыгышы бәйрәмнең иң төп өлеше була торган иде. Шушы чыгышны баштан тын да алмыйча, соңга таба әзрәк боргаланып тыңлап утырганда бу көннең Октябрь бәйрәме генә түгел, ә хөрмәтле укытучыбызның туган көне дә икәне беребезнең дә башыбызга килми иде шул.

Укытучы сугыштан соңгы елларда авыл халкының белем бирүчесе, аңа мәдәният яктылыгы китерүче, оештыручы, тормыш-көнкүрешендә киңәшчесе була. Тормышта кыенлыклар килеп чыкканда авылыбыз кешеләре иң элек кемгә барган? Әлбәттә инде төпле киңәш, турыдан-туры ярдәм сорап Габделхәй Вәли улына. Бер генә кеше дә игътибардан, иң әһәмиятлесе, өметләнгән ярдәменнән мәхрүм калмый. Әнә шуңа да инде Вәлиуллиннар дөреслек яклаучылар, хаклыкны эзләү өчен вакытларын да, тырышлыкларын да кызганмаучы намуслы кешеләр булып көрнәлелеләр күңелендә яшиләр. Хөкүмәтебез гади авыл укытучысының намуслы хезмәтен лаеклы бәяли. Советлар Союзы оборонасын ныгыту һәм социалистик төзелештәге аеруча хезмәтләре өчен ул Хезмәт

Кызыл Байрагы ордены һәм медальләр, къпсанлы Мактау кәгазьләре, рәхмәт хатлары белән бүләкләнә. Иң әһәмиятлесе ул авыл халкы, укучылыры алдында зур ихтирам, абруй казанды. Күп еллар (ул елларда халык үзидарәсенең бер формасы) авыл иптәшләр суды рәисе булып торуы аның авыл халкы өчен иң ышанычлысы, Ил агасы булуы турында сөйли.

Шушында, Көрнәледә алар Гөлсем апа белән тормыш корып, 8 бала үстерәләр, барысына да диярлек югары белем алырга юнәлеш бирәләр. 3 кызлары: Фалия , Фирая, Гөлфинә эти әниләре юлыннан китеп, гомерләрен укытучылык эшенә багышлыйлар.

Фалия апаның кызыклы итеп биология дәресләре алып баруы әле дә исемдә. Ул соңыннан Сарман районында биология фәнен республика күләмендә танылырлык итеп, зур нәтиҗәләргә ирешеп укытты. Тик мәкерле авыру аны аямады. Икенче кызлары Фирая апа Яр Чаллы мәктәпләрендә математика укытып, хәзер лаеклы ялда. Гөлфинә Габделхәй кызы Тукай районында гомер буе математика укытты. Лаеклы ялда булуына карамастан, әле бүген дә мәгарифне ташламый. Вәлиуллиннарның күпсанлы онык-оныкалары, оныкчыклары арасында бүген педагоглар да, юристлар да, фән эшлеклеләре дә, медиклар да бар. Аларны санау түгел максатым. Бүген аларны хәтерләгән авылдашларым колагына әйтер сүзем бар. Үтеп баручы 2014 ел безнең яраткан , хөрмәт иткән укытучыбыз, безне бар күңеле, белеме белән чын кешеләр, коммунизм кешеләре итәргә тырышып, янып яшәгән укытучыбыз, “Левашево” совхозының Көрнәле бүлекчәсе партоешма җитәкчесе, ялкынлы пропагандист Вәлиуллин Габделхәй Миңневәли улының (1914-1984) тууына 100, ә вафатына 30 ел булыр иде. Яңа елларга керүгә изге Мәүлид бәйрәмнәре башлана. Шушы изге көннәрдә шушы язманы кызыксынып укучыларның күңелендәге рәхмәт хисләре Укытучыбызның рухына дога булып иңсен иде.

Уч төбенә куеп Җирне гүя,
Бүгенгесен аның, үткәнен
Күрсәтте ул безгә, урап кайттык
Бер белмәгән илләр үтәли.
Аяз дөнья, кешелек бәхете өчен
Көрәшергә безне өндәде.
- Яратыгыз җирне! – диде һаман,
- Мине яратыгыз, – димәде.
Аңа бүген еллар аша карыйм:
Көлеп басып тора күңелдә.
Ах, хәйләкәр абый!
Җирне, кешеләрне яраттырып,
Яраттырган икән үзен дә!

*Резидә Фатыхова*

## *Гомере бушка узмаган*

“Кешене өмет яшәтә”, “Кешене мәхәббәт яшәтә” кебек гыйбарәләргә көннән-көн күбрәк ышанам. Әйе! Мәхббәт кешене яшәртә, канатлар куя, яшәтә. Бигрәк тә иң олы мәхәббәт – ана мәхәббәтедер. Сыңар канат булып калган хатынның баласы булса, ул баласы өчен яши, аңа гомерен багышлый. Әгәр ирең сугышта үлеп, җиде бала белән калсаң?.. Бар булган мәхәббәтеңне шушы балаларга өләшеп, барысына да җиткерергә тырышып, үзәк өзгән кайгың арткарак чигенәдер. Ләкин бетми дә, күңелдән дә китмидер. Һаман сызып, йөрәкне кимерәдер. Ярты гасырдан артык ничек чыдар иде ул йөрәк, әгәр шушы җиде балага өләшкән мәхәббәт зураеп, үсеп яңадан анага әйләнеп кайтмаса. Ул ана балалары алдында гына түгел, халкы, авылдашлары алдында да бөек Анага әйләнә.

Соңгы айларда күп балалы аналар балалары турында кәгазьләр җыйдылар, нindидер ярдәм көтеп, өмет белән

яшәделәр. Өметсезлеккә бирелеп, берни дә бирмиләр икән, дигән сүзләр дә йөрде. Менә шундый көннәрдә миңа берничә күп балалар тәрбияләп үстергән ана белән сөйләшергә туры килде. Һәркайсы белән аерым-аерым сөйләшсәм дә, берничәсенең авызыннан: “безгә бирмәсләр дә инде, ичмасам әнә Галия апага бирсеннәр. Аңа тиеш”, - дигәнне ишеттем. Аның хөрмәткә, олылауга лаек булуы бәхәссез. Бернинди бүләкләр дә, медальләр дә халык тануын, халыкның хөрмәт хисен алыштыра алмый.

Бүген сүзем 92 яшен тутырып килүче Галия әби Галимова турында. Ул бүгенге көндә Коры Көрнәленең иң өлкән яшьтәге кешесе. Кече кызы Нәҗия һәм кияве Зәкиулла Мусиннар тәрбиясендә яши.

Галия әби 1909 елда урта хәлле крестьян Мортаза абзыйның унынчы – төпчек һәм бердәнбер кыз баласы булып дөньяга килә. Уңган-булган, үз тырышлыклары белән шактый мул тормышта көн итүче Мортаза абзый белән Газизә абыстай исән калган дүрт баласын (калганнары яшьли үлә) эшкә өйрәтеп, тормыш итәргә әзерләп үстерәләр. Кызлары Галия дә иркәләнеп өйдә чигү чигеп кенә утырмый, ир туганнары белән бар хуҗалык эшен эшләп үсә. Шуңа да, авылның шулай ук урта хәлле, уңган кешесе Корбангали абый улы Нурмөхәммәткә кияүгә чыккач та, соңыннан сугыш елларында да эш авырлыгыннан бөгелеп төшми ул. Бер-бер артлы җиде бала дөньяга килә, яңа йорт җиткереп башка чыгалар. Инде колхозга да ияләшеп бетәләр. Менә шулай матур гына яшисе иде дә бит...

Каһәр суккан сугыш башланып, авылның асыл егетләрен, ирләрен сугышка алалар. Галия апаның ире Нурмөхәммәт абзый да фронтка китә. “Гел кайгырып утырып кына булмый бит. Сигез кашыкны туйдырасы бар”, - дип искә ала Галия әби. Бер кара төннән икенчесенә кадәр авыр эш, ачлык. Кышкы кичләрдә сугыштагы солдатларга оекбаш, бияләйләр

бәйләүләр. Үземнең дә җиде балам дип тормый, бер эштән дә калмый Галия апа да. Терлек асрарга тырыша. “Эх, ул продналогның үзәккә үткәне!.. Балаларым ат кузгалагы, алабута, кычыткан ашап үстеләр. Сөт, ит, йомырка налог түләргә китә. Артканын районга илтеп сатам да, шырпы, тоз, керосин алам”, - ди ул.

Шулай берчакны күршесе Хәдичә апа белән Алексеевскида пекарня яныннан узып баралар икән. Май саткан акча кесәдә, ә икмәк исе үзәккә үтеп борынны кытыклый. Икесенә бер кисәк икмәк алып ашарга уйласалар да, өйдә калган балалар искә төшә. Озак кына пекарня янына утырып икмәк исе исниләр дә, кайтып китәләр.

Сугышның соңгы еллары. Күп балалы гаиләләргә ярдәм оештырыла. Галия апа да исемлектә була. Җәяүләп Алексеевскига барып җитеп, озак кына чират торгач, ниһаять, бүлмәгә керә... Һәм аңа үтүк китереп тоттыралар. “Мине мыскыл итәргә чакырдыгызмы, минем балаларымның өсләренә кияргә юк, нәрсә үтүклим”, - дип үпкәләп чыгып китә. Ак шәл ябынган бер хатын артыннан чыга да: “Апа, бу үтүкне ал, сатарсың. Бүтәннәргә үтүк тә юк, бөтен районда җиде кешегә генә бирдек”, - ди. Чыннан да үтүк саткан акчага күлмәге юклыктан укырга бармаган балага күлмәк алына. Теге ак шәлле хатынга яхшы киңәше өчен әле дә рәхмәт укый Галия әби.

Сугыш чорының салкын кышкы бер көнендә районга май сатарга барган Галия апа озаграк тоткарлана. Кышкы көн кыска, кичкә кала. Буран чыгып адаша. Инде өметен өзгәндә ут күреп, шунда бара. Кыркүлнең кырый йортында яшәүче хуҗа хатын башына эскәтер ябынган (шәлен онга алыштырып балаларын ашата), туңган Галия апаны өенә кертеп җылыта, чабаталарын киптереп, алабута күмәче белән сыйлап, кундырып җибәрә. “Телләребез төрле булса да, бик яхшы аңлаштык. Диннәребез төрле булса да, Ходай рәхмәт

итсен ул бәндәгә, дип дога кылам”, - ди Галия әби.

Тормыш ничек кенә авыр булмасын, ирен, балалары әтиләрен көтеп, өмет белән яшиләр алар. Көннәрдән бер көнне кыл кебек... өмет өзелә. 1943 елның августында ире Нурмөхәммәтнең “Батырларча һәлак булды”, дигән кара язуы килә. “Минем өчен кара көннәр башланды”, - ди Галия әби. Һай, авыр ул өметсезлек, яшәүнең бер мәгънәсе калмый. Тик, әлеге дә баягы, шул балалар дип яшисе бар.

Һәм яши Галия әби. 1945 елгы Җиңү көненнән бирле менә инде 56 ел бәйрәм каршылый. Язлар җитеп, бәйрәм якынлашкан саен яңадан хатирәләр кузгалып, йөрәк сыкрап куя. Тик бер нәрсәгә шатлана Галия әби: “Аллага шөкер, шул ачлыкта, шул газапларда эшкә яраклы дүрт кыз, армиягә яраклы өч ул үстердем. Барысын да исән-сау аякка бастырдым. Ә бит сугыш вакытында ачлыктан, авырулардан балаларын югалткан аналар да күп булды. Кар астында кыш чыккан башак ашап кына биш кыз баласы белән Гатифә апа үлеп китте. Сугыштан, ут эченнән ире исән-сау кайтты, ә гаиләсе юк иде... Күпме кеше үлде ул елны...”

Галия әби сөйли дә сөйли. Аның сөләгәннәрен барын да язсаң, китап булыр иде. Озын, бай тормыш юлы. Озак яшәвенең серен дә яшерми ул: “Хезмәтне яраттым, эшләп яшәдем, хәрәкәттән курыкмаска кирәк”, - ди. Тагын бер сәбәп искә төшеп өстәп куя: “Килен булып төшкәч, Минһаҗ мулла мәчете (тау башы мәчете) бик начар хәлдә булганлыктан, мин аны берүзем сыладым, агарттым һәм юып чыктым. Намазга җыелган мәхәллә картлары минем исәнлегемә-саулыгыма дога кылганнар, озын гомер теләгәннәр. Догалары кабул булгандыр”. Әйе, изгелек югалмый ул. Һаман шулай балаларыңа, оныкларыңа шатланып, авылдашларыңның хөрмәтен тоеп яшә, Галия әби. 56нчы Җиңү көнен дә исән-сау, матур итеп каршы ал.

*Резидә Фатыхова*

## *Кеше китә, җыры кала*

Кеше гомере йолдызларныкы сыман. Аяз кичтә күктәге бихисап йолдызларга карап хәйран каласың: кайсылары сүлпән генә сирпелеп тора, икенчеләре (безгә якынрак торучыларыдыр инде) “мине күрми калмагыз”, дигәндәй, күз кыса-кыса җемелдиләр. Шунда кинәт бер йолдыз атылып китә. Бүгенге язмам героен мин әнә шул якты, әмма тыйнак кына җемелдәүче йолдызга тиңләр идем. Ул минем һәм бик күп көрнәлеләрнең яраткан укытучысы Хөсәенов Һади Ибәтулла улы булыр. Бөек Җиңүнең инде 70 еллыгын да билгеләп үттек. Батырларны барладык та кебек. Тик чын сугыш каһарманнары турында әле сыңар сүз дә әйтелмәгән очраклар күп. 23 февраль – Ватанны саклаучылар көне алдыннан Һади абый турында язмасам, өстемдә бик зур бурычым калыр сыман.

Әлбәттә инде, укытучы дәресләре белән бала күңеленә кереп кала. Һади абый безне табигать белеме, физкультура, рәсем кебек авыл мәктәбендә икенче пландарак торган фәннәрдән укытты. Ләкин ул дәресләрнең икенчеме, әллә беренче пландамы булуы бик күп укытучыдан тора шул. Табигать белеме дәресләренең һәрберсенә Һади абый ниндидер күрсәтмә материалсыз керми иде: тау токымнары коллекциясеме ул, теллуриймы – дәрес мавыктыргыч, кызыклы үтә иде. Без хәзер бик озак исәпләп тормыйча, “Гильмутдинов-Гайнутдинов” дип кенә җибәрәбез. Каян килгән ул чор укытучыларына бу кадәр матур тел: авыл мәктәбен бетереп ерак та түгел Спас педагогия курсларында гына белем алганнар бит югыйсә. Саф татарча Нәҗмиев, Вәлиев дип кенә эндәшә иде, хәтта шук малайларны да матур итеп, “Фәлән акыллым, ник шулай Маһи әбиеңнең мөгезсез кәҗәсе кебек утырам икән”, - дип тавыш күтәрмичә генә әрли иде. Табигать белеме дәресенең иң үтемлеләрен Һади абый табигатьнең үзендә бирә, ул безне бик еш урманнарга, әрәмәгә алып чыгып китәр иде. Рәсем, хезмәт дәресләрен берләштергәндер инде, табигатькә карап натурадан рәсем

ясатсынмы, агачларның исемнәрен (карама, зирек ишеләрне әле бик күпләр белеп тә бетерми), аларны танырга өйрәтсенме, язгы һәм көзге гөмбәләрне күрсәтсенме – һәр экскурсия максатчан булыр, ул урманга барып туп уйнап, вакыт уздыру белән чикләнми иде. Иң әһәмиятлесе – ул безне табигать матурлыгын күрергә, аңа карап сокланырга өйрәтте.

Ә рәсем дәресләре үзләре ни тора! Бик оста рәсем ясаучы иде укытучыбыз. Сугыштан соң Казан художество училищесын тәмамлаган. Үзенең белгәннәрен безгә дә өйрәтергә тырышты: “җирлек”, “яктылык”, “күләгә” кебек әһәмиятле төшенчәләрне аңлата, шул таләпләрне куеп рәсемнәр ясата иде. Мин шәхсән үзем рәсем ясарга бик яратам, күп нәрсәне Һади абыйдан алдым, дип әйтә алам. Хәзерге балаларның ак кәгазь битендә бушлыкта эленеп калган рәсемнәренә карыйм да, моннан 3-4 дистә еллар элек безнең чор балаларына Һади абыйның белем бирүе нинди зур бәхет булган икән, дип уйлап куям.

Без үскәндә авыл халкы әллә ни затлы киенә иде, дип әйтә алмыйм, сугышның яралары төзәлеп бетмәве сәбәптерме, алтмышынчы еллар әле авыррак чор иде. Ләкин мин Һади абыйның хәтта мәктәптәге без зур хөрмәт белән караган укытучылар арасында да үзенә генә хас зәвык белән, бик ыспай киенгәнен искә алам. Аның күзлеге дә башкаларныкы кебек пластмасса кысалы түгел, алтынсу төстәге металл кысалы булыр, чем-кара чәчләрен ыспай гына артка тараган – гаҗәп матур кеше иде ул. Әнә шулай тышкы кыяфәте белән дә, мөгамәләсе белән дә, сүзе белән дә тәрбияләгән ул безне. Зыялылык кешенең канында була, diләр – бу дөрес. Аңа кайда да булса укып кына ирешеп булмый.

Ә бит безнең укытучыбыз матур киенеп йөрүче генә түгел иде: авылда беренче таш йортны (мәктәп котельные тирәсендә бушка өелеп яткан күмер шлакларын ташып) үз куллары белән салды, авылда беренче пар белән ягу җайланмасын өендә ул урнаштырды. Авылда агач-куакларның төрлелеге, түтәлләренең үзенчә дизайн белән урнашуы белән аерылып торучы бакча да Һади абыйларныкы иде. Мәктәптәге

чараларны фотога төшереп, ул фотоларны ясап истәлекләр калдыручы да, авылда беренчеләрдән булып үз тырышлыгы белән автомобильгә утыручы да Һади абый булды. Йорт тулы терлек асраулары да өй тирәсендәге матурлыкны бер дә бозмый иде нишләптер.

Һади Ибәтулла улы Идел буе өчен бик авыр ел – 1921 елның декабрендә дөньяга килә. Ачлык елның ачы үлеменнән Америка җибәргән гуманитар ярдәм коткарып кала аны (Сара апа сөйләгәннәрдән). Авыр елларның иләгеннән бер кыз, өч ул исән калалар. Ибәтулла бабайның бар уллары да Бөек Ватан сугышында катнаша. Олы улы Шәрифулла, ике бала атасы, Бөек Ватан сугышында һәлак була. Икенче улы Һади сугышның беренче көненнән фронтта. Табигый сәләтен, җитез, сизгер булуын абайлап алганнардыр, разведкада топограф булып хезмәт итә. Гади солдаттан лейтенант дәрәҗәсенә күтәрелә. Сугыштан 1946 елда гына әйләнеп кайта. һади Ибәтулла улының хәрби билетында “Батырлык өчен”, “Сугышчан батырлык өчен”, “Ленинград оборонасы өчен” медальләре һәм башка күп кенә бүләкләр теркәлгән. Ни кызганыч, без мәктәптә укыганда (ул чорда сугыш ветераннары бик күп иде) укытучыбызның сугыштан шундый зур батырлыклар эшләп кайткан фронтовик икәнен дә, сөйләгәндә сизелер-сизелмәс тотлыгуының сугышта алган баш контузиясе нәтиҗәсе икәнен дә белми идек. Фронтовиклар белән очрашулар, митинглар әзерләшә, әмма үзе турында бик сөйләми иде шул тыйнак укытучыбыз. Бары тик кырыгынчы елларның икенче яртысындагы укучылар гына сугыштан күкрәк тутырып медальләр тагып кайткан яшь, чибәр лейтенант егетнең мәктәпкә укытырга килүен, шул вакытта мәктәптә укытып йөрүче кыр чәчәкләредәй зәп-зәңгәр күзле, сап-сары озын толымлы Сара исемле сылу кызны (ул да Көрнәледә туып үскән) үзенә тормыш юлдашы итеп сайлавын искә алып сөйлиләр. Һади абый белән Сара апа берсеннән-берсе чибәр, талантлы өч ул һәм бер кыз үстерделәр: Луиза, Марат, Айрат, Самат. Луиза апа бүген Менделеевск шәһәрендә яши. өч уллары да инде

вафат. Алар бик оста гармунчы, баянчы, рәссам, эретеп ябыштыручы – җыеп халыкча итеп әйткәндә, “кулларыннан гөл түгелүче” егетләр иделәр. Талантлы кешеләр тормышның кырыслыкларына бирешүчән була, бик сирәкләр (корыч ихтыярлылар гына) авырлыклар бөгелдергәч, тураеп баса ала. бу егетләр халык күңелендә якты хисләр калдырып (Айрат абый туган авылына багышлап беренче җыр чыгаручы, авылдашларына юнь генә бәягә капкалар ясап бирүче дә, клубтагы чараларны актив оештыручы да, Самат абый оста рәсемче, баянчы, Марат абый аяклы энциклопедия – белмәгән бер эше дә юк иде), китеп бардылар. Һади абый үзе дә гомере буе мәктәптә эшләп лаеклы ялга чыккач, бик рәхәтләнеп кенә озак яши алмады шул: сугыш авырлыклары, бигрәк тә контузия үз эшен эшләде – 1990 елның җәендә арабыздан китте. Аңа әле җитмеше дә тулып җитмәгән иде.

Әйе, йолдызлар атыла тора, тик күк йөзенең әле йолдызсыз торганы юк. Кеәеләр дә китә, үзләреннән соң матур хатирәләр калдырып, тәрбия орлыклары сибеп китә кайберләре. Һади Ибәтулла улы да әнә шундый иде. Бөек Җиңүнең 71 еллыгы уңаеннан Ватан алдында изге бурычын намус белән үтәгән, өч солдат тәрбияләп үстергән, туган авылы балаларына төпле белем биргән укытучыбызны искә алуыбыз аның рухына дога булып барсын иде.

*Резидә Фатыхова*

# Авылдашлар иҗаты

## *(Коры Көрнәле авылы имамы Нәбиулла Гайнулла улы шигырьләре[1])*

### *Коръән Кәрим*

Коръән өнди гәдаләткә, нәфес өнди заляләткә,
Коръән юлына кергәннәр төшмәячәк һәлакәткә.

Коръән өнди яхшылыкка, нәфес өнди шакшылыкка,
Коръән юлына кергәннәр чыгар бер көн яктылыкка.

Коръән сөяр хаклыкны, ул телидер пакълекне,
Дәхи аның бер максуды – тели күңелнең сафлыкны.

Ак-пакъ һәм саф күңел белән укысаң син Коръәнне,
Һич хатасыз кылачаксың ул Коръәндә кушканны.

Ихлас, Коръән сүзе бик тәмле, укучысы бик ямьле.
Ихлас белән укылса гәр, төшә тәнең вә җаның мәйле.

Коръән укысаң – агара синең каралган күңелең.
Бераз укымышың да булып, булса синең белемең.

[1] Шигырьләр авторның 1929 елды гарәп хәрефләре белән язылган кулъязма дәфтәреннән алынды. Ул Г.Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана: 53 фонд, 5 тасвирлама, 26 сакл. бер. – 225-237 б.

## *Фәкыйрьлекнең зарары*

Бу фәкыйрьлек яман нәрсә икәндер, мин белмәдем.
Мондин начар, мондин яманны һич мин күрмәдем.

Гыйбадәттә ләззәт булмый, дөнья әгәр тар булса,
Рухың тәмам төшә икән кайгы-хәсрәтең булса,

Фәкыйрьлекдән сакланыгыз дип әйтәмен сезләргә,
Чөнки аның ачыйглыгы килгән иде безләргә.

Түшәгеңә күрә генә аяк сузу кирәктер.
Икътисад белән торучы бу дөньяда сирәктер.

Бу фәкыйрьлекнең килүе икътисад юклыгыннан,
Хак Тәгаләне зикердән күңелемнең бушлыгыннан.

Фәкыйрь булсаң синнән качар бөтен ага-энеләр,
Үзләре тук булган өчен синең хәлне белмиләр.

Дәхи бер кабих сыйфат бар – ялкаулыктыр элгәре,
Ялкауларны тикшереп сез, карап тормыш күрегез.

Бу фәкыйрьлекнең килүе әнә шул ялкаулыктан,
Бәхет-дәүләтнең килүе – синең күңелең саулыктан.

Сакларга бик кирәк икән бу күңелнең саулыгын,
Саклап бик нык тотар өчен тазарак иш баулыгын.

Бу фәкыйрьлектән дә яман дөньяда һич нәрсә юк.
Киләчәк көнең дә кайгырт, булсаң әгәр бүген тук.

Алдагы көнне кайгырту бигрәк тә кирәк икән,
Бүген сиңа күпме кирәк, иртәгә дә шулай икән.

### ***Кайтам әле Көрнәлемә***

Җырларда җырланган җирләр
Очратсам да юлымда,
Йөрәгемдә сагыну уты
Туган авылым уемда.

Көрнәлемнең үрләреннән
Карадым күлләренә,
Кайтам әле Көрнәлемә
Сагынган көннәремдә.

Безнең авыл кызларына
Күзе төшмәс кемнәрнең,
Такташны гашыйк итәрлек
Кыз үстергән Көрнәлем.

Сандугачлар әрәмәдә
Тыңлап үстем көйләрен,
Бер сандугач булыр идем
Әрәмәңдә Көрнәлем.

Көрнәлемнең үрләреннән
Карадым күлләренә,
Кайтам әле Көрнәлемә
Сагынган көннәремдә.

### ***Көрнәле җыры***

Безнең яшьләр күп авылда,
Авыл матур булганга,
Әрәмә суларын эчеп,
Көрнәледә туганга.

Эх, матур  урманнары,
Умарталык буйлары!
Әллә каян куренеп тора
Аның такыр юллары.

Авылыбызның тирә-ягын
Чолгап алган урманнар.
Урман алды киң-киң кырлар
Комбайннар уралар.

Күрәсегез килсә әгәр,
Килегез безгә, дусларым!
Туйганчы бер эчәр идек
Шул әрәмә суларын.

## *Туган авылым Коры Көрнәлем*

Авылыма кайтып киләм
Язның матур аенда,
Умырзая чәчәк ата
Көрнәле тугаенда.

Көрнәле болыннарында
Чәчәкләр үсеп чыкты,
Язгы болытлар килеп
Җылы суларын сипте.

Ага Әрәмә сулары
Көрнәлегә ямь биреп,
Сайрыйдыр сандугачлары
Тирә якка моң сибеп.

Көрнәле, Көрнәле
Ялт(ы)рый асфальт юллары,
Шул юллардан кайтып йөри
Кызлары һәм уллары.

Безнең Көрнәле яшьләре,
Матур иттереп җырлый,
Сәхнәләргә чыгып бии
Оялып басып тормый.

Көрнәле, Көрнәле
Сиңа карап уйга талам,
Әйтерсең лә кайтам яшьлегемә
Туфрагыңнан гүя көч алам.

### *Көрнәле моңнары*

Бер моң булып керә авыл
Хис тулган күңелемә,
Яшьлегемә кайтам тагын,
Кайтаваз көйләренә.

Шушы көйне тоеп яшим
Иртәсен дә, кичен дә
Язмыш кайларда йөртсә дә,
Ул мәңге йөрәгемдә.

Яңа сауган сөт тәмедер,
Яңа салган ипидер,
Бәлки яңа өеп куйган
Печәннәрнең иседер.

Һаман әле сизәм сыман
Морҗаның төтеннәрен,
Сагынып көткәннәрем истә
Куян күчтәнәчләрен.

Әй, Көрнәле чишмәләре,
Игеннәре, кырлары,
Синдә калган сабый чагым,
Синдә яшьлек җырлары.

* * *

Сессиягә барган саен мине
Шәһәр шавы тарта авылдан.
“Һай, зыяга үтә икән яшьлек!
Агылган да гомер агылган...”

Театрга барыйм дисәң – театры,
Дуслар дисәң – күпме чакырган!
Кичке кала утлары ул әнә
Күз кысалар ничә чакрымнан.

Озаккарак килсәм шулай да мин
Тиз туямын шәһәр шавыннан.
Әнием дә төштә яулык болгый,
Мине дәшә Көрнәл(е) тавыннан.

Кайт кызым ди, мине ташлап китмә,
Гафу итмәс туган туфрак.
Гафу итмәс эткәң белән бергә
Урманнарга йөргән тар сукмак.

Әрәмәдән эчкән суың тартыр,
Сине үстергән Көрнәле ризыгы.
Шул бурычың әгәр үтәмәсәң,
Тормышыңның булмас кызыгы!

# Кулланылган әдәбият исемлеге

1. Алексеевский район: История и современность. – Казань: Матбугат йорты, 2000. – 279 с.

2. Археологические памятники бассейна р. Черемшан. – Казань: Ин-т яз., лит. и истории, , 1990. – 112 с.

3. Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге. Ике томда. I том. – Казан: Мәгариф - Вакыт, 2015. – 568 б.

4. Исторические судьбы народов Поволжья и Приуралья. – Казань: Институт истории им. Ш.марджани АН РТ; Изд-во “Яз”, 2014. – 304 с.

5. Йосыпов Г. Генерал Зәки Котлин. – Казан: Татарстан кит. нәшр., 1959. – 100 б.

6. Казаков Е.П., Старостин П.Н., Халиков А.Н Археологические памятники Татарской АССР. - Казань. Татарское книжное издательство, 1987. – 240 с.

7. Мухаметшин Д.Г. Татарские эпиграфические памятники. Региональные особенности и этнокультурные варианты. Серия “Археология евразийских степей”. – Выпуск 6. – Казань: Институт Истории АН РТ, 2008. – 132 с.

8. Насыров Р.Г. Сельское расселение Западного Закамья во второй половине XVI-XVIII вв. Диссертация на соискание ученой степени кандидата исторических наук. – Казань, 2007. – 220 с.

9. Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. 4 нче чыгарылыш. – Казан: ИЯЛИ, 201. – 280 б.

10. Татар энциклопедия сүзлеге / Баш мөхәррир М.Х. Хәсәнев, җаваплы мөхәррир Г.С. Сабирҗанов. – Казан ТР ФА Татар энциклопедиясе институты, 2002. – 830 б.

11. Хәмидуллин Л. Күңелдә калганнар. – Казан: Сүз, 2007. – 240 б.

## *Тарихи чыганаклар исемлеге Татарстан Республикасы Дәүләт архивы. Ф. № 2., Опись № 2.*

1. Д. 1252. Дело о перестройке мечети в дер. Сухих Курналях Спасск. уезда. 1 янв. – 31 дек. 1878 г. 7 л.
2. Д. 1700. Прошение крестьянина Чистопольского уезда Шамсутдинова Фахрутдина об утверждении пожертвованного им дома в молитвенный дом и об утверждении к этому дому муллою крестьянина Спасского уезда деревни С[ухих Курналей]… 1 янв. – 31 дек. 1880 г. 10 л.
3. Д. 1729. Дело о перестройке 3-й соборной мечети в дер. Сухих Курналях Спасск. уезда. 1 янв. – 31 дек. 1880 г. 12 л.
4. Д. 2863. Дело об определении в муллы к соборной мечети в дер. Сухие Курнали Спасск. уезда Хусаинова. 16.02.1884 – 29.02.1884 г. 7 л.
5. Д. 2864. Дело об определении Хусаинова Гарея азанчеем к мечети в дер. Сухие Курнали Спасск. уезда. 01.06.1884 – 26.06.1884. 12 л.
6. Д. 3230. Дело об определении Гилязетдинова азанчеем к мечети в дер. Сухие Курнали Спасск. уезда. 18.06.1886 – 27.07.1886. 29 л.
7. Д. 3599. Дело об определении Хусаинова и о назначении его в дер. Сухие Курнали Спасск. уезда азанчеем к мечети. 24.02.1888 – 12.05.1888 г. 11 л.
8. Д. 6462. Дело по ходатайству крестьян деревни Бабаевы Челны Спасского уезда об определении в их мечеть муэдзином крестьянина дер. Сухие Курнали Спасск. уезда Хайретдина Хуснутдинова. 1 янв. 1901 г. – 31 дек. 1902 г. 17 л.
9. Д. 7931. О постройке мечети в дер. Сухие Курнали. 20 окт. 1907 г. – 25 янв. 1908 г. 13 л.
10. Д. 8359. Об определении Барышева [муллой] третьей соборной мечети в дер. Сухие Курнали. 24 июня – 31 июля 1909 г. 12 л.

11. Д. 8482. О разрешении постройки второй соборной мечети в дер. Сухие Курнали. 2 - 5 марта 1909 г. 12 л.

12. Д. 8494. О разрешении постройки третьей соборной мечети в дер. Курнали. 19 – 22 авг. 1909 г. 18 л.

13. Д. 8588. Об утверждении Барышева [муллой третьей соборн. мечети] в дер. Сухие Курнали. 20 янв. – 17 февр. 1910 г. 11 л.

14. Д. 8636. О назначении Нурутдинова соборной мечети в дер. Курнали. 2 ноября – 10 декабря 1910 г. 16 л.

15. Д. 9013. Об утверждении имама Мингазетдинова хатыпом первой соборной мечети в дер. Сухие Курнали Спасск. уезда. 23 – 27 окт. 1912 г. 12 л.

16. Д. 9829. Дело об утверждении крестьянина Хамзина 2-м муллою дер. Сухие Курнали Лаишевского уезда. 9 авг. 1916 г. 19 л.

17. Д. 10581. Дело о приеме на жительство арестанта из крестьян дер. Сухие Курнали Спасск. уезда Сайфуллина. 03.11.1881 г. – 24.03.1882. 16 л.

18. Д. 10713. Дело о высылке крестьян Сухокурналинского сельск. общества Спасск. уезда Шамсутдинова, Алеева, Негематуллина и Шамсутдинова. 11.08.1882 – 01.06.1883 г. 43 л.

# ЭЧТӘЛЕК

Гүзәл авылым – Коры Көрнәлем......................... 5

Ерак тарих ни сөйли *(Коры Көрнәле авылының килеп чыгышы турында фаразлар)*.......................... 9

Көрнәленең язмышына ташлар шаһит *(Коры Көрнәле авылындагы ташъязма истәлекләр)*......... 18

Коры Көрнәле мәхәлләләре һәм мәчетләре тарихы...................................................................... 39

Нәселебезне барлаганда... *(Коры Көрнәле авылы метрика дәфтәрләреннән)*..................................... 62

Авылыбызның күренекле шәхесләре.................... 87

Коры Көрнәле авылы кешеләре Бөек Ватан сугышында................................................................ 102

Кушымта. Коры Көрнәле авылы турында язмалар..................................................................... 109

*Ә. Галиев* Такташ каены................................... 109

*К. Хәмзин* Такташ һәм аның гаиләсе................ 113

*Л. Хәмидуллин* Касыйм Хамзинның «Көрнәле мишәрләре»........................................................... 120

*Р. Фатыхова* Вәлиуллин Габделхәй турында язмасы....................................................................... 123

*Р. Фатыхова* Гомере бушка узмаган.............. 129

*Р. Фатыхова* Кеше китә – җыры кала ........... 133

Авылдашлар иҗаты. Шигырьләр......................... 137

Кулланылган әдәбият исемлеге............................ 144

Авыл тарихы фотографияләрдә

**Коры Көрнәле авылы тарихы**

**Төзүчеләре**
Гомәров Илһам Госман улы
Усманов Венер Мөдәрис улы

Компьютерная верстка *Д. Р. Галиуллиной*
Дизайн обложки *А. В. Булатова*

Подписано в печать: 10.08.2018 г.
Формат 60×84 1/16. Гарнитура «Таймс». Бумага офсетная, печать офсетная.
Усл.-печ. л. 16,2. Уч-изд. л.16,7. Тираж 300 экз. Заказ